# 2020 елга Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында ХИСАП

Казан 2021

**Эчтәлеге**


| | |
|---|---|
| I. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ | 3 |
| II. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ | 14 |
| КЕШЕ КАПИТАЛЫ | 14 |
| Демография | 14 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсе һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру | 19 |
| Хезмәт базары, эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү һәм социаль яклау | 30 |
| Үсеш нигезе буларак мәгариф | 33 |
| Яшьләр сәясәте | 45 |
| Мәдәният үсеше. Креатив индустрияләр | 48 |
| Гражданлык җәмгыяте үсеше | 55 |
| ТИРӘЛЕК, РЕАЛЬ КАПИТАЛ | 62 |
| Транспорт-логистика инфраструктурасы | 62 |
| Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык | 68 |
| Татарстан Республикасында агломерацияләрне үстерү | 78 |
| Туристлык-рекреация комплексын үстерү | 84 |
| САТУ БАЗАРЛАРЫ | 91 |
| Тышкы икътисадый элемтәләрне үстерү | 91 |
| Нефть-газ-химия комплексы | 98 |
| Энергетика комплексы | 102 |
| Машина төзү һәм башка эшкәртү производстволары комплексы | 104 |
| Агросәнәгать комплексы | 120 |
| Сәүдә комплексы | 124 |
| ИНСТИТУТЛАР. ЭШКУАРЛЫК | 126 |
| Стратегик планлаштыру | 126 |
| Илкүләм проектлар | 128 |
| Эшкуарлыкка ярдәм итү | 130 |
| Дәүләт идарәсе | 138 |
| ИННОВАЦИЯЛӘР | 153 |
| Инновацияле үсеш | 153 |
| Электрон рәвештә хезмәт күрсәтү | 174 |
| ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ | 179 |
| Җир һәм су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану | 179 |
| Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметү | 184 |
| ФИНАНС КАПИТАЛЫ ҺӘМ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР | 188 |
| Финанс ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге | 188 |
| Инвестиция сәясәте | 194 |
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КОМИТЕТЛАРЫННАН ҺӘМ ДЕПУТАТ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕННӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ БУЕНЧА МӘГЪЛҮМАТ | 205 |

# I. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ




2020 елда коронавирус йогышлы чире таралу сәбәпле Татарстан Республикасының һәм тулаем алганда Россия Федерациясенең икътисады дөньякүләм кооперация һәм сәүдә элемтәләре чуалу, эшмәкәрлек активлыгы кимү, нефть бәяләре һәм валюта курслары үзгәреп тору, ОПЕК+ килешүе кысаларында нефть чыгару күләмнәрен чикләү нәтиҗәсендә киң мәйданда сатып алуга ихтыяҗның һәм тәкъдимнең чикләнүенә байтак дәрәҗәдә бәйлелектә булды.

Икътисадый һәм социаль тотрыклылыкны тәэмин итү максатларында илнең һәм Татарстан Республикасының җитәкчелеге тарафыннан коронавирус йогышлы чиренә каршы көрәшү, бизнеска һәм халыкка ярдәм күрсәтү өчен чаралар комплексы эшләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы чире таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары нигезендә республиканың бөтен территориясендә халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырылды. Коронавирус чиренең таралуы китереп чыгарган кризислы күренешләрнең нәтиҗәләрен киметү эшен оештыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы 620-р номерлы боерыгы нигезендә Яңа коронавирус йогышлы чире таралу, нефтькә бәяләрнең һәм доллар курсының үзгәреп торуы сәбәпле вазгыятьнең начараюы шартларында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен

тәэмин итү чаралары планы (алга таба – Чаралар планы) расланды. Ул төп 4 юнәлеш буенча эшләнде:

иң кирәкле товарлар белән тәэмин итү һәм халыкка ярдәм күрсәтү;

икътисадның куркыныч янаган зонадагы тармакларына ярдәм күрсәтү;

кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү;

гомум системалы чаралар.

Чаралар планын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 3 апрелендәге 719-р номерлы боерыгы нигезендә төзелгән Оператив штаб җитәкчелегендә алып барыла. Аңа Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин җитәкчелек итә. Чаралар планын гамәлгә ашыру барышы даими рәвештә Оператив штаб секретаре – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры М.Р. Шаһиәхмәтов доклады нигезендә видео-конференция элемтәсе режимында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов уздырган киңәшмәләрдә карала.

Чаралар планын гамәлгә ашыру буенча эш төркеме кысаларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, кредит оешмалары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, муниципаль берәмлекләр белән берлектә икътисадтагы һәм социаль өлкәдәге вазгыятьне тиз арада мониторинглау һәм чаралар күрү системасы җайга салынды. Россия икътисадының яңа коронавирус йогышлы чире таралу сәбәпле вазгыятьнең начараюы шартларында иң зур зыян күргән тармаклары оешмаларына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары нигезендә адреслы ярдәм күрсәтелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 8 октябрендәге 2080-р номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт өлеше булган һәм бюджетның нигезен тәшкил иткән, республика территориясендә эшчәнлек алып барган эре, икътисадый һәм социаль яктан әһәмияткә ия булган (система тәшкил иткән) оешмаларның, предприятиеләрнең финанс-икътисадый хәлен көн саен мониторинглау уздырылды, шуңа нигезләнеп тискәре нәтиҗәләрне киметү чаралары күрелде.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына зур ярдәм күрсәтелде. Федераль үзәктә эшләнгән программалар ярдәмендә Татарстан эшкуарлары хезмәт коллективларын саклап калу һәм хезмәт хакын вакытында түләү өчен субсидияләр, процентсыз кредитлар алуга ирештеләр, салым һәм иминиятләштерү кертемнәре буенча түләүләр буенча кичектереп тору, аренда өчен түләүләрдән азат ителү яисә аларны кичектереп тору, банкларның ташламалы кредитлау программаларында катнашу мөмкинлегеннән файдаландылар. Эшкуарлар хәзерге шартларга тизрәк җайлашсын өчен Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсе нигезендә барлыгы 3,3 млрд сумга республика чаралар комплексы тиз арада эшләнде һәм гамәлгә ашырылды. Бу исә зыян күрде дип танылган тармаклар исемлегенә кертелмәгән, әмма кризис аларга да тискәре йогынты ясаган тармакларга ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирде. Икътисадтагы вазгыятьне тотрыклырак итү, бизнеста чыгымнарны киметү, эш урыннарын саклап калу буенча вакытлы кабул ителгән

федераль дәрәҗәдәге һәм республика ярдәм чаралары күпчелектә тискәре социаль-икътисадый нәтиҗәләрне киметергә ярдәм итте.

Татарстан Республикасы төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча элеккечә – Россия Федерациясенең алдынгы төбәкләре сафында.

**Россия Федерациясе субъектлары һәм Идел буе федераль округы төбәкләре арасында Татарстан Республикасы рейтингы**

| Макроикътисадый күрсәткечләр | 2020 ел | |
|---|---|---|
| | Россия Федерациясе субъектлары арасында | Идел буе федераль округы төбәкләре арасында |
| Тулаем төбәк продукты күләме[1] | 6 | 1 |
| Сәнәгать җитештерүе күләме | 4 | 1 |
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе күләме | 4 | 1 |
| Төп капиталга кертелгән инвестицияләр күләме | 6 | 1 |
| «Төзелеш» эшчәнлеге төре буенча башкарылган эшләр күләме | 6 | 1 |
| Торакны файдалануга тапшыру | 5 | 1 |
| Ваклап сатуда товар әйләнеше | 7 | 1 |
| Уртача номиналь айлык хезмәт хакы | 36 | 2 |
| Эшсезлекнең теркәлгән дәрәҗәсе (декабрь ахырына)[2] | 10 | 1 |

[1]2019 ел

[2] Урыннарга бүленеш күрсәткечнең артуы тәртибендә бүленешенә нигезләнеп исәпләнгән (беренче урын – иң түбән (иң яхшы), соңгы урын – иң югары (иң начар) күрсәткеч.

Республика Россия Федерациясе субъектлары арасында тулаем төбәк продукты күләме буенча – алтынчы (*2019 ел йомгаклары буенча*), сәнәгать җитештерүе һәм авыл хуҗалыгы буенча – дүртенче, торакны файдалануга тапшыру буенча – бишенче, төзелеш һәм төп капиталга инвестицияләр кертү буенча – алтынчы, ваклап сатудагы товар әйләнеше буенча җиденче урында тора.

**2020 елда Татарстан Республикасының ТТП**



2020 ел йомгаклары буенча тулаем төбәк продукты күләме, бәяләүләр буенча, 2 446,7 млрд сум тәшкил иткән, ягъни 2019 елга карата – 97,1 процент.

**2020 елда икътисадый эшчәнлек төрләре буенча Татарстан Республикасының ТТП җитештерү структурасы (бәяләү), %**




Икътисад структурасында иң зур өлешне, традиция буенча, сәнәгать алып тора һәм 45,9 процентны тәшкил итә (шул исәптән файдалы казылмалар чыгару – 26,1 процент, эшкәртү производстволары – 17,2 процент, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру – 2,2 процент, су белән тәэмин итү; су бүлү, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрату очракларын бетерү буенча эшчәнлек – 0,4 процент), күпләп һәм ваклап сату 10,7 процентны, төзелеш 7,8 процентны, авыл хуҗалыгы 6,5 процентны тәшкил итә.

**Сәнәгать**

Сәнәгать җитештерүе индексы 2020 ел дәрәҗәсенә карата 96,4 процент, төяп җибәрелгән продукция күләме 2 721,2 млрд сум[1] тәшкил итте.

Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2019 ел дәрәҗәсенә карата – 89,5 %, эшкәртү производстволарында – 102 %, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итүдә; һава әйләнешен булдыруда – 85,4 %, су белән тәэмин итүдә; юынтык су агызуда, калдыкларны җыю һәм утильләштерүдә, пычрату очракларын бетерү буенча эшчәнлекне оештыруда 98,4 % тәшкил итте.

Эшкәртү производстволарының түбәндәгеләрендә үсеш күзәтелде: кокс һәм нефть продуктлары (2019 ел дәрәҗәсенә карата 103,1 %), резина һәм пластмасса

[1]2020 елның гыйнварыннан 2018 һәм 2019 еллар өчен сәнәгать җитештерүе индексын исәпләү 2018 ел күрсәткечләренә нигезләнеп башкарыла.

әйберләр (110,6 %), дәвалау максатларында кулланыла торган дарулар һәм материаллар (124,8 %), азык-төлек продуктлары (114,1 %), эчемлекләр (107,4 %), электр җиһазлары (124,3 %), металлургия җитештерүендә (102,4 %), текстиль әйберләр (132,4 % ) кием (114,5 %) кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр (107,4 %) җитештерү, башка әзер эшләнмәләр (129,2 %).

**2020 елда сәнәгать өлкәсендә җитештерү**




Химик матдәләр һәм химия продуктлары (2019 елга карата 96,8 %), автотранспорт, прицеплар (96,4 %), башка транспорт һәм җиһазлар (73,9 %), машина һәм җиһазлар (98,5 %), компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр (94,3 %), машиналар һәм җиһазлардан тыш, әзер металл эшләнмәләр (96,9 %), металл булмаган башка минераль продукция (97,4 %), агач эшкәртү һәм агачтан һәм бөкедән эшләнмәләр (87,8 %), күн һәм күн эшләнмәләр (75,4 %), мебель (65,6 %) җитештерүдә күрсәткечләр тискәре булды.

Дизель ягулык (2019 елга карата 4,6 %), автомобиль бензины (1,7 %), нефть коксы (9,5 %), шин, покрышка, резин камералар (3,4 %), дару препаратлары (24,4 %), йөк автомобильләре (1,4 %), кәгазь-катыргы (3 %), йорт хуҗалыгы өчен суыткычлар (1,1 %) җитештерү артты.

Шул ук вакытта нефть чыгару күләме (2019 елга карата 89 %), синтетик каучукның башлангыч формалары (87,5 %), ягулык мазуты (66,6 %), җиңел автотранспорт (4,6 %), һава яисә вакуум насослары, һава яисә башка төр газ компрессорлары (77,8 %), электроэнергия (82 %) җитештерү кимеде.

Сәнәгать структурасында файдалы казылмалар чыгару өлеше – 21,2 %, эшкәртү производстволары өлеше – 72,5 %, электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру өлеше – 5,1 %, су белән тәэмин итү; су бүлү, калдыкларны җыю һәм утильләштерү, пычрату очракларын бетерү эшчәнлеге өлеше 1,2 % тәшкил итте.

**2020 елда Татарстан Республикасы сәнәгате структурасы,%**




## Авыл хуҗалыгы

Авыл хуҗалыгында продукция күләме 263,4 млрд сум, ягъни 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 104 % тәшкил итте.

Үсемлекчелек продукциясен җитештерү 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 6,6 процентка артты һәм 135,5 млрд сум тәшкил итте.

2020 елда терлекчелек продукциясе җитештерү 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,5 процентка артты һәм 127,9 млрд сум тәшкил итте.

Барлыгы беренчел исәпкә алынган авырлыкта 5 566,9 мең тонна ашлык җыеп алынды (ахырга кадәр ачыкланган авырлыкта 5 200,8 мең тонна), бу исә 2019 ел белән чагыштырганда 23,1 процентка артыграк.

барлыгы 2 150,8 мең тонна шикәр чөгендере (2019 елга карата – 76,7 %), 325,8 мең тонна (94,7 %) яшелчә (каплаулы туфракта үстерелгәнен дә кертеп) үстерелде. Республикада 1 174,2 мең тонна бәрәңге (2019 елга карата – 96,7 %) җыеп алынды.

**2020 елда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме**




Барлык категория хуҗалыкларда 528,6 мең тонна сугым терлеге һәм кош-корт (сугымга кадәрге авырлык) (2019 ел белән чагыштырганда 102,1 %), 1 935,2 мең тонна сөт (102,1 %), 1 475,4 млн данә йомырка (98,2 %) җитештерелде.

Авыл хуҗалыгы оешмаларында бер сыерга уртача 6 348 килограмм сөт савылды, бу 2019 елга караганда 7,6 процентка күбрәк. Бер тавыкның йомырка салуы 3,4 процентка кимеде һәм 314 данә тәшкил итте.

## Төзелеш

2020 ел йомгаклары буенча төзелеш эшләре күләме 356,1 млрд сум, ягъни 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 96 % тәшкил итте.

**2020 елда «төзелеш» эшчәнлек төре буенча эш күләме**




Гомуми мәйданы 2 680,1 мең кв.метр тәшкил иткән торак файдалануга тапшырылды, бу 2019 ел дәрәҗәсенә карата 100,2%[2] % тәшкил итте. Социаль ипотека программасы буенча гомуми мәйданы  216,5 мең кв.метр булган 3 767 фатир төзелде.

**2020 елда файдалануга торак тапшыру**




## Кулланучылар базары

Карантин чаралары кертелү кулланучылар ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән тармакларда аеруча тискәре нәтиҗәләргә китерде.

## 2020 елда ваклап сату әйләнеше




2020 елда ваклап сатуда товар әйләнеше 926,3 млрд сум тәшкил итте (2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 93,9 %), җәмәгать туклануында әйләнеш – 36,2 млрд сум (73,6 %), халыкка түләүле хезмәт күрсәтү күләме – 262,6 млрд сум (87,4 %).

## 2020 елда җәмәгать туклануында әйләнеш




## Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү күләме



**Кулланучылар бәяләре индексының динамикасы**
(2019 елның декабренә карата, процентларда)




Ел башына (2019 елның декабренә карата 2020 елның декабре) куллану бәяләре үсеше 104,8 %, шул исәптән азык-төлек товарларына 107,1 %, азык-төлек булмаган товарларга 104,9 %, хезмәт күрсәтүләргә 101,8 % тәшкил итте.

2020 елның декабрендә Татарстан ИФОның 14 төбәге арасында инфляция тизлеге ягыннан 12 урында торды (1 урында Саратов өлкәсе (106,7 %), 14 урында Пермь крае (104,5 %).

**Тормыш дәрәҗәсе**

Республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлек субъектларын да кертеп, уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы 2020 елда 39 588,3 сум тәшкил итте һәм 2019 ел белән чагыштырганда, 5,6 процентка артты. Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре индексын исәпкә алып хисапланган реаль хезмәт хакы 102,4 % тәшкил итте.

2020 елда уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы күләме буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында рэнкингта Татарстан 2 нче урында тора (1 нче урында – Пермь крае).

**Айлык уртача хезмәт хакы динамикасы**



2020 ел йомгаклары буенча республикада югары хезмәт хаклары икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төрләрендә күзәтелгән: файдалы казылмалар чыгару – 63,5 мең сум; финанс һәм иминиятләштерү эшчәнлеге – 58,7 мең сум; электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру – 51,3 мең сум; һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек – 55,1 мең сум; мәгълүмат һәм элемтә өлкәсе – 54,0 мең сум; эшкәртү производстволары – 43,9 мең сум.

2020елда бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы түбәндәгечә: сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә – 40,8 мең сум, мәгариф өлкәсендә – 32,2 мең сум, мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачуны оештыру өлкәсендә – 41,5 мең сум.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында социаль өлкә учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын этаплап арттыру буенча планлы эш алып барыла. Күрелгән чаралар нәтиҗәсендә 2020 ел өчен хезмәт хакы түбәндәгечә булды:

мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләре – 31 199,6 сум;

гомуми белем бирү учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләре – 34 474,8 сум;

балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләре – 36 644,8 сум;

башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укытучылары һәм мастерлары – 35 520,4 сум;

югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре укытучылары – 78 330,0 сум;

медицина оешмаларының медицина хезмәтләре күрсәтүче, югары медицина (фармацевтика) яки башка югары белеме булган табиблары һәм хезмәткәрләре, – 76 809,1 сум;

урта медицина (фармацевтика) персоналы – 38 415,6 сум;

кече медицина персоналы – 33 429,1 сум;

социаль хезмәткәрләр – 34 423,5 сум;

мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре – 34 634,6 сум;

фәнни хезмәткәрләр – 51 196,7 сум;

белем бирү, медицина оешмаларының яки ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның педагогика хезмәткәрләре – 36 141,4 сум.

«Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә 2021 елның 1 гыйнварыннан хезмәткә түләүнең минималь күләме 2019 елның 1 гыйнвары белән чагыштырганда 7,5 процентка артты һәм аена 12 130 сум, 2021 елның 1 гыйнварыннан аена 12 792 сум тәшкил итте.

Федераль дәрәҗәдә хезмәткә түләүнең минималь күләме артуга бәйле рәвештә 2019 елның 25 декабрендә Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы эш бирүчеләр берләшмәләре координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Татарстан

Республикасында минималь хезмәт хакы турында килешү кабул ителде (алга таба – Килешү). Аңа таянып 2020 елның 1 гыйнварыннан икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмаларында һәм юридик зат оештырмыйча эшкуарлык белән шөгыльләнүче индивидуаль эшкуарлар тарафыннан үз акчалары, эш вакыты нормасын тутырган һәм хезмәт нормаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрнең минималь хезмәт хакы аена 14 000 сумнан да ким булмаган күләмдә билгеләү күздә тотыла. Бу 2019 елның 1 кварталы өчен тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 88,8 процентын тәшкил итә.

2020 елның 30 декабрендәге килешү нигезендә 2021 елның 1 гыйнварыннан минималь хезмәт хакы аена 15 400 сум күләмендә билгеләнде, бу исә 2020 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 93,3 процентын тәшкил итә.

Бурычлы предприятиеләр белән эшләү республикада Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 25 февралендәге ПУ-207 номерлы Указы нигезендә төзелгән Халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, хезмәт, Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе, шулай ук Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы республика комиссиясе каршындагы Хезмәткә түләү, керемнәр һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча координация советы эшчәнлеге кысаларында муниципаль берәмлекләрдәге территориаль комиссияләр, тармак министрлыклары, контроль күзәтчелек һәм салым органнары, республиканың һөнәри берлекләре һәм эш бирүчеләре берләшмәләре белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла.

# II. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

## КЕШЕ КАПИТАЛЫ

### Демография

Кеше капиталы үсешенә демографик процессларның аерым йогынтысы бар.

2020 елда республикада 41 598 кеше туды, туучылар коэффициенты 1000 кешегә 10,7 очрак тәшкил итте (Россия буенча – 1000 кешегә 9,8 очрак).

2020 елда халык арасында үлүчеләр саны күрсәткече 1000 кешегә 13,9 очрак тәшкил итте (Россиядә – 1000 кешегә 14,5 очрак). 2019 елда үлүчеләр саны структурасында кан әйләнеше системасы авырулары – 100 мең кешегә 657,7 очрак (2019 елда – 532,7 очрак), шешләр барлыкка килү – 100 мең кешегә 186,8 очрак (2019 елда – 187,6 очрак), клиник һәм лаборатория тикшеренүләре вакытында ачыкланган, башка рубрикаларда классларга бүленмәгән симптомнар, билгеләр һәм нормадан тайпылышлар – 100 мең кешегә 105 очрак (2019 елда – 75,9 очрак).

Сабыйлар арасында үлем-китем очраклары коэффициенты тере туган 1 000 балага 4 очрак тәшкил итте (2019 елда – 4,88).

Халыкның табигый кимүе – 12 678 кеше яисә 1000 кешегә (–) 3,2 (Россиядә тулаем – (–) 4,7).

Демография процессларында тискәре тенденцияләргә карамастан, Татарстан Республикасы бала туу дәрәҗәсе ягыннан 1000 кешегә иң югары, ә үлем-китем очраклары ягыннан иң түбән коэффициентка ия.

***«Демография» илкүләм проекты***

*«Гаиләләргә бала туганда финанс ярдәме күрсәтү» төбәк проекты*

Татарстан Республикасында халыкның тотрыклы табигый үрчемен саклап калу өчен системалы нигездә балалы гаиләләр өчен социаль инфраструктура булдырыла, социаль программалар, шул исәптән балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният йортлары, спорт объектлары, фельдшер-акушерлык пунктлары төзү һәм төзекләндерү, амбулатория-поликлиника учреждение, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен, балаларны савыктыру лагерьларын, яшүсмерләр клубларын капиталь төзекләндерү программалары гамәлгә ашырыла. Балалы гаиләләргә федераль һәм төбәк социаль ярдәм чараларының киң пакеты бирелә.

2019 елдан «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында беренче бала тууга (уллыкка-кызлыкка алуга) бәйле рәвештә җан башына кереме хезмәткә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләменнән 1,5 тапкырдан артып китмәгән гаиләләргә айлык түләүләр бирелә. 2020 елда 28 567 кеше мондый түләүне алган.

Шулай ук 2019 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала тапкач бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2019 елның 9 февралендәге 67 номерлы карары нигезендә Татарстан

Республикасы территориясендә авыл җирендә кимендә өч ел даими яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган түләүләр каралган: 25 яше тулганчы беренче баласын тудыргач – 50 мең сум; 29 яше тулганчы өченче баласын тудыргач – 100 мең сум. 2020 елда 2 320 хатын-кыз мондый түләүне алды.

Балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында берьюлы өч яисә аннан артыграк бала туган 6 гаиләгә 2020 елда һәр балага 10 мең күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие һәм берьюлы туган өч яисә өчтән артык 1,5 тулмаган бала тәрбияләүче 21 гаиләгә ай саен һәр балаларга 1 мең сум күләмендә айлык пособие түләнде.

Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә 2020 елның 1 гыйнварыннан республика территориясендә түбәндәге ярдәм чаралары кертелде:

биш һәм аннан да күбрәк балалы, җан башына кереме уртача яшәү минимумыннан азрак булган гаиләләрнең һәр әгъзасына гаиләнең җан башына исәпләнгән уртача кереме һәм яшәү минимумы арасындагы аерма күләмендә айлык пособие (2020 елда мондый түләүне 12 605 граждан алды);

өч һәм аннан да күбрәк балалы, җан башына кереме уртача яшәү минимумыннан азрак булган гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүгә компенсация күләме 100 процентка кадәр арттырылды. Яңа шартлар буенча 2020 елда 5 821 гражданга акча күчерелде;

җан башына уртача кереме халыкның җан башына исәпләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, яңа туган балалары булган аз керемле гаиләләрдәге өч яше тулмаган балаларга ярты елга бер тапкыр дару һәм аптека ассортиментындагы башка товарлар сатып алу өчен 5 мең сум күләмендә акча (елына гомуми күләме 10 мең сум тәшкил итә). 2020 елда түләүне 5 083 граждан алган;

җан башына уртача кереме халыкның җан башына исәпләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, яңа туган балалары булган гаиләләргә балалар өчен кирәк-яракларның бүләк комплектлары. 2020 елда мондый комплектлар 4 415 гаиләгә бирелгән.

Анага олы хөрмәт тәрбияләү максатларында биш яисә аннан артык бала тапкан һәм лаеклы итеп тәрбияләгән 24 хатын-кызга 2020 елда «Ана даны – Материнская слава» медале тапшырылды. Медаль белән бүләкләнгән, 5 бала тәрбияләп үстергән аналарга 50 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырылды, 6 яисә аннан артык бала тәрбияләгән аналарга, бүләкләү көненә аларга яшь ярым тулган очракта, һәрбер шуннан соң туган балаларга акчалата бүләкләү күләме 10 мең сумга арттырылды.

*«Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яше тулмаган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын булдыру» төбәк проекты*

Мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында «Демография» илкүләм проекты кысаларында Татарстан Республикасында 1,5 яшьтән алып өч яше тулмаган балалар өчен мәктәпкәчә оешмаларда өстәмә урыннар булдыру буенча чаралар күрелде. Хисап елында 5 030 урынга 22 мәктәпкәчә белем бирү объекты (шул исәптән 10 сы – компенсация чаралары кысаларында), шулардан 2 525 урын 1,5 нан алып 3 яшькәчә балалар өчен. 2020 елда моңа 5,2 млрд сум, шул исәптән федераль

бюджет акчалары исәбеннән 1,2 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 4,0 млрд сум бүлеп бирелде.

2020 елда 3 яше тулмаган бала караучы, мәктәпкәчә яшьтәге баласы булган, хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм эшкә урнаштыру органнарына мөрәҗәгать иткән 3 363 хатын-кыз яңадан һөнәри әзерлек узды һәм квалификациясен күтәрде.

*«Өлкән яшьтәге гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк проекты*

2019 елда Татарстан Республикасы озак вакыт дәвамында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны тәрбияләү системасын булдыру буенча пилот төбәкләр арасына керде. Республиканың өлкән яшьтәге гражданнарын һәм инвалидларны озак вакыт дәвамында карау системасын булдыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру чаралары төбәк планы («юл картасы») расланды, анда озак вакыт дәвамында тәрбияләү системасын кертүнең төп юнәлешләре билгеләнде.

2020 елда 3 682 кешегә, ягъни өйдә социаль хезмәтләр алучы өлкәннәр санының 16,1 процентына мондый ярдәм күрсәтелә.

Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт дәвамында карау системасын төзүгә 2020 елда 148,3 млн сум, шул исәптән 120,1 млн сум федераль бюджет акчалары һәм 28,2 млн сум Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан тотылды.

2020 елда Татарстан Республикасы хосусый медицина оешмаларын 65 яше тулган һәм аннан да өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәт күрсәтү эшенә тарту буенча пилот төбәкләр арасына керде. Конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча 4 оешма җиңүче буларак танылды, алар белән 65 яше тулган һәм аннан да өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәт күрсәтүгә тотылган чыгымнарны каплау өчен 31,1 млн сум күләмендә субсидияләр рәвешендәге грантлар бирүгә килешүләр төзелде. Хисап елында 360 кешегә медицина-социаль хезмәт күрсәтелде.

2020 елның 3 сентябрендә 2019 елда «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 97 урынга исәпләнгән өч катлы торак корпусы файдалануга тапшырылды. Аны төзүгә 2019–2020 елларда 86,3 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджет исәбеннән – 63,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 23,1 млн сум.

«Өлкән яшьтәге гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк проекты кысаларында 50 яшен тутырган һәм аннан өлкәнрәк, шулай ук пенсия яшенә җиткән кешеләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү оештырыла. 2020 елда бу эшкә 87,5 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән 70,9 млн сум – федераль бюджет акчалары хисабыннан, 16,6 млн сум Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан.

2020 елда 20 гериатрия кабинеты ачылды. Республикада 42 муниципаль берәмлектә 63 амбулатория-поликлиника учреждениеләре һәм үзәк район хастаханәләре поликлиникалары базасында 63 гериатрия кабинеты эшли, аларның 37 се 2019 елда ачылды. 13 медицина оешмасы базасында стационар гериатрик ярдәм күрсәтү өчен 12 муниципаль берәмлектә 175 койка тәүлек буе эшли, шулардан 7 койка 2020 елда ачылды.

Диспансерлаштыру һәм профилактик медицина тикшерүләре уздыру кысаларында, шул исәптән диспансер күзәтүе барышында, хезмәткә сәләтлелек яшендәге 196 383 кешенең сәламәтлеген тикшерү уздырылды (хезмәткә сәләтлелек яшендәге гражданнар санының 19,5 проценты). Хезмәткә сәләтлелек яшен узган, авыру икәнлекләре һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булуы ачыкланган, диспансер күзәтүендә торган затлар өлеше – 77 %.

Комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре өчен 2019 елда 43 автомобиль сатып алынды, бу исә 2020 елда диспансерлаштыру һәм профилактик медицина күзәтүләре, медицина тикшеренүләре уздыру, планлы төстә госпитальләштерү өчен авыл җирендә яшәүче, 65 яшен тутырган 44,9 мең кешене үзәк район хастаханәләренә һәм табиблык амбулаторияләренә китерү мөмкинлеге бирде.

*«Дөрес туклануны һәм начар гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру» төбәк проекты*

Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру максатыннан чыгып «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру дәвам иттерелде. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Йогышлы булмаган авыруларны профилактикалауны һәм медицина оешмаларында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чараларын уздыруны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 октябрендәге 1177н номерлы боерыгы нигезендә Әлмәт, Зеленодольск, Казан һәм Түбән Кама шәһәрләрендә җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча 4 үзәк эше оештырылды. Республикада 22 муниципаль берәмлектә җәмәгать сәламәтлеген ныгыту буенча муниципаль программалар расланды.

Предприятиеләрдә хезмәткәрләр сәламәтлеген ныгыту буенча күмәк программалар эшләнә һәм куллануга кертелә. Аерым темаларга багышланган республикакүләм акцияләр, конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләр, матбугат конференцияләре, барлык Россиякүләм мәгълүмати кампанияләрдә, шул исәптән онлайн форматта, катнашу оештырылды.

*«Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәренә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шул исәптән спорт объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен арттыру шулай ук спорт резервын формалаштыру» төбәк проекты*

Татарстан Республикасында 11 205 спорт корылмасы (авыл җирендә – 4 814 корылма) бар, болар: 45 стадион, мәйданчыклы 6 020 спорт корылмасы, 2 012 спорт залы, ясалма бозлы 49 ябык объект (52 бозлы мәйданчык бар), 16 манеж (10 җиңел

атлетика, 6 футбол кыры), ябык һәм ачык 249 йөзү бассейны, 87 чаңгы базасы, спортның мылтыктан ату төрләре өчен 183 корылма, спортның ишкәкле төрләре өчен 2 корылма, башка төрдәге 2 539 спорт корылмасы.

2020 елда республикада 406 спорт корылмасы файдалануга тапшырылган. Спортның олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия база төрләре буенча спорт оешмаларына адреслы ярдәм күрсәтелде. Гомуми суммасы 31,7 млн сумлык субсидия спортның төп төрләрен халыкка танытучы 8 дәүләт оешмасына бирелде.

2020 елда Татарстан Республикасында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнар (3 яшьтән 79 яшькәчә) саны 51,3 % тәшкил итте (2019 елда – 49,5 %);

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр (3 яшьтән 29 яшькәчә) өлеше – 87,8 % (2019 елда – 86,1 %);

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче урта яшьтәге гражданнар (30 – 54 яшьлек хатын-кызлар, 30 – 59 яшьлек ир-атлар) өлеше – 40,6 % (2019 елда – 38,4 %);

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче өлкән яшьтәге гражданнар өлеше (55 – 79 яшьлек хатын-кызлар, 60 – 79 яшьлек ир-атлар) – 17,6 % (2019 елда – 14,0 процент);

физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затлар өлеше – 28,5 % (2019 елда – 28,0 %).

2024 елга Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт белән даими рәвештә шөгыльләнүче гражданнар өлешен 60,2 процентка җиткерү планлаштырыла

Татарстан Республикасында 171 спорт мәктәбе эшли (шуларның 33е Олимпия резервындагы махсус спорт мәктәбе), аларда 74 спорт төре үстерелә.

2020 елда Россиянең спортның олимпия төрләре буенча җыелма командалары составына Татарстаннан 395 спортчы кертелде (2019 елда – 385 спортчы).

Республикада 24 эре ярыш, шуларның 8е халыкара дәрәҗәдә, уздырылды. 2020 елда Татарстан Республикасы спортчылары Россия күләмендәге һәм халыкара ярышларда 425 медаль яулады, шуларның 124е – алтын, 165е – көмеш, 136 сы – бронза.

2021 елда Токиодагы Олимпия Паралимпия уеннарында катнашу өчен Татарстан Республикасыннан спортның 14 олимпия төре буенча 31 спортчы һәм спортның 2 паралимпия төре буенча 3 спортчы Россия җыелма командасы составына кертелде.

***«Татарстан – Идел буена халыкны җәлеп итү үзәге» флагман проекты***

«Татарстан – Идел буена халыкны җәлеп итү үзәге» проекты Татарстан Республикасы халкының, барыннан да элек, Россиянең башка төбәкләреннән килгән мигрантлар хисабына артуын көчәйтүгә һәм мигрантлар агымында төбәк хезмәт базарында кирәкле квалификацияле һәм югары квалификацияле белгечләр санын арттыруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт

программасы кысаларында ел саен мигрантларның социаль җайлашуына юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларны үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирелә.

2020 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан мигрантларның социаль җайлашуына юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларны үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирүгә конкурс уздырылды. Аның йомгаклары буенча әлеге максатларга «Яңа гасыр» автоном коммерцияле булмаган хәйрия оешмасы 2,4 млн сум күләмендә субсидия алды, 2020 елда курсларда 3 100 мигрантка белем бирелде.

2020 елда Татарстан Республикасында яшәү урыны буенча 185 639 чит ил гражданы (2019 елда – 324 163 кеше), шул исәптән беренчел буларак – 96 379 чит ил гражданы (2019 елда – 233 633 кеше), теркәүне озайту тәртибендә – 89 260 чит ил гражданы (2019 елда – 90 530 кеше) миграция исәбенә куелды.

Республикага чит ил гражданнарының күпчелеге Үзбәкстан, Таҗикстан, Казахстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Украинадан, Кытайдан, Төркиядән һәм Германиядән килә. Үзләренең республикага килү максаты хезмәткә бәйле булуы турында 40 178 чит ил гражданы белдерде (республикага беренче тапкыр килгән кешеләрнең гомуми санынннан 41,7 %).

2020 елда чит ил гражданнарына эшкә 18,3 меңнән артык патент рәсмиләштерелде (2019 елда – 31,8 мең патент), алар өчен Татарстан Республикасы бюджетына 588,9 млн сум күчерелгән (2019 елда – 781,8 млн сум).

### Сәламәтлек саклау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру

2020 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру дәвам иттерелде. Ул сәламәтлек саклау өлкәсендә профилактикалауны һәм беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне үстерүгә, махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен, диагноз кую өчен тикшеренүләрнең, профилактика һәм дәвалауның инновацион ысулларын үстерү һәм гамәлгә кертү, халыкны медицина ысуллары белән тернәкләндерүне үстерүгә, сәламәтлек саклау системасын югары квалификацияле һәм мотивацияле кадрлар белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Республикада баш мие кан әйләнеше гадәттән тыш бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү системасын камилләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыру дәвам итә. Республикада мондый авырулар өчен 18 районара неврология бүлеге эшли. 2020 елда аларда 15 993 кеше дәваланган (2019 елда – 17874 кеше), ишемия инсульты белән чирләүчеләргә 852 тромболизис үткәрелгән (2019 елда – 1 057 тромболизис).

Йөрәк кан тамырлары чиренең көчәюе күзәтелгәндә, шул исәптән миокард инфаркты вакытында, халыкка ашыгыч медицина ярдәме, коронарография һәм йөрәк кан тамырларын стентлау технологияләрен кулланып, барлык муниципаль берәмлекләрдә 7 күппрофильле югары технологияле медицина учреждениесе базасында күрсәтелә. Алар түбәндәгеләр: «Татарстан Республикасы Сәламәтлек

саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария часте, «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Казан шәһәренең 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Татнефть» ГАҖ һәм Әлмәт шәһәренең медицина-санитария часте, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.

2020 елда әлеге медицина учреждениеләренә «гаять көчле коронар синдром» диагнозы белән 11 528 пациент (2019 елда – 11 484 кеше), шул исәптән 5 542 кеше «миокард инфаркты» диагнозы белән (2019 елда – 5 495 кеше) салынды, ашыгыч рәвештә диагноз кую өчен коронарография (2019 елда – 8 010), йөрәк кан тамырларына 4 692 ашыгыч ангиопластика (2019 елда – 4 289) уздырылды.

Татарстан Республикасында югары технологияле медицина ярдәмен 21 профиль буенча 17 медицина оешмасы күрсәтә, 2020 елда мондый ярдәм 28 719 кешегә күрсәтелде (2019 елда – 24 284 кеше).

2020 елда Татарстан Республикасында яман шеш авыруларының 13 765 очрагы беренчел ачыкланды (алга таба – ЗНО), бу 2019 елга караганда 16,6 процентка кимрәк (16 507 очрак). ЗНО: калын эчәк – 13 %, тире меланомасы – 12,1 %, сөт бизләре – 11,9 %, үпкә – 9,8 %, хатын-кыз җенес органнары – 9,9 %, ашказаны – 6,5 %, мәни бизе – 6 %.

Татарстан Республикасында органнар күчереп утырту буенча ике үзәк эшли: «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында бөер һәм бавыр күчереп утырту, «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында – йөрәк күчереп утырту башкарыла. «Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә 2020 елда бөер күчереп утырту буенча 40, бавыр күчереп утырту буенча 18 операция ясалды. «Төбәкара клиник-диагностик үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында йөрәк күчереп утырту буенча 4 операция ясалды.

2020 елда республикада бала тудыра алмый торган авыруларны ярдәмче репродуктив технологияләр кулланып дәвалау буенча шәхси милек формасындагы 7 оешмада оештырылган: «АВА-ПЕТЕР» ҖЧҖ, «АВА-Казан» АҖ, «ВРТ» ҖЧҖ, «Гаилә медицинасы клиникасы» ҖЧҖ, «Нуриевлар Клиникасы – Чаллы» ҖЧҖ, «Корл» ҖЧҖ, «Ана һәм бала – Казан» ҖЧҖ. Экстракорпораль аталандыру буенча 2 333 процедура үткәрелгән, шуларның 648е – яралгы күчереп утырту чаралары.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең яңа туган балалар патологиясе бүлегендә 2020 елда 1 619 яңа туган бала (2019 елда – 1 341 бала), шул исәптән 629 җитлекми туган бала (38,9 %), экстремаль аз авырлыктагы 66 бала, бик аз авырлыктагы 113 бала дәваланды.

Республикада халыкка ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче 68 структур бүлекчә эшли: 3 ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе һәм үзәк район

хастаханәләрендәге 5 станция, аларның составына 10 подстанция, 8 филиал, 42 бүлекчә керә.

Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хезмәтенә 436 санитар транспорт бүлеп бирелде: «В» класслы 399 автомобиль һәм «С» классы 37 автомобиль. 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән һәм федераль программаны гамәлгә ашыру кысаларында санитар машиналар паркына 100 ашыгыч медицина ярдәме автомобиле өстәлде, шуларның 54 е Татарстан Республикасы бюджеты, 46 сы федераль бюджет акчалары хисабына сатып алынды. Бу исә санитар автомобильләр паркын тулысынча яңартырга һәм файдалану срогы 5 елдан да артмаган санитар автотранспорты белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Бердәм территориаль-бүленеш мәгълүмати-идарә системасын булдыру концепциясе нигезендә 2020 елда ашыгыч медицина ярдәме һәм һәлакәтләр медицинасы төбәк автоматлаштырылган системасын булдыру һәм куллануга кертү эше башкарылды. Бу ашыгыч медицина ярдәме эшенең ачыклыгын, учреждениенең барлык технологик эш циклын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә (чакыртуларны телефоннан кабул итү һәм бүлүдән алып мәгълүматны статистик эшкәртү һәм учреждение эшенең нәтиҗәлелеген бәяләүне кертеп). «112» системасы белән хезмәттәшлек итү зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең тиз арада башкарылуына китерде. Бердәм диспетчерлык хезмәте эшенә 8 ашыгыч медицина ярдәме станциясе һәм 42 бүлекчәсе, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Республика һәлакәтләр медицинасы үзәгенең барлык структур бүлекчәләре тоташтырылган.

2020 елның декабрендә ашыгыч ярдәм системасының ведомство мәгълүмат системасына – «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе автоматлаштырылган системасына кертү эше төгәлләнде, бу исә ашыгыч чакырту карточкасын поликлиникага электрон рәвештә тапшыруны җайга салырга мөмкинлек бирде. Медицина ярдәме күрсәтүнең күчемлелеген тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен автоматлаштырылган эш урыннары булдырылды: «Кабул итү бүлекчәсе», «Санитария авиациясе».Ашыгыч ярдәмнең барлык бригадаларына планшетлар тапшырылды, бу исә аларның кайдалыгын һәм статусын реаль вакыт режимында белергә, чакырту буенча мәгълүмат алмашырга мөмкинлек бирә.

2020 елда ашыгыч медицина ярдәме хезмәте көчләренең һәм чараларының гадәттән тыш хәлләрдә катнашырга һәм аларның медицина-санитария ягыннан тискәре нәтиҗәләрен бетерергә әзерлеген арттыру һәм Татарстан Республикасында үзара хезмәттәшлек дәрәҗәсен камилләштерү максатларында 396 оператив әзерлек чарасы, шул исәптән тактикага кагылышлы махсус 182 өйрәтү һәм күнекмә, 33 команда-штаб өйрәтүе, 175 штаб өйрәтүе, комплексы ведомствоара 6 өйрәтү үткәрелде.

«Белем бирү сыйфатын мониторинглау республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе бригадалары 2 252 тапкыр, шулардан гадәттән тыш һәм штаттан тыш хәлләргә – 292 тапкыр, медицина эвакуациясенә – 1 663 тапкыр, шул исәптән санитар авиация линиясе буенча 461 тапкыр чыктылар.

*Яңа коронавирус йогышлы чиренә (COVID-19) каршы көрәшү чаралары*

Медицина ярдәме күрсәткәндә яңа коронавирус йогышлы чире (COVID-19) таралуны булдырмау буенча чаралар Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Яңа коронавирус йогышлы чире COVID-19 таралуын кисәтү һәм куркынычны киметү чараларын гамәлгә ашыру максатларында медицина оешмалары эшен оештыруның вакытлы тәртибе» 2020 елның 19 мартындагы 198н номерлы боерыгы нигезендә башкарыла. Медицина ярдәме Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган COVID-19ны кисәтү, диагностикалау һәм дәвалау буенча вакытлы методик күрсәтмәләр нигезендә башкарыла. Медицина ярдәме күрсәтүне сорап территориаль поликлиникага мөрәҗәгать иткәндә яисә табибны өйгә чакыртканда медицина ярдәме Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасы белән билгеләнгән срокларда башкарыла.

Татарстан Республикасы территориясендә яңа коронавирус йогышлы чире COVID-19 таралуны кисәтү һәм кирәкле профилактик һәм дәвалау-диагностикалау буенча чараларны вакытында кабул итү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан оператив штаб төзелде (2020 елның 18 мартындагы 488 номерлы боерык). Аның 2020 елның 19 мартындагы карары нигезендә авырулар күпләп китерелгән чорда медицина оешмалары эшен килештерү һәм яңа төрдәге коронавирус йогышлы чирен, хастаханәдән тыш пневмония йоктырган авыруларга вакытында медицина ярдәме күрсәтү максатында республика шартлы төстә 5 медицина округына бүленгән: Үзәк, Төньяк-көнчыгыш, Түбән Кама 5 Көньяк-көнчыгыш, Кама аръягы. Һәр округта медицина оешмаларының эшен этаплап җәелдерү каралган.

Медицина оешмаларының көчле респиратор вируслы чир, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы чире COVID-19, хастаханәдән тыш пневмония йоктырган дигән шик булган хасталарга медицина ярдәме күрсәтүгә әзерлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «көчле респиратор вируслы чир, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы чире COVID-19, хастаханәдән тыш пневмония йоктырган дигән шик булган хасталар өчен Татарстан Республикасы медицина оешмаларында вакытлыча маршрут төзүне оештыру турында» 2020 елның 3 апрелендәге 593 номерлы боерыгы чыгарылды.

Койкаларга ихтыяҗны исәпләү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган нормативлар нигезендә башкарыла.

Яңа коронавирус йогышлы чире таралуны булдырмау өчен республикада провизор госпитальләре системасы оештырылды, алар базасында хасталарны башлангыч бүлү һәм аларга диагноз кую башкарыла (тикшерү, COVID-19 га лаборатор тикшерү, инструменталь тикшерүләр: күкрәк читлеге органнарына компьютер томографиясе ясау, рентгент тикшеренүе уздыру һ.б.). Коронавирус йогышлы чире булу буенча лаборатор статусны исәпкә алып һәм медицина күрсәтмәләре булган очракта хасталар санитар автотранспортта профиле үзгәртелгән медицина оешмаларына юллана.

Эпидемия чорында госпитальләрне этаплы рәвештә эшләтә башлау планы нигезендә барлык муниципаль районнарда 5 территориаль округта 55 медицина

оешмасының эше оештырылган. Халык санын истә тотып COVID-19 чирен йоктырган хасталар өчен 2 577 койка сакланды, шул исәптән аларның 902 сенә кислород бирү җайланмалары куелган. 2020 елда медицина оешмаларында койкаларны өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдим иткән нормативка (5 552 койка) туры китереп үзгәртеп кору башкарылды. Үзгәртеп кору өчен әзерләнгән медицина оешмаларында авыруларны йөртү маршрутлары схемалары һәм эпидемиологик вазгыять катлауланып киткән очракта тиз арада куллана башлау өчен план төзелде. Медицина оешмаларының эш юнәлешен үзгәртеп кору өстәмә койкалар кую кирәклеге турында мәгълүмат алынганнан соң 2 сәгать эчендә башкарыла.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Оператив штабы диагностикалау, дарулар, аппаратура, госпитальләр ихтыяҗлары өчен медицина билгеләнешендәге эшләнмәләрнең стратегик запасын булдыра. Көн саен Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарында COVID-19 диагнозлау чараларының (транспорт, зондлар) һәм шәхси саклану чараларының (битлекләр, респираторлар, йогышлы чирдән саклый торган кием) булуын һәм аларга ихтыяҗны тикшерү уздырыла. COVID-19 чирен йоктырган хасталарга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары кирәкле дарулар, җиһазлар, медицина эшләнмәләре белән тәэмин ителгән.

COVID-19 чире йоктырган дигән диагноз расланган очракта, хаста кешедә чирнең клиник күрсәткечләре булмаса яисә чир җиңел узса дәвалану өйдә алып барыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 октябрендәге 2805-р номерлы боерыгы нигезендә Россия Федерациясе субъектларына COVID-19 чирен дәвалауга акча бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Яңа коронавирус йогышлы чирен (COVID-19) йоктырган хасталарны ташламалы дарулар белән тәэмин итү турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 1887 номерлы боерыгы нигезендә амбулаторияләрдә дәвалана торган авыруларга дарулар түләүсез бирелә. Дарулар 2020 елның 13 ноябреннән бирелә башлады. Авыруларга аларны өйләренә волонтерлар китерә.

***«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты***

*«Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты*

«Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыруга 2020 елда 376,2 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән 73,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 303,1 млн сум бүлеп бирелде.

Проект кысаларында 2020 елда:

9 фельдшерлык-акушерлык пункты Актаныш, Алексеевск, Әлки, Балтач, Кукмара, Балык Бистәсе, Сарман, Биектау, Питрәч муниципаль районнарында) төзелде;

санитар авиациянең 193 очышы башкарылды, санитар авиацияне кулланып 184 кеше эвакуацияләнде (2019 елда – 150 санитар авиация очышы, 146 пациент эвакуацияләнде);

68 медицина оешмасының 84 хастаханә бүлекчәсе башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасының яңа моделен төзүдә һәм тиражлауда катнаша;

1 483 кешегә профилактика чаралары күрсәтелә;

100 кешедән ким булган торак пунктларда яшәүче республика гражданнарын диспансерлаштыруны уздыру өчен 4 «Мобиль поликлиника» медицина комплексы эшләвен дәвам иттерә;

диспансерда тикшерү үткәрү тәртибе үзгәрде: 18 – 39 яшьлек затлар – өч елга бер тапкыр, 40 – 99 яшьлек затлар – ел саен. 2020 елда 1432 кеше тикшерелде.

*«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты*

2020 ел проекты кысаларында Кан әйләнеше системасы авырулары регистры эшләнде һәм файдаланыла башлады. Бу – баш миендә кан әйләнеше бик нык бозылган, миокард инфаркты кичергән, шулай ук аортокоронар шунтирование, кан тамырларына стентлау белән ангиопластика һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары буенча катетер абляциясе кичергән, авырый башлаган вакытыннан ташламалы дарулар белән амбулатория шартларында бер ел дәвамында тәэмин ителгән авыруларның белешмәләр базасы (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасында кан әйләнеше системасы авырулары регистрын кертү турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 163 номерлы боерыгы).

Баш миендә кан әйләнеше бик нык бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерү максатларында «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» һәм Казан шәһәренең «7 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында төбәк кан тамырлары үзәкләре оештырылды (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 2 мартындагы 377 номерлы боерыгы), Казан шәһәрендә кан тамырларын башлангыч дәвалау буенча ике үзәк («Сугыш ветераннары госпитале» һәм «18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында) ачылды.

Йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлүчеләр санын киметү һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары белән авыручыларга ярдәмнең сыйфатын яхшырту максатларында 2020 елда «Кабат инсульт булу куркынычын профилактикалау» модуле кертелде. Ул инсульт кичергән авыруларның сәламәтлеген контрольдә тоту максатларында эшләнде.

«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» республика проектының «Портавита» йогышлы булмаган хроник авырулы пациентларны үзәкләштерелгән мониторинглау системасын гамәлгә ашыруда 39 медицина оешмасы, Татарстан Республикасында яшәүче 123 650 пациент катнаша: «Йөрәк-кан тамырлары авыруларын кисәтү» модулендә 115 214 авыру; «Антикоагуляция» модулендә 4 937 авыру; «Шикәр авыруы» модулендә 3 217 авыру; «Хроник обструктив үпкә

авырулары» модуленә 52 пациент; «Кабат инсульт куркынычын профилактикалау» модулендә 230 авыру катнаша.

«Татарстан Республикасында йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» проекты кысаларында 2020 елда «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе каршындагы төбәк кан тамырлары үзәге, Чаллы шәһәренең «Казан шәһәренең 5 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе», Казан шәһәренең «2 номерлы клиник хастаханәсе», «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре каршындагы кан тамырларын башлангыч дәвалау буенча 3 бүлекчә ачылды. 309 берәмлек медицина җиһазы сатып алынды һәм куелды.

COVID-19 чире таралу нәтиҗәсендә килеп чыккан эпидемиологик вазгыять шартларында 2020 елда кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны 100 мең кешегә исәпләгәндә 657,7 очракка арткан (2019 елда – 537,9 очрак). 2020 елда амбулатория-поликлиника һәм стационар шартларында медицина ярдәме күрсәтүне, халыкны диспансерлаштыру һәм профилактика тикшеренүләре уздыруны туктатып торырга мәҗбүр булу йөрәк-кан тамырлары авыруларының яңа очракларын һәм аларның килеп чыгу куркынычы янаган авыруларны ачыклауның, шулай ук профилактика чаралары уздыру мөмкинлегенең кискен кимүенә китерде.

*«Онкология авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты*

2020 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының «Онкология авыруларына каршы көрәшү» ярдәмче программасы чараларын үтәүгә федераль бюджеттан 871,3 млн сум бүлеп бирелде.

Әлеге проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә яңа шешләрдән үлүчеләр саны 100 мең кешегә 186,8 очракка кадәр кимегән, бу исә 2019 елгы күрсәткечтән 0,74 процентка кимрәк (2019 елда – 188,2 очрак).

«Онкология авыруларына каршы көрәшү» проекты кысаларында 2020 елда

«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җирлегендә амбулатор онкологик ярдәм үзәге ачылды 1 293 пациентка өенә барып ярдәм күрсәтелде, 46 химиотерапия сеансы уздырылды), 15 берәмлек җиһаз сатып алынды һәм куелды.

*«Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» төбәк проекты*

Проект чараларын үтәүгә 2020 елда 1 377,9 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан – 778,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 599,6 млн сум тотылды.

Проект кысаларында 2020 елда:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Симуляция үзәгендә 185 белгеч перинаталь, неонатология һәм педиатрия өлкәсендә әзерлек узды;

38 балалар поликлиникасы һәм поликлиника бүлекләре яңадан җиһазландырылды, 107 берәмлек җиһаз кайтартылды;

республиканың 32 балалар хастаханәсендә балаларга уңайлы шартлар тәэмин итү максатларында оештыру-планлаштыру каралары хәл ителде, шулардан 1 объект – капиталь ремонт уздыру хисабына;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында балалар онкологиясе, гематологиясе һәм хирургиясе үзәген төзү эшләре башланды (гомуми мәйданы 17 090 кв. метр булган, 100 койкага исәпләнгән алты катлы бина). 2020 – 2021 елларда төзелешкә 2 204,5 млн сум тотылды (федераль бюджеттан – 1 184,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 020,5 млн сум, проект-смета документларын эшләүне исәпкә алып);

балалар табиб – уролог-андрологлары тарафыннан 39 650 малай (еллык планның 1046,6 проценты), табиб – акушер- гинекологлар тарафыннан – 35 564 кыз (еллык планның 99,2 проценты) карап тикшерелде;

бала тудыру сертификатлары түләнде: 1 нче талон – 36 259 берәмлек, 2 нче талон – 38 895 берәмлек, бала тудырганда аналарга 39 559 тапкыр ярдәм күрсәтелгән.

*«Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты*

Проект кысаларында 200 елда:

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында табиблар белән тәэмин ителеш – 10 мең кешегә 35,0, урта медицина хезмәткәрләре белән тәэмин ителеш – 10 мең кешегә 91,0 тәшкил итте (оператив мәгълүматлар буенча);

амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтү (алыштыру коэффициенты 1,2 булганда физик затлар тарафыннан) бүлекчәләрендә табиблар белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 84,4 % тәшкил итте;

амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтү (алыштыру коэффициенты 1,2 булганда физик затлар тарафыннан) бүлекчәләрендә урта медицина персоналы белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 100 процент тәшкил итте;

43 926 табиб югары медицина белемле белгечләргә өзлексез медицина белеме бирү системасына җәлеп ителгән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрлар кытлыгын бетерү максатларында белгечләр җәлеп итү буенча актив эш алып барыла һәм түбәндәге чаралар һәм программалар гамәлгә ашырыла:

югары медицина белеме бирү оешмаларына керү өчен 341 максатчан юллама максатчан кабул итү квоталары буенча бирелде;

5 кеше муниципаль берәмлекләр өчен табибларны адреслы әзерләү социаль программасы кысаларында белгечлек программалары буенча укырга җибәрелде;

2014 елдан «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина факультетында максатчан акча хисабыннан 60 кеше «дәвалау эше» белгечлеге буенча укый. Белгеч аккредитация узганнан соң, уку йортын тәмамлаучылар Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсенең башлангыч звеносында табиб-терапевт буларак кимендә 3 ел эшләргә тиеш булачаклар;

бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве 90 табибка һәм 20 фельдшерга бирелгән;

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең грантлар бирү программасы буенча республиканың медицина оешмаларына 125 белгеч эшкә урнаштырылды.

*«Бердәм дәүләт мәгълүмати сәламәтлек саклау системасы (ЕГИСЗ) нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм цифрлы контур булдыру» төбәк проекты*

2020 елда төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыруга 529,1 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән 428,6 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 100,5 млн сум бүлеп бирелгән.

Татарстан Республикасында 104 медицина оешмасы «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсендә электрон хезмәт күрсәтү» (алга таба – ТР ЭСС БДМС) бердәм дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ТР ЭСМ БДМС системалары белән берләштерелгән автоматлаштырылган системасын кулланалар. 2020 елда Татарстан Республикасы медицина оешмаларында табибка кабул итүгә 13,5 млн электрон язылу очрагы теркәлгән (2019 елда – 18,1 млн).

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре порталында кара-каршы элемтә системасы гамәлгә ашырылды һәм куллануга кертелде. Табиб килеп киткәннән соң икенче көнне һәр кешегә гади итеп төзелгән сораштыру кәгазе җибәрелә, анда 5 баллы шкала буенча медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын һәм шартларын бәяләргә тәкъдим ителә.

Яңа коронавирус чире таралуны кисәтү чараларын үз вакытында кабул итү максатларында 2020 елда медицина мәгълүмати системаларында түбәндәге модульләр файдалануга кертелде:

кан әйләнеше системасы авырулары регистры – кан әйләнеше системасы авырулары белән чирләгән пациентларны исәпкә алу һәм аларны хәлен күзәтеп тору;

пульмо-регистр – вируслы пневмония кичергән пациентларны күзәтеп тору;

COVID-19 белән авыручылар, йөкле хатыннар регистры;

Дәүләт хезмәтләре һәм функцияләре бердәм (федераль) порталы аша пациентларны коронавирус йогышлы чиреннән вакциналауга язу.

2020 елда электрон медицина документлары – пациентларның медицина карталары архивын тутыру эше дәвам иттерелде.

«Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе автоматлаштырылган системасының йөрәк-кан тамырлары авырулары федераль вертикаль интеграцияләнгән медицина мәгълүматы системасы (ВИММС) белән мәгълүмати хезмәттәшлеге гамәлгә ашырылды.

*«Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты*

2020 елда дәваланган чит ил гражданнары саны 33 149 кеше тәшкил итте (план – 10 600 кеше), бу хезмәт өчен 76,9 млн сум акча алынды.

***«Актив озын гомер» флагман проекты***

Сәламәтлек саклау өлкәсенең өлкән яшьтәге гражданнарга кагылышлы төп бурычы – аларның актив яшәеш чорын озынайту һәм сәламәтлеген ныгыту.

Махсуслаштырылган гериатрия ярдәмен үстерү – өлкәннәргә медицина ярдәмен оештыруның мөһим өлеше булып тора, аның максаты – өлкән яшьтәге кешеләргә, аларның физиологик яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, медицина ярдәме күрсәтү.

Нәтиҗәле эшләү өчен тематик һәм массакүләм пропаганда чараларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү зур әһәмияткә ия. Шушы максаттан чыгып өлкән яшьтәге гражданнарның авырулары турында тематик мәгълүмати-күрсәтмә материаллар тарату, геронтология, гражданнар сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләренә багышланган пропаганда видеофильмнары күрсәтү оештырылды.

«Актив озын гомер» һәм «Сәламәтлек зонасы» дигән ел саен уздырыла торган махсуслаштырылган күргәзмәләр кысаларында хроник йогышлы авыруларны профилактикалау буенча мәгълүмати-мәгърифәти әдәбият күргәзмәсе, видеороликлар күрсәтү, шулай ук гигиена тәрбиясе һәм дәвалау физкультурасы буенча консультацияләр оештырыла.

«Җәмгыять сәламәтлеге һәм медицина тернәкләндерү республика үзәге» (алга таба – Үзәк) дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең тернәкләндерү һәм спорт медицинасы кафедрасы белгечләре коллективы тарафыннан иртәнге гигиена гимнастикасының якынча комплексы, шулай ук төрле хроник авыруларны булдырмау өчен күнегүләр комплексы эшләнде. Үзәк даими төстә йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларның көчәюе куркынычына каршы көрәшү мәсьәләләре буенча лекторийлар уздыра.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы кешеләрнең актив озын гомергә омтылышында мөһим элемент булып тора. Республика халкына социаль хезмәт күрсәтү системасының хәзерге торышы өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты белән идарә итү өлкәсендәге уңай үзгәрешләр хас. Республикада социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга 117 хезмәт күрсәтү оешмасы, шул исәптән дәүләтнеке булмаган 26 оешма күппрофильле ярдәм күрсәтә. Ел саен әлеге учреждениеләр челтәре тарафыннан 204 меңгә якын гражданга хезмәт күрсәтелә.

Республикада ялгыз һәм ялгыз яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннары (алга таба – Бөек Ватан сугышы ветераннар), һава һөҗүменә каршы оборона объектларында эшләгән, «Камалыштагы Ленинградта яшәгән» билгесе белән бүләкләнгән, 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә 6 ай эшләгән авыл кешеләренә өйләренә килеп социаль ярдәм күрсәтү хокукы бирелде. 2020 елда республикада 2 407 Бөек Ватан сугышы ветеранына, шул исәптән 2 393 тыл хезмәтчәненә, шулай ук «Камалыштагы Ленинградта яшәгән» билгесе белән бүләкләнгән 14 кешегә социаль ярдәм өйләренә килеп түләүсез күрсәтелде.

2015 елдан муниципаль дәрәҗәдә 80 яшен тутырган һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз һәм ялгыз яшәүче кешеләрнең тормыш шартларын тикшерү буенча ведомствоара профилактика чарасы уздырыла. 2016 елдан бу эш 70 яше тулган кешеләргә, шулай ук I һәм II төркем инвалидларга карата да башкарыла. 2020 елда социаль хезмәткәрләр йорт саен (фатир саен) йөреп 115 мең кешенең хәлен белештеләр. Тикшерүләр барышында көнкүреш приборларын, газ җиһазларын,

мичләрне, электр җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләү буенча, янгын вакытында саклану кагыйдәләре буенча, социаль мошенниклыклардан саклану ысуллары турында инструктажлар уздырыла, ашыгыч ярдәм күрсәтүче хезмәтләрнең телефоннары теркәлгән белешмәлекләр таратыла, өйдә хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлар исемлеккә теркәлә һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелә.

2020 елда Татарстан Республикасында Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт дәвамында тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру 13 муниципаль районда ( Арча, Әлмәт, Алабуга, Балык Бистәсе, Биектау Зеленодольск, Кукмара, Түбән Кама, Саба, Спас, Тукай, Чистай муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә) алып барылды. Пилот проектны гамәлгә ашыруда социаль хезмәт күрсәтү буенча 26 учреждение (халыкка социаль ярдәм күрсәтү буенча 13 комплекслы үзәк, картлар һәм инвалидлар өчен 8 йорт-интернат, 5 психоневрология интернаты). Озак вакыт дәвамында тәрбияләү системасына 3 682 кеше кертелгән (республикадагы социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ затларның 16,1 проценты), шулардан 1910 кешегә – өйдә, 159 кешегә ярым стационар рәвештә, 1613 кешегә стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтелә.

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсенә стационарларга алмашка технологияләр кертү һәм өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту, аларны карау максатында түбәндәге проектлар гамәлгә ашырыла:

Өлкән яшьтәге гражданнарны гаиләләргә тәрбиягә бирү (2020 елда – 37 муниципаль районда 38 гаилә);

«Өйдәге шифаханә» (101 кешегә хезмәт күрсәтелгән);

«Тәрбияләү мәктәбе» (сәламәтлек саклау оешмаларының медицина хезмәткәрләрен җәлеп итеп, якыннарына өлкән яшьтәге кешеләрне карау күнекмәләре бирелә (1 791 кеше);

«Авыру багучы» (авыру багучылар хезмәтеннән 775 кеше файдалана).

«Уңайлы мохит» программасын гамәлгә ашыру кысаларында республикада мәгълүматлар банкын һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан файдалану мөмкинлеге картасын формалаштыру һәм үстерү буенча программа продукты булдырылды һәм сәнәгатьтә файдалануга кертелде. Файдалану мөмкинлеге картасына 6 897 объект буенча мәгълүмат бирелә.

«Ачык Татарстан» проекты кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында «Халык контроле» проектының «Һәркем файдалана ала торган мохит» бүлеге хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы кешегә теләсә кайсы объектның уңайлылыгы яисә киресенә уңайсызлыгы турында хәбәр итәргә һәм дәүләт органы яисә муниципаль орган кабул иткән карарның сыйфатын бәяләргә мөмкинлек бирә.

**Хезмәт базары, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм социаль яклау**

Төрле тармакларны цифрлы нигезгә кору һәм санитар-эпидемиологик вазгыять 2020 елда хезмәт базарында үзгәртеп коруларны тизләтте. 2020 елның 9 апрелендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә гаризалар гражданнар тарафыннан «Россиядә эш» гомумроссия вакансияләр базасы мәгълүмати-аналитика системасында шәхси кабинет аша электрон формада тутырыла (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 8 апрелендәге 460 номерлы боерыгы нигезендә).

2020 елда халыкны эшкә урнаштыру хезмәте органнарына 255,1 мең кеше мең кеше төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән, шул исәптән 159,9 мең кеше эш эзләүчеләр сыйфатында исәпкә алынган. 61,1 мең кешегә эш бирелгән, шуларның 52,7 меңе – эшсез граждан.

2020 елның 1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 38,7 мең кеше, ягъни эшче көчләр санының 1,9 проценты теркәлгән (2019 елның 1 гыйнварына – 0,54 процент).

**Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе**




2020 ел башы белән чагыштырганда, эшсезләр составында беренче тапкыр эш эзләүче гражданнар өлеше – 19,4 процентка (2020 елның 1 гыйнварына – 3%), 16 – 29 яшьлек яшьләр өлеше 22,2 процентка (2020 елның 1 гыйнварына – 15,12%) арткан. Үз теләге белән эштән киткән кешеләр өлеше 60,15 процентка (2020 елның 1 гыйнварына – 67,5 %) һәм эштән азат ителү сәбәпле эштән китүчеләр өлеше 4,9 процентка (2020 елның 1 гыйнварына 14,8 %), пенсия яшенә җитеп килүче гражданнар саны 11,9 процентка (2020 елның 1 гыйнварына 23,9 %), инвалидлар өлеше 3,3 процентка (2020 елның 1 гыйнварына 11,3%) кимегән.

2021 елның 1 гыйнварына эш бирүчеләр тарафыннан 46,8 мең вакансия тәкъдим ителгән, хезмәт базарында киеренкелек коэффициенты 1 вакансиягә 0,83 кеше тәшкил иткән (2020 елның 1 гыйнварына – 1 вакансиягә 0,27 кеше).

Республика буенча эшсезлекнең уртача дәвамлылыгы 2021 елның беренче гыйнварына 4,77 ай тәшкил итте (2020 елның 1 гыйнварына – 4,04 ай).

2020 елда гражданнарга эшкә урнашырга ярдәм итә максатларында халыкны эшкә урнаштыру органнары тарафыннан 353 вакансия һәм өйрәтү өчен эш урыннары ярминкәсе уздырылды, анда 1 328 эш бирүче һәм 15 уку-укыту учреждениесе катнашты. Ярминкә йомгаклары буенча 1 439 кеше эшкә урнаштырылган.

2016 елдан башлап инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре оештырган предприятиеләргә инвалидлар өчен гамәлдәге эш урыннарын саклап калуга субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтелә. 2020 елда программада Казан, Әлмәт, Алабуга, Чистай шәһәрләрендә эшчәнлек алып баручы 6 предприятие катнашты. 316 инвалидка хезмәт өчен түләүгә тотылган чыгымнар капланды.

«Инвалидларга һәм социаль ярдәмгә аеруча мохтаҗ булган гражданнарга эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган инвалидлар һәм гражданнар өчен эш урыннары резервлау тәртибен раслау турында» 2007 елның 18 маендагы 194 номерлы боерыгы нигезендә 2020 елда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен 13 эш урыны резервланды.

Әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эшкуарларда инвалидларны урнаштыру өчен эш урыннары квоталау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары нигезендә 2020 елда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен 1029 эш урынына квота бирелде, аларга 365 инвалид эшкә урнаштырылды.

Республикада социаль түләүләр системасы 85 төр түләүдән: 32 төр федераль һәм 53 төр республика чараларыннан тора. 2020 ел йомгаклары буенча адреслы чаралар 820,0 мең кешегә бирелгән. Адреслы чараларны финанслау күләме 8,3 млрд сум тәшкил итте.

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарын үтәү йөзеннән, аз керемле гаиләләргә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелә. 2020 елда 9 623 социаль контракт төзелде, дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә тотылган акча күләме 421,9 млн сум тәшкил итте.

2020 елда 32 571 граждан социаль контракт нигезендә дәүләттән социаль ярдәм алды, бу исә социаль ярдәм алган гражданнар гомуми санының 99,5 процентын тәшкил итә.

**Социаль хезмәтләрне үстерү**

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасына социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары белән беррәттән

дәүләтнеке булмаган оешмалар (коммерциячел һәм коммерциячел булмаган) да кертелә. Аларга, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларга куелган таләпләргә туры килгәндә, социаль хезмәт күрсәтергә хокук бирелә.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе турында» 2014 елның 23 декабрендәге 1012 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе расланды. Ул Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эшкә урнаштыру һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган (https://mtsz.tatarstan.ru/reestr-postavshchikov-sotsialnih-uslug.htm). Шулай ук аны булдыру һәм алып бару тәртибе расланды, аның буенча Реестрга кертелү оешмаларга шартнамә нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы кысаларында гражданнарга күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен хезмәт күрсәтүчеләрнең чыгымнарын раслаган документлары булган очракта гына компенсация алырга мөмкинлек бирә.

2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына 117 социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, шул исәптән дәүләтнеке булмаган 26 оешма кертелгән, аларның 12 се өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны, 8 е сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләрне тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтә, 5 се өлкән яшьтәге гражданнарга өйләрендә, 1 се авыр тормыш хәлендә калган балаларга социаль хезмәт күрсәтә. Дәүләтнеке булмаган оешмалар өлеше 18,2 процент тәшкил итте (2019 елда – 16,9 %). 2020 елда дәүләтнеке булмаган оешмалар 10 524 гражданга хезмәт күрсәтте, 244,8 млн сумлык компенсация түләнде.

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсен җайга салучы норматив хокукый документлар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы сайтында урнаштырылган (https://mtsz.tatarstan.ru/normativnie-dokumenti-v-sfere-sotsialnogo.htm).

Татарстан Республикасы халкына дәүләт хезмәте һәм социаль әһәмиятле хезмәтләр күрсәтү ачыклыгын һәм аның сыйфатын күтәрүне тәэмин итү өчен социаль өлкәгә мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланышка кертү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора. Социаль яклауның 10 хезмәте тулысынча электрон төргә күчерелде:

мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-анадан алына торган түләүнең бер өлешенә компенсация билгеләү (төп компенсация);

мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-анадан алына торган түләүнең бер өлешенә гражданнарга аларның керемнәреннән чыгып бирелә торган өстәмә компенсация билгеләү;

балага айлык пособие билгеләү;

пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү;

күп балалы гаиләләрдәге укучы балаларга транспортта йөрүгә айлык субсидия билгеләү;

18 яше тулмаган өч яисә аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә торак бина өчен һәм коммуналь түләүләргә субсидия-ташлама билгеләү;

18 яше тулмаган өч яисә аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә 6 яше тулмаган бала өчен дару алуга субсидия билгеләү;

инвалидларга торак өчен һәм коммуналь хезмәткәргә түләүләргә субсидия-ташлама билгеләү;

торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия;

беренче бала туу (яисә уллыкка/кызлыкка алу) белән бәйле айлык түләү.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Хезмәтләр күрсәтү порталында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә түбәндәге дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылды:

хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат;

гражданнарга аларга кирәкле эш табуда ярдәм итү;

эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда ярдәм итү;

эш бирүчеләргә үзләренә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда ярдәм итү;

Татарстан Республикасында эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

түләүле иҗтимагый эшләр оештыру;

шул исәптән башка җирдә белем бирүне дә кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү;

эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә ярдәм итү.

2020 ел йомгаклары буенча социаль яклау органнарына тапшырылган 1,4 млн гаризаның 1,2 миллионы гражданның шәхси катнашыннан башка электрон рәвештә бирелгән.

## Үсеш нигезе буларак мәгариф

*Мәктәпкәчә белем бирүнең үсеше*

Татарстан Республикасында балаларга мәктәпкәчә белем бирү төрле типтагы 2 008 мәгариф оешмасында бирелә, шуларның 1 744е мәктәпкәчә мәгариф оешмалары, 264е структурасында мәктәпкәчә төркемнәре булган мәктәпләр. Мәктәпкәчә белемне 220 мең бала ала. Мәктәптә белем алу мөмкинлеге республикада уртача 94,4 % тәшкил итә, шул исәптән 98 проценты – 3 яшьтән өлкәнрәк балалар өчен. 36 муниципаль берәмлектә мәктәпкәчә белем бирү 100 процентка тәэмин ителгән.

Халыкның туган телдә мәктәпкәчә белем алу ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында республикада татар телендә белем һәм тәрбия бирелә торган 749 балалар бакчасы, 9 – мари телендә белем һәм тәрбия бирелә торган, 46 – чуваш телендә белем һәм тәрбия бирелә торган, 13 – удмурт телендә, 9 мари телендә, 1 мордва телендә белем һәм тәрбия бирелә торган балалар бакчасы эшләп килә.

Республиканың 519 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында компенсация юнәлешендәге төркемнәр оештырылды, аларга үсешендә төрле кимчелекләр булган

(сөйләм, ишетү, күрү, терәк-хәрәкәт аппараты, интеллект) 16,5 мең бала йөри. Катнаш юнәлешле 61 төркемдә сәламәт балалар белән берлектә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 162 бала йөри. 4,2 мең бала тубинтоксикацияле, еш авыручы, аллергия, нефрология һәм башка авырулары булган балалар өчен сәламәтләндерү төркемнәренә йөри.

Мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив рәвешләре дә үсештә. Күпбалалы гаиләләр базасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре буларак оештырылган 15 мәктәпкәчә белем бирү буенча гаилә төркемнәре эшләп килә. 1,7 меңнән артык бала төрле юнәлештәге аз вакытка исәпләнгән төркемнәргә йөри: иртә үсеш, мәктәпкә әзерлек, физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен.

Республикада мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча эшчәнлек алып баручы хосусый 24 мәгариф оешмасы һәм 10 шәхси эшмәкәр бар. Дәүләтнеке булмаган балалар бакчаларында 3 меңнән артык бала тәрбияләнә. 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан хосусый балалар бакчаларында мәктәпкәчә мәгариф программаларын гамәлгә ашыруга бирелә торган субсидияләргә 131,2 млн сум бүлеп бирелде. Субсидияләр 15 дәүләтнеке булмаган мәктәпкәчә мәгариф оешмасына, мәктәпкәчә төркемнәре булган 6 хосусый мәктәпкә һәм мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы 10 шәхси эшкуарга бирелде.

*Гомуми белем бирүнең үсеше*

2020 елда Татарстан Республикасында 1 403 гомуми белем бирү оешмасы, шул исәптән 1 316 гомуми белем бирү мәктәпләре һәм мәктәп-интернатлар, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 53 мәктәп һәм мәктәп-интернат, 2 шифаханә-мәктәп-интернат, тәртибендә тайпылышлар булган балалар өчен 1 мәктәп, 10 кичке мәктәп, 19 дәүләтнеке булмаган мәктәп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 1 мәктәбе һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 1 мәктәбе эшли.

Мәгариф системасында педагогларның һөнәри үсешенә аерым зур роль бирелә. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан педагогларны аттестацияләүнең төбәк системасы укытучылар корпусы әзерлеген камилләштерү һәм Татарстан Республикасында уку-укыту сыйфатын яхшырту бурычлары белән бәйле рәвештә реформалаштырылды, эш бирүчеләрнең педагогик кадрларны эшкә алу, аттестациягә әзерләү, квалификацияләрен күтәрү вакытында билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен җаваплылыгын арттыру чаралары күрелде.

2020 елда эпидемиологик вазгыятькә бәйле рәвештә бердәм дәүләт имтиханы (алга таба – БДИ) рәвешендәге дәүләт йомгаклау аттестациясе 11 сыйныфта һәм мәҗбүри рус теле һәм математика фәннәре буенча 9 сыйныфта төп дәүләт имтиханы уздырылмый. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, төп база дәрәҗәсендәге математика буенча БДИ дәүләт йомгаклау аттестациясенең имтихан фәннәре исемлегеннән төшереп калдырылды. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте тарафыннан аттестатларны БДИ бирмичә генә тапшыру турында кабул ителгән карар нигезендә урта гомуми белем турындагы аттестатлар 11 сыйныфны тәмамлаучыларның барысына да тапшырылды. Урта гомуми белем турындагы аттестат 11 сыйныфны тәмамлаган 16 907 укучыга һәм төп

гомуми белем турындагы аттестат 9 сыйныфны тәмамлаган 37 366 укучыга тапшырылды.

Сайлап алынган фәннәр буенча БДИны югары уку йортларына керергә ниятләгән 11 сыйныф укучылары гына бирде.

2020 елда БДИ буенча урта балл 2018 һәм 2019 еллар белән чагыштырганда 8 фән буенча (рус теле, физика, тарих, география, француз теле, җәмгыять белеме, кытай теле һәм әдәбияты) артты, информатика и мәгълүмат-коммуникация технологияләре буенча 2,35 баллга, биология буенча 1,62 баллга кимеде. Немец теле буенча балл байтакка – 10,6 баллга кимүе күзәтелде.

Татарстан Республикасы буенча БДИ нәтиҗәләре
(уртача балл)

| Фән | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|
| Рус теле | 74,25 | 74,91 |
| Математика (профильле/ база) | 64,43/4,48* | 59,95/ төп дәрәҗәдәге |
| Җәмгыять белеме | 61,25 | 63,72 |
| Физика | 60,32 | 60,30 |
| Биология | 58,53 | 56,66 |
| Химия | 64,95 | 60,36 |
| История | 59,26 | 64,61 |
| Инглиз теле | 80,43 | 77,01 |
| Информатика һәм МКТ | 69,60 | 67,01 |
| Әдәбият | 71,20 | 70,62 |
| География | 65,10 | 68,85 |
| Немец теле | 79,17 | 67,81 |
| Француз теле | 65,20 | 71,94 |
| Испан теле | – | 87,00 |
| Кытай теле | – | 77,00 |

*Төп дәрәҗәдәге математика 5 баллы шкала буенча бәяләнде.

2020 елда БДИ тапшыручыларның 239ы йөз балл җыйды, шуларның 227се – 2019/2020 уку елында мәктәпне тәмамлаучылар. 2019 ел белән чагыштырганда йөз балл җыючылар саны 40 кешегә артты. 205 кеше1 фән буенча 100 балл җыйды, шуларның 12 се мәктәпне узган елларда тәмамлаучылар һәм 193 е мәктәпне 2020 елда тәмамлаган укучы. 2019/2020 уку елында мәктәп тәмамлаган 17 кеше 2 фәннән 100 балл җыйды (2019 елда – 10 кеше).

Республикада дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру процедураларының ачыклыгын һәм аңлаешлылыгын тәэмин итү максатларында җәмәгать күзәтүе системасы оештырылды. 2020 елда җәмәгать күзәтүчеләре буларак Татарстан Республикасының 139 югары уку йорты студентына аккредитация бирелде.

Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы мәктәп укучылары командасы Мәскәү һәм Санкт-Петербург командаларыннан гына калышып, Россия Федерациясендә 3 урынны алды. 2020 елда Татарстан Республикасы командасы Идел буе федераль округы укучылары арасында

интеллектуаль олимпиада 4 программа төре буенча җиңү яулады: «Программалаштыру», «Робототехника», «Уйлап табу мәсьәләләрен чишү» һәм «Нәрсә? Кая? Кайчан?» интеллектуаль уены. Халыкара олимпиадалар йомгаклары буенча 2020 елда республика мәктәпләре укучылары:

Нидерландта узган (онлайн форматта) Математика буенча IX Европа хатын-кызлар олимпиадасында 3 алтын һәм 1 көмеш медаль;

Сингапурда узган XXXII Информатика буенча халыкара олимпиадада алтын медаль;

Болгариядә узган Информатика буенча халыкара турнирда 2 алтын, 4 көмеш һәм 8 бронза медаль.

2020 елда «Брайль ысулы белән язылган эссе» халыкара конкурсында «Казанның сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 172 номерлы мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе укучысы бүләк алды.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен «Бертигез» Халыкара конкурс проектында «Казанның Е.Г. Ласточкина исемендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укучысы 1 нче урынны алды.

2020 елда республикада инклюзив белем бирүне үстерү өчен шартлар һәм инновацияле механизмнар булдыру эше алып барылды. Республиканың гомуми белем бирү оешмаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән 12 меңнән артык бала укый. Башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча даими төстә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары эшли һәм үсә. Җайлаштырылган төп мәгариф программалары 7 868 бала өчен 53 мәгариф оешмасы базасында (38 учреждение – акыл үсеше ягыннан тайпылышлар булган, 5 – күзләре начар күрүче балалар өчен, 5 – ишетмәүче, начар ишетүче балалар өчен, 4 – терәк-хәрәкәт аппаратында тайпылышлар булган балалар өчен, 2 – сөйләмнәрендә нык тайпылышлар булган балалар өчен) һәм укучыларның гомуми саны 220 кеше тәшкил иткән 2 шифаханә-мәктәп-интернатта гамәлгә ашырыла.

Моннан тыш, республикада инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укытуның төрле рәвешләре, шул исәптән хосусый укыту да үстерелә. 2 меңгә якын бала, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар учреждениеләрендә тәрбияләнүче балалар да, өйдә белем ала. Укучыларга бер үк вакытта табиблар, логопед, психологлар, медицина хезмәткәрләре, массажчылар һәм социаль педагоглар ярдәм күрсәтә. Ишетү, күрү, сөйләм органнары, терәк-хәрәкәт аппараты, акыл үсеше ягыннан тайпылышлары булган балаларны укыту буенча уку-укыту планнарының 15 тән артык варианты гамәлгә ашырыла.

2020 уку елы дәвамында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән һәм акылга зәгыйфь (интеллектуаль яктан тайпылышлары булган) балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертү 183 гомуми белем бирү мәктәбе базасында алып барыла. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга уңайлы даирә булдыру өчен мөмкинлекләр тудырылган. Аутизм белән авыручы балаларга комплекслы ярдәм системасын булдыру эше алып барыла.

2017 елдан «Ресурс классы» моделе буенча 5 гомуми белем бирү мәктәбе билгеләнде, анда аутизм белән чирләүче 48 бала укый. Болар: Казан шәһәре Мәскәү районының «Кайбер фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 65 номерлы урта гомуми белем бирү татар-рус мәктәбе, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «168 номерлы соматик авырулы балалар өчен озайтылган көн төп гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Идел буе районының «97 номерлы рус-татар гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Совет районының «156 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе», Әлмәт шәһәренең «21 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе – «Дай 5» мәгариф үзәге».

«Ресурс классы» моделе теләсә кайсы балага белем алу хокукын тәэмин итә һәм һәр укучының ихтыяҗына туры килә торган укуны аны чикләми торган мохитта оештырырга мөмкинлек бирә. Балалар психолог-медик-педагоглар комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә төзелгән индивидуаль уку планы нигезендә белем ала.

Республикада «Яндекс.Лицей» мәгариф проектын тормышка ашыру дәвам итә. Ул 8 – 9 сыйныф укучыларын дөньяда иң популяр һәм еш кулланыла торган программалаштыру телендә (Питон) эшләргә өйрәтүгә юнәлдерелгән. 2020 елда проект 25 торак пункттагы 14 көндезге мәйданчык базасында гамәлгә ашырылды, аларда 32 укытучы укытты.

«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе базасында «Ачык мәктәп 2035» мәгариф платформасы (алга таба – платформа) гомуми белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге платформа белән эшләгәндә методик ярдәм күрсәтү өчен төзелде. Платформада 1-11 сыйныфлар өчен мәктәп программасы нигезендә эшләнгән 10 меңнән артык видеоәсбаб, тренажерлар, тестлар һәм башка материаллар бар, татар теле буенча башлангыч мәктәп өчен контент эшләнде (1 – 2 сыйныфлар). Платформага 500 республика мәгариф оешмасы тоташтырылды. Өстәмә төстә 515 гомуми белем бирү оешмасы дистанцион форматка вакытлыча күчү чорында уку елы ахырына кадәр түләүсез тоташтырылды.

2019/2020 уку елыннан Татарстан Республикасы 13 белем бирү оешмасы базасында укытуның индивидуаль траекторийларын гамәлгә ашыруны һәм нәтиҗәләрне бәяләүне тәэмин итүче цифрлы платформаны сынау буенча Россия Федерациясенең пилот субъектларыннан берсе булып тора.

«Балалы гаиләләргә ярдәм итү» проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2020 елда республикада балалары булган гражданнарга 42 меңнән артык психологик-педагогогик, методик һәм консультатив ярдәм күрсәтелде. «Тиктормас» мәгариф үзәге» автоном коммерциячел булмаган гомуми белем бирү оешмасы, «Үренте» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге, «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм булган балаларны гаиләләргә урнаштыру, Казан шәһәрендә тәрбиягә алучы гаиләләрне әзерләү» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәт күрсәтте.

2020 елда пандемиягә бәйле рәвештә республиканың барлык мәктәпләре «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә җепселле-оптик элемтә технологиясе буенча тоташтырылды. «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады » милли программасының «Цифрлы технологияләр» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында аңа 546 мәгариф оешмасы һәм 10 һөнәри урта белем бирү

оешмасы тоташтырылды. Бу максатларга федераль бюджеттан 300,0 млн сум акча бүлеп бирелде (шулардан урта һөнәри белем бирү оешмаларына - 5,4 млн сум), Татарстан Республикасының инвестиция акчалары хисабына 138 млн сумлык 522 белем бирү оешмасы тоташтырылды, Wi-Firа тоташу нокталарын модернизацияләүгә 136,0 млн сум тотылды.

Укуда дистанцион формат кулланылган чорда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында кайнар линия эшләде. Белгечләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану, белем бирү процессында катнашучыларны төрле онлайн-платформаларга һәм цифрлы ресурсларга, балаларның мәгълүмати иминлеге, башка техник проблемалар карала торган сайтларга теркәү мәсьәләләренә кагылышлы сорауларга җавап бирде. Үзизоляция һәм читтән торып укытуны оештыру чорында ярдәмгә мохтаҗ укучыларга социаль ярдәм күрсәтү максатларында республиканың гомуми белем бирү оешмалары 4 116 берәмлек компьютер җиһазларын түләүсез файдалануга (уку елы ахырына кадәр) бирделәр.

«Үз мәктәбеңә запас гаджет бир!» һәм «Өйдә укырга ярдәм ит!» хәйрия акцияләре кысаларында республика халкы һәм бизнес вәкилләре үзләре тәмамлаган мәктәпләрдә укучылар өчен 1 391 гаджет җыеп тапшырырга ярдәм итте. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 1 969 планшет-компьютер (1 909ы – гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен, 60ы – урта һөнәри белем бирү оешмалары өчен) муниципаль берәмлекләргә тапшырылды, аларны киләчәктә аз керемле һәм күпбалалы гаиләләргә дистанцион укытуны оештыру максатларында тапшыру күздә тотыла. Аз керемле һәм күпбалалы гаиләләр өчен республика территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары ректорлары тарафыннан 124 планшетлы компьютер бирелгән.

*Һөнәри белем бирүне үстерү*

Татарстан Республикасында 99 һөнәри белем бирү оешмасы эшли, шулардан 88 е – төрле ведомство буйсынуындагы дәүләт оешмасы, 74 675 кеше белем ала торган дәүләтнеке булмаган 11 оешма, шул исәптән урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча 62 661 кеше, квалификацияле эшчеләр әзерләү программалары буенча 12 014 кеше белем ала.

41 ресурс үзәге эшли. 2020 елда дүрт һөнәри белем бирү оешмасына ресурс үзәге статусы бирелде («Бөгелмә төзелеш-техник көллияте» (төзелеш, сәнәгать һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсе), «Чаллы педагогика көллияте» (педагогик кадрлар әзерләү), «Казан политехника көллияте» (металл эшкәртү), «Е.Н. Королев исемендәге Түбән Кама политехника көллияте» (төзелеш һәм энергетика) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениеләре).

2020 елда «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) VIII милли чемпионат финалы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы диплом һәм беренче дәрәҗә кубок (38 алтын, 25 көмеш, 39 бронза медаль, шулай ук һөнәри осталык өчен 29 медаль) белән бүләкләнде. Республика 2017 елдан WorldSkills стандартлары буенча демонстрация имтиханында актив катнашучы булып тора. 2020 елда республика бу юнәлештә үзенең нәтиҗәле эшләвен арттырды. Демонстрация имтиханын 62 мәгариф оешмасыннан 48 компетенция буенча 4 086 укучы (2019 ел белән чагыштырганда 25

процентка артыграк) тапшырды. Аларның әзерлек дәрәҗәсен бәяләүдә педагогика өлкәсе хезмәткәрләре һәм республика предприятиеләре һәм оешмалары хезмәткәрләреннән 1 000 тирәсе эксперт катнашты.

Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча VI Милли чемпионат ярышларында «Абилимпикс» республика җыелма командасы 42 компетенциядә 84 медаль яулады (19 алтын, 19 көмеш, 46 бронза) 2 нче урыны яулады.

«Цифрлы нигездә белем бирү мохите» федераль проектының «Гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы нигездә белем бирү мохитенең максатчан моделен кертү» чарасы кысаларында республиканың 39 көллияте һәм техникумы компьютер һәм интерактив җиһазлар белән җиһазландырылды, шул исәптән моңа федераль бюджеттан 71,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 16,7 млн сум тотылды.

2020 елда һөнәри белем бирү өлкәсенең 6 оешмасындагы 29 остаханәне җиһазлар белән тәэмин итүгә «Яшь һөнәр ияләре» федераль проекты кысаларында 269,3 млн сум бүлеп бирелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 216,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 53,1 млн сум («Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте», «Лениногорск нефть техникумы», «Әлмәт политехника техникумы», «Казан радиомеханика көллияте», «Алабуга политехника техникумы», «Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениеләре).

*Милли мәгарифне үстерү*

Этномәдәни белем һәм тәрбия бирү, Татарстан Республикасы халыкларының тарихын, мәдәниятен, милли традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү – өстенлекле бурычларның берсе. Хәзерге вакытта республиканың мәгариф оешмаларында 5 телдә (рус, татар, чуваш, удмурт, мари) белем бирелә, 7 тел (рус, татар, чуваш, удмурт, мари, мордва, иврит) өйрәнү предметы булып тора.

Якшәмбе мәктәпләренең 42 бүлегендә «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы белән берлектә 25 милләт вәкиленең телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү оештырылды (әрмән, азәрбайҗан, немец, грузин, башкорт, керәшен, татар, поляк, һинд, кыргыз, төрек, гарәп, удмурт, инглиз, вьетнам, чуваш, бурят, испан, лезгин, мари, таҗик, мордва (эрза), үзбәк телләре). Укыту-методика ягыннан ярдәм итү өчен аларның эшчәнлеге дәреслекләр белән тәэмин ителә. 2016 – 2020 елларда туган телләр (чуваш, удмурт, мари, мордва) өйрәтелә торган мәктәпләргә барлыгы 2,8 млн сумлык 20 мең экземпляр дәреслек һәм матур әдәбият китаплары китертелде, Татарстанның якшәмбе мәктәпләре өчен укыту-методик комплектлар сатып алынды.

Федераль исемлеккә татар теле һәм әдәбияты буенча 89 дәреслек кертелде, 24 укыту-методик комплекты уку әсбабы буларак кулланыла. 2020 елда федераль реестрга башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары өчен «Туган (татар) тел», «Туган телдә белем бирелә торган мәгариф оешмалары өчен туган (татар) тел» предметлары буенча якынча программалар кертелде.

Башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары өчен «Туган (татар) әдәбияты», «Туган телдә белем бирелә торган мәгариф оешмалары өчен туган (татар)

әдәбият», «Туган телдә әдәбият уку» предметлары буенча белем бирүнең якынча программалары эшләнде. «Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен үстерү федераль институты» федераль дәүләт бюджет учреждениесе белгечләре белән берлектә «Татарстан Республикасы дәүләт теле – татар теле» программалары буенча УМК эшләнә.

2020-2024 елларга татар теленә тәрҗемә ителгән уку басмаларын федераль дәреслекләр исемлегенә кертү буенча юл картасы эшләнде. Белем бирү процессында татар теленә тәрҗемә ителгән 79 УМК кулланыла.

Татар теле һәм туган (татар) әдәбият дәресләре өчен методик һәм дидактик материалларның (видеодәресләр, презентацияләр, дәреснең технологик карталары, тестлар) электрон базасы булдырылды. 2013 елдан теләге булган һәркем өчен ачык булган «Ана теле» татар телен дистанцион укыту онлайн-мәктәбе эшли. Аннан кулланучылар саны 2020 ел ахырына 28 меңнән артып китте, шул исәптән – 1 151 чит ил кешесе.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «2014-2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы һәм «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасында рус теле» ведомство максатчан программасы кысаларында уздырылган фәнни, мәдәни һәм белем бирү чаралары тел күптөрлелеген саклауга юнәлтелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән «2023-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы расланды.

2020 елда татар теле һәм әдәбияты укытучыларына татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призерларын әзерләгән өчен, татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадада 1,5 миллион сумлык 13 грант бирелгән. 100 укытучы өчен 50 мең сум күләмендә «Туган (татар) телендә укытучы укытучыларга ярдәм» дигән грант тормышка ашырылды.

«Татарстан Республикасының муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар, чуаш, удмурт, мари, мордва) телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» һәм «Туган (татар, чуаш, удмурт, мари, мордва) телләрендә балаларны укытуны һәм тәрбияләүне оештыру буенча иң яхшы балалар бакчасы» республика конкурслары үткәрелде, аларның йомгаклары буенча 20 мәктәп һәм 20 балалар бакчасы 500 мең сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнде.

2020 елда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының статусын күтәрү, педагогик тәҗрибәсе һәм һөнәри осталыгы белән уртаклашу максатларында Казан шәһәре Совет районының «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе һәм Казан шәһәре Совет районының «180 нче күппрофильле полилингваль гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе базасында «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бөтенроссия конкурсының йомгаклау этабы үткәрелде. Анда Татарстан Республикасының 15 муниципаль берәмлегеннән 20 татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Россия Федерациясенең 12 субъектыннан 12 татар теле һәм әдәбияты укытучысы катнашты.

2020 елда «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе тарафыннан класстан тыш эш буенча чаралар һәм проектлар әзерләү буенча ТАССР мәгарифенең 100 еллыгына багышланган республика конкурсы уздырылды, анда педагогларның 150 эше каралды. Беренче дәрәҗәдә 15 педагог, икенче дәрәҗәдә 19 педагог, өченче дәрәҗә 17 педагог җиңүче булды.

Җәйге каникуллар вакытында татар телен тирәнтен өйрәнү, балаларда милли үзаң формалаштыру максатында махсус профильле лагерь сменалары оештырылды. Анда 1045 бала катнашты. Заманча уңайлы шартларда балалар татар һәм инглиз телләрен өйрәнделәр, шулай ук көндәлек күңел ачу программаларында һәм һөнәри инструкторлар җитәкчелегендә төрле осталык дәресләрендә катнаштылар.

2020 елның апреленнән июль аена кадәр гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорының туган ягы тарихына багышланган рус, татар, чуаш, удмурт, мари, мордва телләрендә иң яхшы әсәрләргә конкурс үткәрелде, якташларының исемнәрен һәм батырлыкларын, шул исәптән урамнар, мәйданнар, предприятиеләр һәм оешмалар исемнәрен белүгә багышланган иде.

Татар телен электрон мәгълүмат киңлегенә таратуны гамәлгә ашыру буенча системалы чаралар күрелде. Балалар арасында да, өлкәннәр арасында да «Шаян ТВ» балалар телевизион каналы, «Бала» балалар мультимедиа китапханәсе һәм «Татар иле» электрон мәктәп энциклопедиясе популярлык казанды. Алар шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган һәм барлык төбәкләр өчен ачык.

2020 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара коммуникация институты Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе базасында максатчан төстә милли кадрлар әзерләү дәвам иттерелде. Монда 2020/2021 уку елында би- һәм полилингваль нигездә 386 кеше белем ала, шул исәптән 2020 елда 1 курска кабул ителгән 132 студент. Көндезге уку формасы студентлары белән максатчан уку турында килешүләр төзелде, алар нигезендә бу студентлар укып бетергәч республиканың милли мәктәпләренә, мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына эшкә урнаштырылачак. Бу проект буенча беренче чыгарылыш 2023 елда булыр дип көтелә.

***«Мәгариф» илкүләм проекты***

2020 елда Татарстан Республикасы «Заманча мәктәп», «Һәр баланың уңышы», «Цифрлы нигездә белем бирү мохите», «Киләчәк укытучысы» федераль проектларының 11 чарасын гамәлгә ашыруда катнашты. Әлеге максатларга бүлеп бирелгән акчаның гомуми суммасы 1,8 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 1,1 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 700,0 млн сум.

2020 елда «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында 42 мәктәптә «Үсеш ноктасы» цифрлы нигездә һәм гуманитар профильле белем бирү үзәкләре булдырылды, «Технология», «Мәгълүмат», «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» фән өлкәләре буенча җиһазлар сатып алынды. Белем бирү эшчәнлеген

бары тик җайлаштырылган гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы 2 оешмада сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен остаханәләренең, өстәмә белем бирү кабинетларының матди-техник базасы, педагог-психолог, укытучы-дефектолог, укытучы-логопедның составы яңартылды. Казан шәһәрендә гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру чаралары кысаларында Н.Җиһанов урамында 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы һәм 1 224 урынга исәпләнгән «Адымнар» полилингваль мәктәбе ачылды.

«Һәр баланың уңышы» федераль проекты чаралары кысаларында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча түбәндәге эшләр башкарылды:

6 спорт залында ремонт ясалды;

Чаллы шәһәренең «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы базасында мобиль кванториум;

«Казан талантларның ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасы һәм «Республика Олимпиада үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең «Дуслык» савыктыру-белем бирү комплексы структур бүлекчәсе базасында Татарстан Республикасында сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү буенча республика үзәге («Сириус» белем бирү үзәге моделе буенча);

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең (филиалы) Алабуга институты базасында балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Фәнни коллаборация йорты ачылды.

«Цифрлы нигездә белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында республиканың 78 мәгариф оешмасында цифрлы нигездә белем бирү мохитенең максатчан моделе кертелде. 39 мәктәп һәм 39 урта һөнәри белем бирү оешмасы өчен исәпләү техникасы, программа белән тәэмин итү һәм презентация җиһазлары сатып алынды, алар укучыларның һәм педагогларның цифрлы нигездә белем бирү инфраструктурасына (федераль электрон платформаларны да кертеп) керүен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. 2020 елда «Әлмәт политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри учреждениесе базасында «IT-куб» балаларга цифрлы белем бирү үзәге ачылды, аны төзүгә 12,8 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан 10,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 2,4 млн сум тотылды.

«Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында кысаларында 2020 елда Татарстан Республикасы Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәген һәм Педагогларның һөнәри осталыгын өзлексез арттыру үзәген төзүгә федераль бюджеттан субсидияләр алуга конкурс нигезендә сайлап алуда җиңеп чыкты. Бу үзәкләрне төзүгә 71,9 млн сум, шул исәптән федераль бюджетыннан 58,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 13,7 млн сум тотылды. Субсидия җиһазлар, исәпләү техникасы сатып алуга һәм ремонт эшләренә бирелә.

***«Белем бирү төбәге: яңа икътисадка – яңа һөнәрләр һәм белемнәр» флагман проекты***

2016 елдан Чаллы шәһәрендә Күпфункцияле гамәли квалификацияләр үзәге һәм Түбән Кама шәһәрендә Казан милли тикшеренү технология университетының Нефть

химиясе инжиниринг үзәге эшли. Алар Татарстан Республикасының югары технологияле тармаклары белгечләренең квалификациясен күтәрү белән шөгыльләнәләр.

Күпфункцияле гамәли квалификацияләр үзәге – гамәли күнекмәләр һәм белем алу өчен һөнәри укыту һәм квалификация күтәрү буенча кыска вакытлы программаларны гамәлгә ашыручы уку үзәге. Анда түбәндәге эшчәнлек алып барыла:

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте персоналын өйрәтү, шул исәптән яңа һөнәр бирү өчен;

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте хезмәткәрләре квалификациясен, шул исәптән разрядын да, күтәрү өчен;

профильле мәгариф оешмаларында студентлар өчен уку-гамәли дәресләр уздыру өчен;

чит оешмалар хезмәткәрләрен һәм аерым затларны укыту өчен.

Чаллы шәһәрендә Күпфункцияле гамәли квалификацияләр үзәгендә машина төзү өлкәсендә 150 программа буенча төрле эшче һөнәрләр һәм белгечләр әзерләү каралаган. Үзәктә 18 уку кабинеты һәм лаборатория бар, алар заманча җиһазлар белән комплектланган. Болар: Mercedes-Benz двигательле КАМАЗ – 5 490 магистраль автопоездларын тарту машинасы, «Kremit» BSB буяу-киптерү камерасы, «Clark GTX16 электртөягеч, 6 «Wabeko» өйрәнгеч станоклары һәм «CORTINI» һәм башка лаборатор җиһазлар.

2013 елдан Казан (Идел буе) Федераль Университеты 5/100 федераль проектында катнаша (әйдәп баручы дөнья фәнни-мәгариф үзәкләре арасында конкурентлыкны үстерү максатында дәүләт ярдәме алу ачык конкурсында җиңүчеләрнең берсе). Проектта катнашуның стратегик максаты – дөнья университетларының ТОП-100 исемлегенә керү һәм шул рәвешчә Татарстан Республикасының имиджын күтәрү. 2020 елда Татарстанның югары уку йортлары дөнья югары уку йортларында уңай динамиканы саклап калды. QS World University Rankings халыкара академик рейтингында Казан (Идел буе) Федераль Университеты 370 позицияне (2019 елда – 392) биләде.

Times Higher Education «Мәгариф» юнәлеше буенча предмет рейтингында (анда 400дән артык югары уку йорты катнаша) Казан (Идел буе) Федераль Университеты 90 урынны алды һәм дөньяның иң яхшы йөз югары уку йорты исемлегенә керде.

«2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы кысаларында яшьләр һәм өлкәннәр өчен «мәгърифәти чаралар уздыру дәвам иттерелде.

2020 елда «Талантлы һәм сәләтле балаларны һәм яшьләрне барлау, үстерү һәм эшкә урнаштыру экосистемасы» темасына «Талантлар ачу» махсус форумы узды, анда 10 меңнән артык кеше катнашты.

«Казанның талантлар өчен ачык университеты 2.0.» автоном коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан «Татарстан Республикасында югары белем имиджы», «Сәләтле булу феномены: балалык чорында чагылышы һәм үсеше үзенчәлекләрен аңлауга карашлар» темасына «Дөнья талантлары: сәләтле балалар һәм яшьләр үсешен үстерү һәм аларга ярдәм итү буенча иң яхшы тәҗрибә үрнәкләре» темасына чагыштырма проект семинары үткәрелде.

«Тренинг-класс» дигән предметка кермәгән компетенцияләрне үстерүнең челтәргә тоташтырылган мәйданчыклары эшчәнлеген дәвам иттерде. 2020 елда төрле дәрәҗәдәге мәгариф оешмалары базасында оештырылган тренинг дәресләредә 5 815 кеше катнашты.

Укучылар арасында эшче һөнәрләре турында профориентация хакатоны үткәрелде. Чараның партнерлары – «Татэнерго» АҖ, «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ һәм «Казан вертолет заводы» ГАҖ.

Җитештерү бурычларын хәл итү, чыгарыла торган продукциянең сыйфатын яхшырту, коллективны берләштерү һәм нәтиҗәле эшләү атмосферасы булдыру, корпоратив элемтәләрне җайга салу, шулай ук «Казан вертолет заводы» ГАҖнең стратегик үсеш программасына идеяләр һәм тәкъдимнәр кертү максатларында «Казанның талантлар өчен ачык университеты 2.0.» автономияле коммерциячел булмаган оешмасының 10 студенты «Тормыш циклы белән идарә итү» компетенциясе буенча һөнәри осталыкның завод конкурсы кысаларында стажировка узды.

*«Югары мәктәпләрнең конкурентлыкка сәләтен үстерү өчен партнерлык» флагман проекты*

2020 елда «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү учреждениесе базасында Татарстан-Финляндия циркуляр икътисад үзәге (алга таба – Үзәк) булдырылды, аның төп партнерлары – Финляндиянең SITRA инвестиция фонды һәм «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ. Үзәк Татарстан Республикасында циркуляр икътисад кысаларында эшне активлаштыру һәм бу өлкәдә проектларны гамәлгә ашыру, шулай ук проектларны гамәлгә ашыру өчен инвесторлар җәлеп итү максатларында төзелде.

2020 елның 28 сентябрендә мәгариф оешмаларын циркуляр икътисад принципларына өйрәтүгә һәм тиешле уку дисциплиналарын (модульләрен) эшләүгә юнәлтелгән фәнни-мәгариф семинары узды. Семинарда республиканың гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләреннән, икътисадый (профильле) дисциплиналар укытучыларыннан 59 кеше катнашты.

«Россия Федерациясендә тикшеренүләр уздыру һәм эшләнмәләр өчен алдынгы инфраструктураны үстерү» федераль проекты кысаларында «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе 2020 елда приборлар базасын яңартуга 157,7 млн сум күләмендә грант алды.

*«Инноваторларга социаль ярдәм» флагман проекты*

2020 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында «Белем бирү буенча күрсәткечләре түбән булган мәктәпләрдә һәм начар социаль шартларда эшләп килүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын күтәрү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында 355 кеше, «Конкрет өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү һәм челтәр методик берләшмәләренә ярдәм итү буенча яңа федераль дәүләт белем бирү стандартына туры китереп белем бирү технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» чарасы буенча 5906 кеше квалификацияләрен күтәрде.

**Яшьләр сәясәте**

2020 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге оешмалар челтәрендә 378 учреждение исәпләнә: 12 республика учреждениесе, 30 муниципаль яшьләр үзәге, 224 муниципаль яшүсмерләр клубы, 52 савыктыру-ял учреждениесе, балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча 6 муниципаль үзәк, 1 балалар һәм яшьләр өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү үзәге, студентларның 3 муниципаль хезмәт отрядлары үзәге, җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләренең 40 муниципаль үзәге, хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне әзерләү буенча 4 муниципаль үзәк, яшьләргә ярдәм итү эшен оештыру буенча 2 үзәк, балаларны, яшүсмерләрне савыктыру, аларның ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча 4 үзәк.

Алар базасында түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып барыла: ирекле эшчәнлек, студентлар хезмәт отрядлары, «ФОРПОСТ» отрядлары, яшьләр советы/яшьләр парламенты, тапкырлар һәм шат күңеллеләр клубы (КВН), нәфис, гамәли, спорт, техник, профилактик, сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру (шул исәптән төрле бәйлелекне, экстремизмны, ВИЧ/СПИДны, сукбайлыкны һәм хокук бозуларны, балигъ булмаганнар арасында суицид очракларын кисәтү), патриотик, туристлык, экология, компьютер, телләрне өйрәнү, эшкә урнаштыру, аралашу төркемнәре.

Татарстан яшьләр үзәкләрен реновацияләү программасы кысаларында аларның эшчәнлек стандарты әзерләнде.

Дәүләт яшьләр сәясәтен норматив хокукый тәэмин итү системасын камилләштерү өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең нигез стандарты» проект офисы гамәлгә ашырыла, аның кысаларында 2020 елда соңгы ун елда беренче тапкыр аттестация уздырылды.

Соңгы 25 елда яшьләр арасында барган иҗтимагый-социаль процессларга дөрес, адекват бәя бирү максатында 2020 елда «Татарстан Республикасында яшьләр турында» аналитик доклад әзерләнде.

Халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең сыйфатын күтәрү өчен Ведомствоара эксперт советы тарафыннан Халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасында психологик эшчәнлек алып баручы белгечләрнең эшчәнлегенә күзәтчелекне башкаруның ведомствоара регламенты расланды.

2020 елгы сәламәтләндерү кампаниясе кысаларында санитария-эпидемиология вазгыяте шартларында күмәк ял итү һәм сәламәтләндерүнең төрле формалары оештырылды, 139 449 бала ял итте. 817 ял һәм сәламәтләндерү оешмасы шул исәптән 102 стационар лагерь, 715 көндезге лагерь эшләде. 2020 елда гамәлдә булган балаларны савыктыру лагерьлары саны буенча республика ил төбәкләре арасында 1 урынны алды.

2020 елда 11 балаларны савыктыру лагеренда, 5 яшьләр үзәгендә, 16 яшьләр-яшүсмерләр клубында төзелеш, яңартып кору һәм төзекләндерү эшләре үткәрелде.

Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше – яшьләргә тормышта үз урынын табу, яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен шартлар

тудыру. Яшьләрнең яшәү урыннарында тиешле шартлар тудырылса, алар читкә китми, дигән сүз.

2020 елда торак мәсьәләләрен хәл итүдә яшь гаиләләргә ярдәм итү максатларында:

1. Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча федераль чара кысаларында 48 яшь гаиләгә 62,8 млн сумлык субсидия бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 13,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 49,5 млн сум.

2. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законы кысаларында 24 яшь гаиләгә 40,6 млн сумлык процентсыз түләү бирелгән.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә социаль ипотека системасында торак бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 13 июлендәге 587 номерлы карары кысаларында «Яшь гаилә» программасында августтан декабрьгә кадәр 398 гаилә катнашты, шуларның 122 се яңа торакка күченде.

4. Социаль ипотека программасы буенча торак алуга яшьләр сәясәте лидерлары арасында уздырылган конкурста катнашучыларның 49 ы (18 муниципаль берәмлектән) җиңүче булды.

2020 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты составы тулысынча формалаштырылды, анда 100 яшь парламентарий керә. Шуларның 45 е – муниципаль берәмлекләр вәкилләре, 35 е – яшьләр иҗтимагый оешмалары һәм берләшмәләре активистлары һәм 20 се – үз кандидатураларын үзләре тәкъдим итүчеләр.

Өч ел рәттән Татарстан Республикасы Яшьләр хөкүмәте Россия Федерациясе Яшьләр хөкүмәтләре ассоциациясе составына керүче субъектлар арасында яшьләр хөкүмәтләре бишлегенә керә. 2020 елда Яшьләр хөкүмәте Красноярск шәһәрендә узган XII Съезд кысаларында иң яхшы экспертлык-аналитика эшчәнлеге өчен бүләкләнде.

Кадрлар эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Яшьләр хөкүмәтенең 28 әгъзасы республиканың министрлыкларына, ведомстволарына, коммерциячел оешмаларына эшкә урнаштырылды, 4 кеше югарырак вазыйфага билгеләнде, Яшьләр хөкүмәтенең 2 әгъзасы министрлыклар һәм ведомстволар карамагындагы иҗтимагый советлар составына, 1 кеше Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе составына, 1 кеше идарәче кадрлар резервына (Татарстан Республикасы Президентының кадрлар резервы) кертелде.

2020 елда яшьләр сәясәтен һөнәри кадрлар белән тәэмин итү системасы – «Корпоратив университет» проекты кысаларында 1 974 кеше укыды.

Республикада төрле юнәлешләрдәге 700дән артык студентлар берләшмәсе эшли, аларда 45 меңнән артык студент катнаша. Һәр берләшмәгә күпсанлы советлар, клублар, комиссияләр, студияләр, коллективлар һ.б. керә.

Иң эре студентлар оешмасы – «Татарстан Республикасы студентлар лигасы» төбәк иҗтимагый оешмасы, ул 150 меңнән артык студентны берләштерә. 2020 елда ул 300дән артык чара (оффлайн һәм онлайн) уздырды, аларда 30 меңнән артык

студент катнашты, 7 шәһәрдә (Алабуга, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск, Бөгелмә, Чаллы) җирле яшьләр иҗтимагый оешмалары булдырылды.

2020 елда Казансу елгасы яры буенда «Миллениум» күпере астында «УРАМ» яшьләр экстрим-паркы ачылды, анда урам спорт төрләре буенча ярышлар уза.

Татарстан Республикасының яшьләрнең ирекледәр хәрәкәтендә 1 247 ирекледәр берләшмәсендә 64 353 кеше катнаша. Волонтерлар берләшмәләре «Җиңү волонтерлары», «Волонтерлар-экологлар», «Волонтер-медиклар», спорт һәм социаль проектларында ирекле катнашучылар (Татарстан Республикасында Kazan volunteers хәрәкәте), «Мәдәният волонтерлары», «Туристлык волонтерлары», «Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы волонтерлары», сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә ярдәм итү, территорияләрне төзекләндерү буенча волонтерлар (волонтерлар) хәрәкәтләре аша тәкъдим ителде. 2020 елда федераль проектның «МыВместе» региональ штабы һәм «Ярдәм Янәшә! Ярдәм якында гына!», республика хәрәкәте булдырылды, анда 7 меңнән артык волонтер катнашты.

Татарстан Республикасының эзтабарлар хәрәкәте тәҗрибәсе федераль дәрәҗәдә берничә ел дәвамында иң яхшыларның берсе дип танылა. Бөтенроссия патриотик форумы кысаларында Татарстан Республикасы иң актив дирекцияләр рәтенә керде. «Ватан» берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы «Иң яхшы эзтабарлар отряды» категориясендә «Хәтер безгә ышанып тапшырылган» номинациясендә җиңүче булды.

2020 елда федераль форум кампаниясе һәм Яшьләр эшләре буенча федераль агентлыкның конкурслары йомгаклары буенча Татарстан Республикасы проектларына 125,05 млн сум бүлеп бирелде, бу исә 2019 елга караганда 33,2 процентка күбрәк (93,9 млн сум).

«Игелекле эшләр регионы» бөтенроссия конкурсы йомгаклары буенча «Мәгариф» илкүләм проектының «Социаль активлык» федераль проекты кысаларында 2019 елда Татарстан Республикасы 2020 елда ирекледәр хәрәкәтенә ярдәм проектларын тормышка ашыруга 10,3 млн сум алды (шул исәптән 8,3 млн сум – федераль бюджеттан, 2,0 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан). Ирекледәргә ярдәм итү проектларын гамәлгә ашыруга 2021 елда 7,7 млн сум акча алынган (шул исәптән 6,2 млн сум – федераль бюджеттан, 1,5 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан).

2020 елның августында «Таврида» арт-кластерында Татарстан Республикасы командасы республикадагы арт-резиденция төбәк челтәре проектын тәкъдир итте һәм 7,5 млн сум күләмендә грант отты. Барлыгы Татарстанда 7 арт-резиденция булачак, шуларның беренчесе 2020 елда «Йолдызлык» арт-резиденциясе булды.

2020 елда 50дән артык чит ил яшьләре Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган халыкара яшьләр проектларында онлайн һәм офлайн-форматларда катнашты. Яшьләрнең эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү, талантлы яшьләргә ярдәм итү, яшьләрнең рухи үсешенә юнәлдерелгән шартлар тудыру, яшьләрнең халыкара дәрәҗәдә алмашуына ярдәм итү кебек юнәлешләр буенча халыкара 10 зур чара уздырылды.

«Милли – актуаль» проект офисы кысаларында «Таба» милли проектларының яшьләр инкубаторы оештырылды, анда 200дән артык проект катнашты, шулай ук

«ЭтноСтартапФорум», «Таба» этно-музыка фестивале һәм «Этно-маркет» кебек проектлар гамәлгә ашырылды.

**Мәдәният үсеше. Креатив индустрияләр**

***«Мәдәният» илкүләм проекты***

Татарстан Республикасында «Мәдәният» илкүләм проекты максатларына ирешү өчен өч төбәк проекты булдырылган: «Мәдәни мохит», «Иҗади кешеләр» һәм «Цифрлы мәдәният». 2020 елда проектны гамәлгә ашыру өчен 279,1 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан 166,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан 113,0 млн сум бүлеп бирелгән.

2020 елда *«Мәдәни инфраструктураны үстерүнең яңа сыйфат дәрәҗәсенә ирешү («Мәдәни мохит»)» төбәк проектын* гамәлгә ашыру кысаларында:

федераль финанслау нигезендә 8 авыл мәдәният йорты төзелде: 100 урынга – Буа муниципаль районының Кырык Садак һәм Питрәч муниципаль районы Надеждино авылларында, 200 урынга – Кукмара муниципаль районының Иске Юмья һәм Тукай муниципаль районының Илбухтино авылларында, 50 урынга – Чирмешән муниципаль районының Светлогорск бистәсендә, Апас муниципаль районының Ясаш-Барыш һәм Түбән Биябаш авылларында, 300 урынга – Саба муниципаль районының Сатыш авылында;

модельле 3 китапханә заманча җиһазландырылды (Спас, Арча һәм Биектау муниципаль районнарында);

Татарстан Республикасының «Чаллы дәүләт курчак театры» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе бинасына капиталь ремонт ясалды;

2 кинозал заманча җиһазландырылды: хосусый – Биектау муниципаль районында һәм Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында.

2020 елда республикада мәдәният учреждениеләренә, тулаем алганда, 22 092,1 мең кеше килде (максатчан күрсәткеч 20 000,0 мең кеше).

*«Милләтнең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру» төбәк проекты буенча* 2020 елда түбәндәге күрсәткечләргә ирешелде:

Мәдәният тармагында эшләүче 716 белгеч Россия Федерациясенең алты югары уку йорты каршында өзлексез белем бирү үзәкләре базасында («Мәскәү дәүләт хореография академиясе» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Россия театр сәнгате институты – ГИТИС» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «С.А. Герасимов исемендәге Бөтенроссия дәүләт кинематография институты» югары белем бирү федераль дәүләт мәгариф учреждениесе, «Санкт-Петербург дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү учреждениесе, «Мәскәү дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт югары белем бирү учреждениесе, «Кемерово дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт югары белем бирү учреждениесе;

20 үзешчән коллектив грантлар белән бүләкләнде, грант алучылар арасында фольклор коллективлары, балалар инструменталь оркестрлары һәм ансамбльләре, халык театрлары бар;

753 волонтер «Мәдәният волонтерлары» программасына кертелгән, бу максатчан күрсәткечтән 13,2 процентка артык (максатчан күрсәткеч - 665 кеше).

5 проектка федераль бюджеттан субсидияләр бирелде:

2 се – 2 889,9 мең сумга «МКМ: Яшьләр. Мәдәният. Менеджмент» һәм «Остров» фестивале волонтерлар проектларын гамәлгә ашыру өчен;

2 се – 13 215,0 мең сумга музыкаль һәм театр сәнгате өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга (XV Халыкара хәзерге сәнгать буенча арт-симпозиум «Дуслык калейдоскобы», «В.А. Моцарт музыкасына В.В. Васильев постановкасында «Реквием» спектакле премьерасын кую»);

1 се – Россиядә гражданлык тәңгәллеген ныгытуга юнәлтелгән иҗади проектларны гамәлгә ашыруга 3 475,0 мең сум күләмендә («Халык иҗаты хәзинәлекләре»).

3 масштаблы фестиваль проекты гамәлгә ашырылды (Ф.И. Шаляпин исемендәге XXXVIII Халыкара опера фестивале, «Нәүрүз» халыкара театр-мәгариф форумы (онлайн), Рудольф Нуриев исемендәге классик балет фестивале).

Россия Федерациясенең әйдәп баручы музейлары белән берлектә 2 күргәзмә проекты оештырылды: «Бөек Новгород һәм Псков бизәкләре» төбәкара күргәзмәсе һәм А.Н. Радищев исемендәге Саратов дәүләт сәнгать музее җыелмасыннан Павел Кузнецов күргәзмәсе.

*«Хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыру һәм мәдәният өлкәсендә мәгълүмати киңлек булдыру» региональ проектын гамәлгә ашыру кысаларында* 2020 елда:

500 китап цифрлаштырылды;

2 мультимедиа-гид булдырылды: «Татарстан Республикасының сынлы сәнгать дәүләт музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең төп экспозициясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгының Ислам мәдәнияте музее экспозициясе.

*«Креатив индустрия» флагман проекты*

2020 елда мәдәният учреждениеләре челтәренә 3 790 учреждение кертеп исәпләнде: 40 театр-тамаша учреждениесе (23 дәүләт һәм 17 муниципаль), 1 511 китапханә (4 дәүләт, 1 507 муниципаль, шуларның 1 301 е – авыл җирендәге китапханәләр), 173 музей (68 дәүләт, 105 муниципаль музей), 1 917 мәдәни-ял итү учреждениесе (шуларның 1 845 е – авыл җирендә), 116 мәгариф оешмасы (10 дәүләт, 104 муниципаль, 2 федераль), 14 киноучреждение (1 дәүләт, 13 муниципаль), 12 халыклар дуслыгы йортлары (1 дәүләт, 11 муниципаль), 6 типик булмаган дәүләт мәдәният учреждениесе, 1 зоопарк (муниципаль).

Республиканың иҗат берлекләре тарафыннан карантин чорында онлайн очрашулар, концертлар, күргәзмәләр цикллары уздырылды, алар шул исәптән 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган иде.

Алар арасында иң әһәмиятлеләре:

«СОТВОРЕНИЕ» сәнгать-күргәзмә проекты кысаларында «ОМЭ» бөтенроссия пленэр-симпозиумы;

ТАССР төзелүгә 100 ел тулуга багышланган Татарстан Республикасы рәссамнары эшләре күргәзмәсе;

Габдулла Тукайның тууына 134 ел тулуга һәм Туган тел көненә багышланган «Шигърият бәйрәме»;

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре истәлегенә багышланган чара;

А.С. Пушкинның тууына 221 ел тулуга һәм Рус теле көненә багышланган флешмоб;

ТАССР төзелүгә 100 ел тулуга Япония һәм Тайваньдагы «Татар музыкасы энҗеләре» циклыннан симфоник концертлар;

Бөек композиторларга багышланган «Композитор истәлегенә» проекты кысаларында 4 камера концерты;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» театр премиясен тапшыру тантанасы һәм башкалар.

*Театр-тамаша учреждениеләре*

2020 елда Татарстан Республикасы театр-тамаша учреждениеләрендә булган тамашачыларның гомуми саны 835,9 мең тәшкил итте, шул исәптән театрларда – 517 мең кеше, концерт оешмаларында – 253 мең кеше, циркларда - 65,9 мең кеше.

2020 елда республика муниципаль берәмлекләре, илебез төбәкләре һәм чит илләр буенча дәүләт театр-тамаша учреждениеләренең 179 гастроле булды (шул исәптән театрлар – 109, концерт оешмалары – 70), шуларның 150 е – Татарстан Республикасы буенча; 25 е – Россия төбәкләре буенча; 4 се – чит илләрдә.

Республиканың дәүләт һәм муниципаль театрлары тарафыннан 92 премьера спектакле куелды, шуларның 38 е – балалар һәм яшүсмерләр аудиториясе өчен.

Эпидемиологик вазгыятьне исәпкә алып, 2020 елда театр-тамаша мәдәният учреждениеләре тарафыннан 18,5 чара онлайн форматта уздырылды, аларны 2 млннан артык кеше тамаша кылды. Карантин тәмамланганнан соң театр-тамаша учреждениеләренә йөрүчеләр саны 190,6 мең кеше тәшкил итте.

Татарстан театрлары дүртенче ел рәттән «Кече шәһәрләр театрлары» (8 театр, шуларның 2 се муниципаль – «Түбән Кама шәһәренең яшь тамашачы театры» һәм «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениеләре) һәм «Театрлар – балаларга» (4 дәүләт балалар театры) федераль проектларында катнашты.

2020 елда «Кече ватан мәдәнияте» федераль проекты кысаларында 44 спектакль куелды, проектлар буенча финанслауның гомуми күләме 99,0 млн сум тәшкил итте, шул исәптән 41,6 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 57,4 млн сум федераль бюджет акчалары исәбеннән тотылды.

«Мирас», «Казан көзе», «Денис Мацуев дуслары янында», «21 гасырда классик гитара», L’arte del arco, «Киләчәк йолдызлары» кебек зур музыкаль фестивальләр уздырылды.

La Primavera оркестры республика буенча концерт туры уздырды, 14 мәктәп-интернаттан физик яктан мөмкинлекләре чикле балалар өчен 12 концерт куелды.

«Казан дәүләт циркы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе мәйданчыгында 3 программа, 60 тамаша куелды, аларны 60 922 тамашачы карады. «Чаллы циркы» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе 90 тамаша һәм күңел ачу программасы күрсәтте.

*Китапханә эшчәнлеге*

Татарстан Республикасында һәркем файдалана ала торган 1 511 китапханә, шул исәптән 4 республика китапханәсе («Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Татарстан Республикасының «Республика яшүсмерләр китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Татарстан Республикасының «Республика балалар китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе) һәм 1 507 муниципаль китапханә, шуларның 1 301е – авыл җирендә эшли.

Һәркем файдалана ала торган китапханәләр фонды 23,3 млн берәмлек тәшкил итә.

2020 елда китапханәләрдә 14,6 млн кеше булды, 1,4 млн китап укучы китапханә хезмәтләреннән файдаланды, 28 миллионнан артык басма укучыларга кулга бирелде.

*Музей эше*

Татарстан Республикасы музей челтәренә 173 дәүләт һәм муниципаль музей челтәре берәмлеге керә, шул исәптән – 68 структур бүлекчәдән торучы 14 дәүләт музее, 105 структур бүлекчәдән торучы 49 муниципаль музей. Республика музейларында 63 883 экскурсия, 1 847 массакүләм һәм 8 784 мәдәни-белем бирү чарасы, 2 248 күргәзмә узды, әлеге чараларда барлыгы 3 364,1 мең кеше катнашты.

Татарстан Республикасы дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклары тарафыннан илебезнең башка төбәкләре музейлары белән берлектә 25 күргәзмә проекты һәм чит илләрдә 4 күргәзмә («Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе – 1 күргәзмә, «Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе – 3 күргәзмә) оештырылды.

Татарстан Республикасында 19 музейның (12 дәүләт һәм 7 муниципаль) рәсми сайты бар, социаль челтәрләрдә 101 музей (27 дәүләт һәм 74 муниципаль) теркәлгән.

«Татарстан Республикасы музейлары» (http://museum.tatar.ru/museum/) һәм «Татарстан музейлары» (http://collections.museum.tatar.ru/) порталларында 62 музей тәкъдим ителгән.

Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогында 2 309 Россия музее, шул исәптән Татарстан Республикасының 75 музее тәкъдим ителгән. Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогына 396 818 саклау берәмлеге (дәүләт музейларыннан – 274 698, муниципаль музейлардан 122 120 берәмлек), комплекслы автоматлаштырылган музей мәгълүмат системасының махсус системасына 1,2 млн предмет (дәүләт музейларыннан – 703 357, муниципаль музейлардан – 477 876 предмет) кертелгән.

«Татарстан Республикасы музейлары» электрон каталогында 215 340 саклау берәмлеге (2020 елда 13 279 саклау берәмлеге), шул исәптән 201 049 төп фонд предметын (2020 елда – 13 021 предмет), 14 291 фәнни-ярдәмче фонд предметын (2020 елда 258 предмет) урнаштырылган.

2020 елда республиканың дәүләт һәм муниципаль музейлары тарафыннан социаль челтәрләрдә һәм республика музейлары сайтларында 1 582 онлайн-күргәзмә оештырылды, аны 1 097,9 мең кеше карады, 3 788,1 мең кеше катнашында

7 616 онлайн чара һәм 1 393 онлайн экскурсия (аудитория – 1 697,2 мең кеше) уздырылды.

2019 елда музей эшчәнлеге өлкәсендә казанышлар:

«Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Россия төбәкләре буенча онлайн-турлар, виртуаль экскурсияләр, күргәзмәләр һәм социаль челтәрләрдә һәм Youtube-каналларда карау өчен Россиянең иң яхшы сынлы сәнгать музейлары категориясендә ТурСтат туристлык порталы рейтингының ТОП-10 да беренче урынны алды;

үзгәртеп корудан соң «Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе бинасы ачылды;

«Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында оештырылган «Борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр Татарстан тарихы» дигән даими эшли торган яңа экспозициясе ачылды;

Мәскәүдә «Дәүләт Третьяков галереясе» бөтенроссия музей берләшмәсе» федераль дәүләт бюджет мәдәният учреждениесендә «Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе җыелмасыннан ТАССРның 100 еллыгына багышланган «Казаннан шедеврлар. Рерихтан Кандинскийга кадәр» дигән көмеш гасыр һәм рус авангарды рәссамнары картиналары күргәзмәсе булып узды.

*Мәдәни-күңел ачу учреждениеләре*

Республикада 1 917 мәдәни-ял итү тибындагы учреждение исәпләнә, аларда 15 777 клуб оешмасы эшли, шул исәптән 13 554 – авыл җирлегендә.

2020 елда клуб учреждениеләре тарафыннан төрле юнәлешләрдәге һәм рәвешләрдәге 218 352 чара уздырылды.

Республика муниципаль берәмлекләренең мәдәни-күңел ачу учреждениеләре иҗат коллективлары халыкара конкурслар һәм фестивальләрдә 650, бөтенроссия күләмендәге 388 һәм 407 төбәк конкурсында диплом яулады.

Мәдәни-ял итү учреждениеләре бурычларының берсе – инвалидлар ялын оештыруда методик һәм оештыру ярдәме күрсәтү. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарны мәдәни-массакүләм чараларда катнашуга җәлеп итү максатыннан, мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрдә 18 118 кеше катнашында 1 515 инклюзив клуб оешмасы эшли. Инвалидлар катнашында 31 213 чара (концертлар һәм әдәби программалар, күргәзмәләр, аралашу гаилә кичәләре, хәйрия акцияләре һәм мәдәни-массакүләм эшчәнлекнең башка рәвешләре) үткәрелде.

*Мәдәният өлкәсендә белем бирү*

Хәзерге вакытта республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсе өчен кадрлар әзерли торган 105 өстәмә белем бирү, 9 һөнәри белем бирү, 2 югары белем бирү оешмасы эшли.

2020 елда мәдәният һәм сәнгать өлкәсе мәгариф оешмаларында 43 591 кеше белем алды, шулардан 38 471 кеше балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында (шул исәптән, 420 кеше «Бәхетле балачак» балалар үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә, 1 224 кеше Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль

районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә, 36 827 кеше Татарстан Республикасы районнарындагы балалар сәнгать мәктәпләрендә), 2 566 кеше – һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә), 2 554 кеше югары белем бирү оешмаларында укыды.

*Кинематография*

2020 елда Татарстан Республикасы кино челтәрен 175 кино залы, шул исәптән 1 дәүләт кинотеатры («Мир» кинотеатры), Татарстан Республикасы «Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең 3 кинозалы (алга таба – «Татаркино» ДБМУ), 7 муниципаль кинотеатрдагы 8 кино залы, 25 хосусый кинотеатрдагы 123 кино залы, муниципаль мәдәни-ял итү учреждениеләре составындагы 40 кино залы тәшкил итте. Моннан тыш, халыкка даими рәвештә кино һәм видео күрсәтүче 27 күчмә кино залы бар.

2020 елда республиканың кино күрсәтү учреждениеләрендә 10,5 мең, шул исәптән балалар өчен – 4,8 мең картина күрсәтелде, аларны 160 мең кеше, шуларның 88 меңе – балалар карады, барлыгы 6,4 млн сум акча җыелды.

«Татаркино» ДБМУ тарафыннан 445 фильм (шул исәптән 117 яңа), шулардан 318 е – Россиядә төшерелгән (шул исәптән 57 яңа фильм) прокатка чыгарылды. 2020 елның июль башында IGTV да («Инстаграм-телевидение») «Татаркино» ДБМУ видеоканалы эшли башлады, аны караучыларның гомуми саны 1,3 млн тәшкил итте.

2020 елда Ростов-на-Дону, Новосибирск шәһәрләрендә, Иркутск өлкәсендә, Чувашстан Республикасында, Финляндиядә, Мисырда Татарстан киносы көннәре узды, анда 900 гә якын кеше катнашты. Иран, Италия, Үзбәкстан, Германия, Япония, Польша киносы көннәре оештырылды.

2020 елда Казан халыкара мөселман киносы фестивале онлайн-режимда узды. Барлыгы дөньяның 63 иленнән 629 фильм теркәлде, конкурс шорт-исемлегенә 4 номинациядә 52 картина кертелде: «Тулы метражлы уен фильмы», «Кыска метражлы уен фильмы», «Тулы метражлы документаль фильмнар», «Милли конкурс».

2020 елда түбәндәге Татарстан фильмнары Россия һәм халыкара кинофестивальләрдә җиңү яулады:

«Ана» фильмы (режиссеры – Вячеслав Кузьмин) – «42 фильм» VIII кыска метражлы кино фестивалендә жюриның махсус призы (Ижевск шәһәре);

«Су анасы» фильмы (режиссеры – Алексей Барыкин) – «Алтын тәлинкә» төбәкара премиясе призы (Казан шәһәре);

«7 энҗе бөртеге» мультипликация фильмы (режиссеры – Сергей Киатров) – «Кояшлы утрау» IV балалар һәм гаилә киносы ачык фестивале жюриеның махсус дипломы (Кырым Республикасы);

«Бәхетле булыгыз» фильмы (режиссеры – Наталья Топал) – «КрымДок» III Кырым фестивале жюриеның махсус дипломы (Симферополь шәһәре);

«Ревизия кенәгәләре. Архив эше» мультипликация фильмы (режиссеры – Сергей Киатров) ÁMEN Animation film festival анимация фильмнары халыкара фестивалендә «Иң яхшы сценарий» номинациясендә җиңү яулады (Нур-Султан шәһәре);

«Казанның йөзек кашы – Апанай мәчете» (режиссеры – Әмир Гатауллин), «Почмакка басып бие» (режиссеры – Солтан Сөнгатуллин) фильмнары Төрек документаль кино халыкара фестиваленең конкурс программасына кертелде, «Почмакка басып бие» фильмы Төркиләр Дөньясының махсус премиясенә лаек булды (Истанбул, Төркия).

*Мәдәният өлкәсендә грант ярдәме*

2020 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан мәдәният өлкәсендә грантлар һәм акчалата бүләкләр бирү буенча түбәндәге конкурслар үткәрелде:

мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты гранты (Татарстан Республикасының 7 әйдәп баручы иҗат коллективы, гомуми суммасы – 329,4 млн сум);

муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (10 җиңүче, гомуми суммасы – 1,75 млн сум);

халык сәнгать һөнәрчелеге өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (12 җиңүче, гомуми суммасы – 5,0 млн сум);

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (91 җиңүче, гомуми суммасы – 15,0 млн сум);

шәһәрләрдә татар һәм рус мәдәни-ял итү мохитен булдыруга грант (5 җиңүче, гомуми суммасы – 400,0 мең сум);

авыл җирлекләренең иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә (63 җиңүче-хезмәткәр, гомуми суммасы – 3,2 млн сум һәм 85 җиңүче-учреждение, гомуми суммасы – 8,5 млн сум) акчалата бүләк.

*Халыкара һәм төбәкара мәдәни хезмәттәшлек*

Эпидемиологик вазгыять чорында иң зур зыян күргән юнәлеш – халыкара һәм төбәкара мәдәни хезмәттәшлек. 2020 елның март ахырыннан барлык чаралар (иҗат коллективлары гастрольләре, Россиядә һәм чит илләрдә Сабантуй бәйрәмнәре, чит ил партнерлары белән уртак мәдәни проектлар) туктатылды. 2020 елның 4 июлендә онлайн режимда үткәрелгән Сабантуй бәйрәме чыгарма булды, аны 1,5 млннан артык кеше карады.

Татар халкының традицияләрен, гореф-гадәтләрен һәм телен саклап калу һәм татар милли мәдәниятен пропагандалау максатыннан чыгып, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрен үткәрү эше алып барылды. 2020 елда Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләрендә һәм Ленинград өлкәсендә уздырылды.

«Үзгәреш җиле» татар җыры фестивале концерты дөньяның иң абруйлы концерт залларының берсе Нью-Йорк шәһәрендәге «Карнеги-холл» сәхнәсендә узды.

2020 елда «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе беренче тапкыр «Нәүрүз» театр-мәгърифәти форумын онлайн-форматта уздырды. Театр сәнгате һәм театр педагогикасы өлкәсенең күренекле

эшлеклеләре, Германия, Колумбия, Бразилия, Польша, Россия Федерациясеннән менеджментлык тармагы белгечләре фестиваль-форумның педагоглары булып торды. Форумда барлыгы Россиянең 33 төбәгеннән һәм 4 якын чит илдән 700 гә якын кеше катнашты.

Россия төбәкләре һәм чит илләр белән мәдәни хезмәттәшлекне үстерү максатларында 2020 елның 25 гыйнварында «Мир» кинотеатрында Россия һәм Индонезия арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруның 70 еллыгына багышланган чара узды, анда Индонезиядә төшерелгән Lima («Биш») фильмы күрсәтелде.

**Граждан җәмгыяте үсеше**

Граждан җәмгыяте институтлары белән актив хезмәттәшлек алып барыла. Идел буе федераль округында теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – КБО) саны ягыннан республика алдынгы урыннарның берсен алып тора. 2021 елның 1 гыйнварына республикада 5 880 КБО, шул исәптән 1 721 иҗтимагый оешма, 2 010 дини берләшмә, 2 116 коммерциячел булмаган башка оешмалар, шулай ук сәяси партияләрнең 33 төбәк бүлекчәсе теркәлгән.

Татарстанда «Татарстан Республикасының 2014–2020 елларга икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасының 2014–2020 елларга Татарстан Республикасы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – СЮКБО) ярдәм буенча ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлдә. Аның максаты – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә катнашуга СЮКБОга этәргеч бирү, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм милләтләр арасындагы татулыкны саклау, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең балансланган булуы нигезендә иҗтимагый иминлеккә ирешү. Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3,3 млрд сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 2,7 млрд сум, федераль бюджет акчалары исәбеннән – 42,2 млн сум, җирле бюджетлардан – 9,7 млн сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 497,8 млн сум. 2020 елда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 262,7 млн сум тәшкил итте.

СЮКБОга ярдәм итүгә юнәлтелгән муниципаль программалар кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла.

СЮКБОга төрлечә ярдәм күрсәтү республикада 2000 еллардан алып барыла. Дәүләт һәм муниципаль дәрәҗәдә дәүләт ярдәме алган коммерциячел булмаган оешмалар саны арта бара. Грант ярдәме, максатчан финанслау, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан тормышка ашырылучы социаль әһәмиятле проектларга конкурс нигезендә субсидияләр бирүгә кагылышлы норматив хокукый актлар кабул ителде.

Татарстан Республикасы иҗтимагый хәрәкәте үзәгендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тора. Аның эшендә 60 палата әгъзасы һәм эксперт берлегенең 200 вәкиле катнаша, иҗтимагый үсешнең актуаль мәсьәләләре буенча 9 комиссия төзелде. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнары каршында 33 иҗтимагый совет, муниципаль берәмлекләрдә 44 иҗтимагый совет эшли.

2012 елдан башлап Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстанда ярдәмнән файдаланган СЮКБОның республика реестры алып барыла. 2021 елның 1 гыйнварына Республика реестрында муниципаль һәм республика дәрәҗәсендә ярдәм алучы 891 оешма турында мәгълүмат теркәлде, аларга 2012–2020 елларда гомуми суммасы 12,6 млрд сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде. 2020 елда 351 социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмага барлыгы 2,0 млрд сумлык ярдәм күрсәтелгән. Реестр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://mert.tatarstan.ru/reestr.htm сылтамасы буенча урнаштырылган.

КБОга инфраструктура ягыннан ярдәм итү кысаларында Татарстан Республикасында КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре эшли, алар Ярдәмче программа акчалары ярдәмендә укыту, консалтинг һәм КБОлар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне тормышка ашыра, шулай ук «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы эшләп килә.

КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре Казан («Инновацияле үсеш һәм технологияләрне трансферлау» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Әлмәт («Вертикаль» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чаллы («Горизонт» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Кукмара («Вектор» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Буа («Буа Грант» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чистай («Бердәмлек» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы) шәһәрләрендә урнашкан.

СЮКБОларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында коммерциячел булмаган оешмалар йорты эшләп килә (Казан шәһәре, 8 Март урамы, 18 йорт).

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан СЮКБОларга түләүсез нигездә мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча республика конкурсы үткәрелә. Конкурста СЮКБОларга 2 елга түләүсез нигездә тулысынча җиһазландырылган эш урыннары белән тәэмин итү уйнатыла.

Гражданлык инициативаларын хуплау һәм республикада граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы гамәлгә ашырыла. 2020 елда әлеге премияне дәгъвалауга үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча (гомуми приз фонды – 2,75 млн сум) 8 премия бирелде:

И.Р. Баязитовка – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары

мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе, «Ярдәм» ислам хәйриячелек милли фонды советы рәисенә;

М.М. Ильясовка – «МИН БУЛДЫРАЧАКМЫН» сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә булышлык итү автоном коммерциячел булмаган оешмасы рәисенә;

Ә.Г. Юлашевка – «Россия ветераннар берлеге» гомумроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисенә;

«Федераль татар милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасына;

«Татарстан Республикасы рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасына;

Әлмәт муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасына;

«Бала – могҗиза» дәвалау педагогикасы үзәге автоном коммерциячел булмаган өстәмә һөнәри белем бирү оешмасына;

«НеЗаМи» балаларга һәм инвалидларга булышлык итү хәйриячелек фондына.

2015 елдан лауреат исеменә Татарстан Республикасының 15 күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм 24 КБО лаек булды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 28 июлендәге 524 номерлы карары нигезендә республикада социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы СЮКБОларның халыкка социаль хезмәт күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалана алуын оештыру буенча Координация советы (алга таба – Координация советы) төзелде.

Дәүләтнеке булмаган оешмаларның, шул исәптән СЮКБОларның социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүгә, социаль өлкәдә хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү механизмнарын эшләү, халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү буенча даими эш алып барыла. Тиешле «юл картасы» эшләнде, анда дәүләтнеке булмаган оешмаларга ярдәм итүнең төп бурычлары, этаплары, механизмнары, гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү эшчәнлегенә дәүләтнеке булмаган оешмаларны җәлеп итү чаралары билгеләнгән.

Социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрында 17 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүче 11 СЮКБО, шулай ук 9 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләргә һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүче 6 СЮКБО кертелгән.

Моннан тыш, өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытка карап тәрбияләп тору системасын булдыру кысаларында 2020 елда социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән ике дәүләтнеке булмаган оешма (Владимир шәһәренең «Булышлык» социаль ярдәм үзәге һәм «Ярдәмче» социаль хезмәте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте) «Авыру багучы» хезмәте күрсәтү буенча пилот проектын тормышка ашыруда катнашты. 2020 елда күрсәтелгән оешмалар өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) «Авыру багучы» хезмәтен күрсәтүгә чыгымнарны каплауга субсидия (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытка карап

тәрбияләп тору системасын гамәлгә ашыру чаралары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 60 номерлы карары нигезендә) алды.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, шулай ук СЮКБОларга ярдәм итү буенча ресурс үзәкләре тарафыннан СЮКБОлар эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру буенча эш алып барыла.

2016 елдан башлап Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ярдәме белән СЮКБО эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырткан иң яхшы массакүләм мәгълүмат чаралары билгеләү буенча конкурс үткәрү турында» 2016 елның 2 декабрендәге 885 номерлы карары нигезендә) үткәрелә. Конкурста ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар, шул исәптән СЮКБОлар да катнаша ала. 2020 елда конкурс 4 номинация буенча уздырылды: «Басма массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы мәкалә», «Иң яхшы телевидение сюжеты һәм тапшыруы», «Иң яхшы радио сюжеты яисә радио тапшыруы», «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы язма». 13 массакүләм мәгълүмат чаралары авторы җиңүче булды. Конкурсның гомуми приз фонды – 400 мең сум.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр өчен социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 25 августындагы 733 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәр елны балалар һәм яшьләр өчен социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы коммерциячел булмаган оешмалар өчен грантларын алуга республика конкурсы үткәрелә. Республика конкурс комиссиясе карары буенча 2020 елда 67 СЮКБО проекты җиңүче итеп игълан ителде, аларны тормышка ашыру өчен 17,4 млн сум бүлеп бирелде.

Татар телен саклау, илебездә татар милли мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру, гражданнар инициативаларына ярдәм итү максатыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү буенча конкурс үткәрелә. 2020 елда әлеге конкурс нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе субъектларыннан 30 КБО җиңүче дип танылды, субсидиянең гомуми суммасы 10,0 млн сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлтелгән иҗтимагый әһәмияткә ия (социаль) проектларны тормышка ашыру белән бәйле финанс чыгымнарны тәэмин итүгә конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бүлеп бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 27 февралендәге 122 номерлы карары нигезендә республикада экологик иминлекне

тәэмин итү өлкәсендәге СЮКБОларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүгә конкурс уздырылды. Конкурс комиссиясе карары белән 2020 елда 8 СЮБКО җиңүче дип табылды, проектларны гамәлгә ашыруга 2,0 млн сум акча бүлеп бирелде.

Моннан тыш, һәр елны республиканың КБОлары Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү буенча конкурсларда катнаша, аларны уздыру 2017 елдан Граждан җәмгыятен үстерү буенча президент грантлары фонды-операторына (Президент грантлары фонды) йөкләнде. Ике конкурс нәтиҗәләре буенча 2020 елда Татарстан Республикасының 16 КБО проекты җиңүче дип танылды, грантларның гомуми суммасы 181,1 млн сум тәшкил итте. Президент грантлары фондының махсус конкурсы нәтиҗәләре буенча яңа коронавирус йогышлы авыруының таралуына каршы көрәш чорында СЮКБОларга ярдәм итү максатыннан республиканың 18 КБО проекты җиңүче дип танылды, грантларның гомуми суммасы 41,9 млн сум тәшкил итте.

КБОларга ярдәм итү максатында республикада махсус портал булдырылды, анда коммерциячел булмаган оешмалар интернетта бушлай үз сәхифәләрен булдыра ала (http://www.nkort.ru/), бу киләчәктә СЮКБОларның имиджын үстерергә, аларны медиа-киңлектә тагын да танытуга этәргеч бирәчәк. Порталда КБОлар өчен кирәкле барлык мәгълүмат: норматив хокукый база, республика һәм шулай ук федераль конкурсларны уздыру, социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыру йомгаклары, СЮКБОларга ярдәм итү буенча муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлеге, муниципальара ресурс үзәкләре тарафыннан эшләнә торган мәгълүмати-методик материаллар урнаштырыла.

СЮКБОларга конкурслар һәм грантлар турында бер тәрәзә режимында мәгълүмат эзләүдә ярдәмгә «Грантлар Капитаны мәгълүмат-белем бирү үзәге» проекты – Россиянең барлык төбәкләрендәге актуаль грантлар һәм конкурслар турында белешмәләрне автоматлаштырылган рәвештә җыю өчен бердәй мәгълүмат системасы (https://cptgrants.org) тормышка ашырыла.

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 30 апрелендәге «#МыВместе» гомумроссия акциясендә катнашучылар белән очрашу нәтиҗәләре буенча төзелгән йөкләмәләр исемлеге нигезендә булдырылган СЮКБОларның федераль реестрына Татарстан Республикасыннан 636 СЮКБО кертелде. Яңа коронавирус йогышлы авыруының таралуы нәтиҗәсендә вазгыятьнең начарлануыннан аеруча зур зыян күргән коммерциячел булмаган оешмалар реестрына Татарстан Республикасыннан 330 КБО кертелде.

2020 елда кредит оешмаларыннан хезмәт хакының бер өлешен түләүгә 261,4 млн сумга ташламалы кредитны (еллык 2 %) Татарстан Республикасының 65 СЮКБОсы алды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда федераль бюджеттан кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга яңа коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау буенча чараларны уздыруга субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 976 номерлы карары нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасының 113 СЮКБОсы гомуми суммасы 26 млн сумга субсидия алды.

Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуы шартларында волонтерлык хәрәкәте массакүләм төс алды, ә волонтерлар барлык ярдәмгә мохтаҗ гражданнар өчен иң төп ярдәмчеләрнең берсенә әверелде. Ирекләләр тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарга, авыру йоктыру куркынычы янаучы гражданнарга, шулай ук өлкән яшьтәге гражданнар, инвалидлар һәм башка категория гражданнар өчен тору урыны булган оешмалар һәм учреждениеләргә ярдәм итү буенча чаралар комплексы тормышка ашырылды.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты базасында «#МыВместе» волонтерлар штабы эшләде, биредә студентлар, иҗтимагый оешмалар активистлары, спорт, мәдәният, мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре, шәһәрнең битараф булмаган гражданнары ирекләләр сафында булды. «#МыВместе» кайнар линиясенә килгән гаризалар «Медицина хезмәткәрләре волонтерлары» бөтенроссия хәрәкәте төбәк бүлекчәсе белән берлектә Гомумроссия халык фронтының яшьләр хәрәкәте тарафыннан эшкәртелде.

Казан шәһәрендә «Казан шәһәре» шәһәр округында халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе базасында 2020 елның 28 мартыннан 25 июленә кадәр 65 яшьтән өлкәнрәк ялгыз гражданнарга азык-төлек продуктлары һәм дарулар китереп бирү буенча «БЕЗ ЯРДӘМ ИТӘЧӘКБЕЗ!» кол-үзәге эшләде.

Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән 2020 елда «Ярдәм янәшә!» республика хәрәкәте оештырылды, ул халыкка ярдәм итүнең киң колачлы чараларын тормышка ашыруга юнәлтелде: халыкның якланмаган катлауларына социаль ярдәм, ирекләләр, коммерциячел булмаган иҗтимагый оешмалар һәм аерым актив кешеләрнең эшчәнлеге, бер-береңә булышу һәм ярдәм итешеп яшәү. Хәрәкәтне башлап җибәрүчеләр булып иҗтимагый оешмалар һәм волонтерлык хәрәкәтләре, оешмалар җитәкчеләре, халыкка төрлечә ярдәм күрсәтүдә актив катнашкан бизнесменнар тора. Әлеге хәрәкәт кысаларында халыкны ирекләләр хәрәкәтенә җәлеп итү буенча онлайн-платформа (помощьрядом16.рф), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ярдәм күрсәтү мобиль пунктлары эше оештырылды.

«#МыВместе» федераль проектын һәм «Ярдәм янәшә!» республика проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлык муниципаль берәмлекләр территорияләрендә 6 686 кешедән торган волонтерлар штабы оештырылды, алар 16 388 гаризаны эшкәртте. Әлеге проектлар үз эшчәнлеген туктатмады, «#МыВместе» төбәк клубы буларак эшли башлады, аның төп максаты – кешеләргә конкрет ярдәм күрсәтү, төбәк территориясендә бер-береңә ярдәм итүнең төрле рәвешләрен үстерү. 2020 елның ахырына әлеге хәрәкәттә теркәлгән ирекләләр саны 5,5 мең кешегә җитте. Барлык муниципаль берәмлекләрдә 9 меңнән артык гариза эшкәртелде. Волонтерлар ярдәме белән 55 меңгә якын продуктлар җыелмасы китереп бирелде, 46 меңгә якын кайнар ризык таратылды, 500дән артык онлайн консультация уздырылды. Ирекләләр тырышлыгы нәтиҗәсендә «#МыВместе» һәм «Ярдәм янәшә!» бер-береңә ярдәм итү акцияләре 2021 елда да дәвам итәчәк.

Волонтерлык үзәкләре ассоциациясе әгъзалары – ирекләләр төбәк ресурс үзәкләре һәм оешмалары эшчәнлекләре нәтиҗәлелегенә мониторинг уздыру йомгаклары буенча 2020 елда «Татарстан Республикасының ирекләләр мәгълүмат-

ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы Россиядә иң яхшылардан берсе дип танылды. 2020 елның 5 декабрендә Волонтерлар көнендә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов Казан Кремленең Ак залында республика волонтерлар оешмалары активистлары белән очрашты һәм 10 волонтерга Россия Федерациясе Президентының истәлекле медален, ә волонтерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче 6 коммерциячел булмаган оешмасына – Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәтен тапшырды.

## ТИРӘЛЕК, РЕАЛЬ КАПИТАЛ

### Транспорт-логистика инфраструктурасы

***«Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» милли проекты***

Проектның төп максаты – нормага туры килүче автомобиль юллары өлешен арттыру һәм юл-транспорт һәлакәтләре (алга таба – юл-транспорт һәлакәтләре) күп булган урыннар санын киметү. Татарстан Республикасында проект составына өч шәһәр агломерациясе – Казан, Чаллы һәм Түбән Кама агломерацияләре, шулай ук төбәк автомобиль юллары челтәре кергән.

2020 елда финанслауның гомуми күләме 8,6 млрд сум тәшкил итте.

*«Юл челтәре» төбәк проектын* гамәлгә ашыру кысаларында 261,6 км юл төзекләндерелде, шул исәптән:

64,9 км төбәк әһәмиятенә ия юллар, бу юлларның нормага туры килгән өлешен 47,5 % ка җиткерергә мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан финанслау күләме 715,8 млн сум тәшкил итте;

111,4 км Казан агломерациясе юллары, бу юлларның нормага туры килгән өлешен 84 % ка җиткерергә мөмкинлек бирә, шул исәптән 49,4 км – Казан шәһәре урамнары, 62,0 км – төбәк юллары. Финанслау 5 007,9 млн сум, шул исәптән 4 022,3 млн сум – федераль бюджет, 985,6 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына;

79,6 Чаллы агломерациясе юллары, бу юлларның нормага туры килгән өлешен 80 % ка җиткерергә мөмкинлек бирә, шул исәптән 17,1 км – Чаллы шәһәре урамнары, 62,5 км – төбәк юллары. Финанслау 2 014,6 млн сум, шул исәптән 1 333,5 млн сум – федераль бюджет, 681,2 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына;

5,7 км Түбән Кама агломерациясе юллары, бу юлларның нормага туры килгән өлешен 70,8 % ка җиткерергә мөмкинлек бирә. Финанслау 533,4 млн сум, шул исәптән 472,2 млн сум – федераль бюджет, 61,2 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына.

Барлыгы «Юл челтәре» төбәк проекты буенча 8 265,9 млн сум акча тотылды, шул исәптән 5 822,1 млн сум – федераль бюджет, 2 443,8 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына.

*«Татарстан Республикасы юл хуҗалыгын үстерүнең гомуми система чаралары» төбәк проекты* кысаларында шәһәр агломерацияләрендә интеллектуаль транспорт системаларын гамәлгә кертү максатларында түбәндәге эшләрне башкаруга 6 дәүләтнеке булмаган контракт төзелде:

монтажлау, эшләтеп җибәрү-көйләү эшләрен башкарып һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе төбәк мәгълүмат системасына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең административ хокук бозуларны автоматлаштырылган рәвештә теркәү үзәгенең ярдәмче системасы) һәм Татарстан Республикасы буенча автоматлаштырылган

контроль системасына кертеп, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фото-видео теркәү комплексларын урнаштыру (3 контракт);

Татарстан Республикасы территориясендә диспетчерлык, мониторинглау һәм транспортка идарә үзәге булдыру;

юл хәрәкәтенә идарә итүнең адаптив системалары светофор объектларын өстәмә җиһазландыру эшләрен башкару;

«Татарстан Республикасы транспорт системасына идарәнең бердәй платформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын булдыруның беренче этабы эшләрен башкару.

Әлеге төбәк проекты буенча федераль бюджет акчалары хисабыннан финанслауның гомуми суммасы 370,0 млн сум тәшкил итте.

Моннан тыш, 2020 елда Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы төбәкләргә пассажир транспортын яңартуда ярдәм күрсәтте. Федераль ярдәм лизинг механизмы ярдәмендә күрсәтелде – пассажир йөртүчеләргә транспорт чараларын 60 % ташлама белән сатып алу мөмкинлеге бирелде. Әлеге проект кысаларында Казан агломерациясе газ-мотор ягулыгында эшләүче 73 автобус сатып алды.

***Һава транспорты предприятиеләре эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының һава транспортын биш авиакомпания тәшкил итә: «ЮВТ АЭРО» (төбәк дәрәҗәсендә авиаочышлар ясаучы), «Тулпар Эйр», «Тулпар Экспресс», «Казан авиапредприятиесе» һәм «Авиасервис» («Бизнес авиация» сегментында эшчәнлек алып баручы).

Бу һәр өч агломерациянең (Казан, Кама, Әлмәт) һәркайсы үзенең аэропорт комплексы бар.

2020 елда Татарстан Республикасы аэропортларына 2 643,8 мең кешегә хезмәт күрсәтелгән (очып килү һәм очып китү), бу 2019 ел белән чагыштырганда 38,5 % процентка азрак (4 301,8 мең кеше).

Тармакның үсешенә этәргеч бирүче фактор булып республиканың төбәк дәрәҗәсендәге авиаочышларга субсидияләр бирү буенча федераль программаларны гамәлгә ашыруда катнашуы тора. 2020 елда Татарстан Республикасы Россия Федерациясе территориясендә авиаочышларга субсидияләр бирү программасы буенча 27 маршрутны (Казаннан – Пермьгә, Түбән Новгородка, Самарага, Оренбургка, Нижневартовскига, Сургутка, Яңа Уренгойга, Омскига, Барнаулга, Махачкалага, Чиләбегә, Ярославльгә, Воронежга, Калугага, Брянскига, Кемеровога, Волградка, Ростов-на-Донуга; Түбән Камадан – Ростов-на-Донуга, Краснодарга, Новосибирскига һәм Сургутка; Бөгелмәдән – Нижневартовскига, Сургутка, Яңа Уренгойга, Ноябрьскига, Усинскига) уртак финанслауда катнашты.

*Халыкара авиаочышлар*

2020 елда «Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыятенең маршрут челтәре 68 юнәлешне үз эченә алды, шулардан 28 халыкара (Ташкент, Дүшәнбе, Ашхабад, Баку, Худжанд, Фирганә, Минск, Бишкәк, Ош, Сәмәрканд, Анталья, Истанбул, Әл Мактаум, Пхукет, Камрань, Дубай, Гоа, Ла Романа, Будапешт, Бодрум, Занзибар, Даламан, Санья, Прага, Утапао, Франкфурт-на-Майне, Тәһран, Харбин (Екатеринбург аша).

2020 елның мартыннан Россия Федерациясе территориясеннән чит ил дәүләтләре территориясенә пассажир авиаочышларына вакытлыча чикләүләр кертелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә 2020 елның 1 августыннан аерым илләр белән халыкара авиаочышлар яңартылды. 2020 елның 20 августында халыкара авиаочышлар яңартылган пунктлар исемлегенә Казан шәһәре дә кертелде.

2020 елның 21 августыннан 31 декабренә кадәр Казан халыкара аэропортыннан очышлар Төркиягә (Истанбул, Анталья, Бодрум, Даламан) һәм Танзания (Занзибарга) ясалды.

***Тимер юл транспорты эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының тимер юл пассажир транспорты «Содружество» акционер җәмгыяте эшчәнлеге белән бәйле.

2020 елда тимер юл транспорты өлкәсенә төбәк әһәмиятендәге тарифларны дәүләт җайга салу һәм гражданнарны ташламаларга ия категорияләрен йөртү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджетыннан 353,7 млн сум бүлеп бирелгән.

2020 елгы эш йомгаклары буенча шәһәр яны тимер юл транспортында 5,03 млн пассажирга хезмәт күрсәтелгән, бу 2019 ел белән чагыштырганда 75,7 процент тәшкил итә (6,65 млн пассажир), шулардан 220,1 мең ташламага хокукы булган гражданнар, 430,8 мең – студент һәм мәктәп укучысы.

Тимер юл транспортында йөрүче пассажирлар санының кимүе республика территориясенә яңа коронавирус йогышлы авыруының таралу куркынычын туктату максатларында кертелгән чикләүләр белән бәйле, шул сәбәпле шәһәр яны пассажир поездлары хәрәкәте, субъект эчендә хәрәкәт итә торган поездлардан, шулай ук иртәнге һәм кичке сәгатьләрдә йөрүче поездлардан (чикләүләр гамәлдә булган чорда үз эшчәнлеген дәвам иткән предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләрен эш урынына китерүне тәэмин итү өчен) кала, туктатылды.

Татарстан Республикасы буенча тимер юл транспортында 15,8 млн тонна йөк ташылган (2019 ел белән чагыштырганда 101,2 процент).

***Эчке су транспорты предприятиеләре эшчәнлеге***

Республика территориясендә шәһәр яны су транспортында пассажирлар йөртү эше белән 2019 елда «Татфлот» суднолар компаниясе» АҖ һәм «Чаллы» мәгъдән булмаган материаллар производство берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте шөгыльләнде.

2020 ел навигациясе «Татфлот» суднолар компаниясе» АҖ тарафыннан түбәндәге хезмәтләр күрсәтелде:

шәһәр яны су транспортында – 209,16 мең пассажир (2019 ел белән чагыштырганда 95,5 %);

«Зеленодольск – Карамалы Тау» паром кичүендә – 102,05 мең пассажир (2019 ел белән чагыштырганда 161,7 %);

экскурсия рейсларында – 32,35 мең пассажир (2019 ел белән чагыштырганда 40,3 %).

«Чаллы» мәгъдән булмаган материаллар производство берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан шәһәр яны су транспортында 6,04 мең пассажирга хезмәт күрсәтелде (2019 ел белән чагыштырганда 86%).

Республика территориясендә «Казан (Аракчино) – Югары Ослан» паром кичүе эшләп килә, аңа «Васильево» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәт күрсәтә. 2020 елда кичү буенча 148,9 мең пассажир күчерелде (2019 ел белән чагыштырганда 74,5 %).

Татарстан Республикасы бюджетыннан ел саен җайга салына торган тарифлар куллану һәм гражданнарның аерым категорияләренә ташламалар бирү белән бәйле алынмый калган керемнәрне каплау, шулай ук җирле әһәмияттәге суднолар йөрү трассаларында юл эшләре башкаруга, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә гомуми кулланыштагы причалларга килү юллары ясау һәм аларны карап тоту өчен субсидия бүлеп бирелә.

Круиз судноларын причалга бәйләп кую операцияләрен куркынычсыз рәвештә уздыруга таләпләрне үтәү өчен Свияжск һәм Болгар причалларына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан причалларны модернизацияләү буенча проект-тикшеренү эшләре башкаруга 9,1 млн сум акча бүлеп бирелде. 2020 елның маенда Свияжск һәм Болгар причалларын модернизацияләү эшләре төгәлләнде.

***Автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы предприятиеләр эшчәнлеге***

Республиканың автомобиль транспортын төрле милек рәвешендәге эшчәнлек алып баручы 45 пассажир йөртүче, шул исәптән Татарстан Республикасының 15 эре автотранспорт предприятиесе тәшкил итә.

2020 елда республиканың пассажир автотранспорты предприятиеләренең күчмә составы 1 836 берәмлек автобус тәшкил итә, алар 721 маршрутка, шул исәптән 130 муниципальара маршрутка хезмәт күрсәтә, ул маршрутларда 505 автобус йөри.

2020 елда республиканың автотранспорт предприятиеләре тарафыннан даими маршрутларда 157,6 млн пассажирга хезмәт күрсәтелгән, бу 2019 ел белән чагыштырганда 27,2 процентка азрак, гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар әйләнеше 1 272,0 млн пассажир тәшкил иткән (2019 ел белән чагыштырганда 66,5 процент).

Төрле эшчәнлек алып баручы кече һәм урта предприятиеләрдә автомобильләр белән йөк ташуы күләме 2020 елда 8 866,5 млн тонна (2019 ел белән чагыштырганда 2 тапкырга артыграк) тәшкил итте.

***Шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы предприятиеләр эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының шәһәр электр транспорты 3 муниципаль предприятие – «Метроэлектротранс» МУП, «Электротранспорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Горэлектротранспорт» МУП, «Әлмәт троллейбус идарәсе» МУП эшчәнлеге белән бәйле.

2020 елда шәһәр электр транспорты предприятиеләренең хәрәкәт итүче составы 488 берәмлек тәшкил итте, шул исәптән 271 трамвай, 202 троллейбус, 15 метрополитен поезды.

37 маршрут буенча пассажирлар йөртү оештырылган.

2020 елда шәһәр электр транспортында 78,3 млн пассажир йөрде (2019 ел белән чагыштырганда 75,4 процент). 2020 елда шәһәр электр транспорты предприятиеләрендә пассажирлар йөртүдә әйләнеш 333,6 млн пассажир тәшкил иткән (2019 ел белән чагыштырганда 73,5 процент).

***Гомуми кулланыштагы автомобиль һәм шәһәр электр транспортында ташламалы категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында***

2020 елның 1 гыйнварыннан 40 муниципаль берәмлектә җәмәгать транспортында йөргән өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы гамәлгә кертелде.

Бер ел эчендә 45 муниципаль берәмлектә 3,2 млн ташламалы транспорт картасы тулыландырылган, 81,5 млн тапкыр ташламалы категорияле гражданнар транспортта йөргән.

2020 елда 45 муниципаль берәмлектә аерым категория гражданнар өчен җәмәгать транспортында йөрү хезмәтен күрсәтүдән тигез хокуклы файдалана алуын тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен үтәүгә 787,8 млн сум күләмендә субвенция түләнгән.

***Юл инфраструктурасын үстерү***

Татарстан Республикасының федераль һәм төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы 14 727,4 км тәшкил итә, шул исәптән федераль юллар – 1 075,4 км, төбәктәге юллар – 13 652,0 км.

Камилләштерелгән каты катлаулы федераль һәм төбәк әһәмиятендәге гомум файдаланудагы автомобиль юлларының озынлыгы – 12 772,4 км (86,7 %), күчү тибындагы катламлы – 1 371 км (9,3 %), грунт юллар – 584,0 км (4,0 %).

Гомуми файдаланудагы юллар челтәренең тыгызлыгы 1 000 кв км территориядә 217,1 км тәшкил итә.

Төбәк автомобиль юлларының күп өлеше түбән (IV һәм V) категориядәге юлларны тәшкил итә – 11 892,0 км (яисә 87,1%).

Моннан тыш, республика шәһәрләрендәге урам юллары һәм торак пунктлары юллары челтәре (муниципаль милектәге) озынлыгы – 24 831 км.

2020 елда бүлеп бирелгән акчалар хисабына Төбәк автомобиль юлларында юл эшләре программасы нигезендә түбәндәгеләр эшләнде:

түбәндәгеләр төзелде:

61,7 км төбәк автомобиль юллары;

13 күпер;

4 юлүткәргеч;

түбәндәгеләр төзекләндерелде:

371,6 км гамәлдәге төбәк челтәре;

6 күпер;

10 авыл торак пункты 27 км озынлыктагы каты өслекле юллар белән тоташтырылды;

авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ярдәм итү өчен 19,2 км озынлыкта 30 гаилә фермаларына һәм терлекчелек комплексына керү юллары төзекләндерелде;

46 мәктәп маршрутында транспорт-эксплуатация шартлары яхшыртылды.

*Муниципаль юлларда юл эшләре*

Республиканың торак пунктларында муниципаль юл-урам челтәре торышын яхшырту максатыннан түбәндәге эшләр башкарылды:

144,7 км озынлыктагы торак пунктларда (вак таш-ком катнашмасы) юл-урам челтәрен нормага туры китерелде;

түбәндәгеләр төзекләндерелде:

торак пунктларның гомуми озынлыгы 89,0 км булган гамәлдәге асфальт-бетон катламы;

юлларны төзекләндерү муниципаль юл фондлары хисабына гомуми озынлыгы 120 км юллар.

*Гражданнарның бакчачылык һәм дача коммерциячел булмаган оешмаларына керү юлларын төзекләндерү*

2020 елда «Татарстан Республикасында 2013–2025 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында республиканың 12 муниципаль районында бакчачылык ширкәтләренә кертү юлларын төзекләндерү эшләре башкарылды.

*Федераль автомобиль юллары*

2020 елда Татарстан Республикасында федераль әһәмияттәге автомобиль юлларын һәм ясалма корылмаларны карап тоту, төзекләндеү, капиталь төзекләндеү, төзү һәм реконструкцияләү өчен федераль бюджеттан юл эшләрен финанслау күләме 10 142,9 млн сум тәшкил итте.

«Идел» М-7 автомобиль юлының Чувашстан Республикасы чигеннән алып Иннополис шәһәренә борылып керүгә кадәр автомобиль юлын реконструкцияләү эшләре дәвам итте, 757 км да Свияга елгасы аша күперне реконструкцияләү эшләре алып барылды, Казан шәһәренә кермичә әйләнеп узу 796 км участогында төрле дәрәҗәдә транспорт чишелешләре төзү буенча проект эшләре алып барылды, Чаллы шәһәрендә 1 048+300 км, 1 052+600 км участокларында төрле дәрәҗәләрдә транспорт чишелешләре проектлау эшләре алып барылды, сул якка борылып төшү мөмкинлеге булган 1 014 км участогында һәм 1 017 км участогында бер дәрәҗәдә транспорт чишелешләре төзү эшләре тәмамланды.

***«Каршылыкларсыз юл» флагман проекты***

«Каршылыкларсыз юл» проекты Татарстан Республикасында зур тизлектә хәрәкәт итү өчен өстәмә юл, ул Казан шәһәрен, «Казан» халыкара аэропортын, Алексеевск штп, Чистай шәһәрен, Кама Аланы штп, Түбән Кама шәһәрен, «Бигеш» аэропортын, Чаллы шәһәрен тоташтырачак.

2020 елда Юл эшләре программасы кысаларында Түбән Кама муниципаль районында 19,5 млн сумга «Чистай – Түбән Кама» (72+092 км –72+723 км) һәм 107,1 млн сумга (40+860 км – 43+556 км, 44+373 км –45+129 км) автомобиль юлын төзекләндерү эшләре уздырылды.

**Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык**

«Торак» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елда 2 680,1 мең кв метр торак файдалануга тапшырылды.

2020 ел йомгаклары буенча бәяләүләр буенча бер кешегә гомуми торак мәйданы 27,7 кв метр тәшкил итә. 2021 елга 2 670 мең кв метр торак булыр дип планлаштырыла.

Торак төзелеше программасын үтәүне тәэмин итү максатларында, даими режимда түбәндәге ярдәмче программалар буенча торак йортлар төзелеше барышын тикшереп тору һәм күзәтү алып барыла:

*Күпфатирлы инвестицион торак*

2020 елда гомуми мәйданы 1 010,9 мең кв метр булган 168 күпфатирлы йорт файдалануга тапшырылды. Күпфатирлы инвестицион торак программасы 12 муниципаль берәмлектә – Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә, Әлмәт, Арча, Баулы, Буа, Югары Ослан, Биектау, Алабуга, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч муниципаль районнарында кертелгән.

*Азкатлы йортлар төзү программасы (шул исәптән, шәхси торак төзелеше)*

2020 елда республикада гомуми мәйданы 1 452,7 мең кв метр булган 10 840 шәхси торак йорт төзелгән һәм файдалануга тапшырылган.

*Социаль ипотека*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге 1241 номерлы карары белән расланган «2020 елга Татарстан Республикасы гражданнарын торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме» программасы нигезендә 2020 елда гомуми мәйданы 216,5 мең кв метр булган 3 767 фатирлы 153 торак йорт файдалануга тапшырылган.

Республикада социаль ипотека программасына яшь гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренең теркәлгән тораклары булмаган затларны, радиацион аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны, Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән территорияләрне, күченеп килергә мәҗбүр булган затларны, 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү, запастагы хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар өчен торак төзү буенча федераль механизмнар кертелгән.

*5 һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү*

Чаралар торак сатып алу өчен субсидияләр бүлеп бирүгә яисә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне шәхси торак белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән. 2007–2019 елларда республика буенча җыелма исемлеккә кертелгән 444 күпбалалы гаилә торак белән тәэмин ителде, финанслау күләме 1 322,1 млн сум тәшкил итте. 2020 елда 46 гаилә (343 кеше) торак белән тәэмин ителде, финанслау күләме 211,9 млн сум, гомуми мәйданы – 3 863,95 кв метр. 2021 елда 45

күпбалалы гаиләне торак белән тәэмин итү планлаштырыла, финанслауның гомуми күләме 220,4 млн сум тәшкил итәчәк.

*«Россия Федерациясе гражданнарын уртача бәядән уңайлы торак белән тәэмин итү һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү» Россия Федерациясе федераль дәүләт программасының «Гражданнарны торак белән тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасы кысаларында граждан категорияләрен торак белән тәэмин итү*

2006–2019 елларда ведомство максатчан программа кысаларында 1 832,4 млн сумга 1 229 субсидия рәсмиләштерелде. 2020 елда федераль бюджеттан 78,2 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелде, шул акчалар исәбеннән Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан 23 субсидия рәсмиләштерелде, шул исәптән:

Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәсендә радиация нурланышы алган гражданнарга 28 млн сумга (9 дәүләт торак сертификаты);

билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күчеп килүче гражданнар дип танылучыларга 46,1 млн сумга (12 дәүләт торак сертификаты);

Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән күчеп кайтучы гражданнарга 4,2 млн сумга (2 дәүләт торак сертификаты).

2021 елда 22,4 млн сумга 9 субсидия рәсмиләштерү планлаштырыла.

*Аренда торагы*

Программа Татарстан Республикасы шәһәр һәм районнарын үстерүгә юнәлтелгән. Аренда торагын төзү өчен яңа җитештерү мәйданчыклары, махсус икътисадый зоналар, сәнәгать парклары булдыру, IT-өлкәне, нефть химиясе сәнәгатен үстерү, шулай ук бюджет өлкәсе белгечләренә (табиблар, укытучылар, мәдәният өлкәсе, спорт, көч структуралары хезмәткәрләре һ.б.) кискен кытлык булган урыннар өстенлекле булып тора. Аренда торагы предприятие хезмәткәрләренә дә, чакырылган белгечләргә дә – бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә бирелә.

2010–2020 елларда гомуми мәйданы 184,9 мең кв метр булган 3 230 фатирлы 366 аренда торагы файдалануга тапшырылды, шул исәптән 2020 елда – гомуми мәйданы 7,2 мең кв метр булган 106 фатирлы 69 торак йорт.

2021 елда аренда торагы программасы кысаларында гомуми мәйданы 11,2 мең кв метр булган 190 фатирлы 69 торак йорт төзү планлаштырылган.

*«Безнең ишегалды» республика программасы*

2020 елда Татарстанда «Безнең ишегалды» – яңа социаль программа эшли башлады, аның максаты – республиканың барлык күпфатирлы йортларында барлык ишегалларын төзекләндерү.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы муниципаль берәмлекләр һәм «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе белән берлектә программаны формалаштыру кысаларында ишегалды территорияләренә инвентаризация уздырды, аның нәтиҗәләре буенча 9 546 ишегалдының 6 775 сына комплекслы ремонт таләп ителә (49,6 млн кв. метр).

Программа кысаларында объектлар исемлеге бүлеп бирелгән финанслау лимитын исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр гаризаларына нигезендә төзелә.

2020 елда «Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыру кысаларында 1 091 ишегалды территориясе төзекләндерелде. Финанслау күләме 8,0 млрд сум тәшкил итә.

2021 елга программа килештерү стадиясендә, финанслауга 8,0 млрд сум күләмендә лимит билгеләнде.

Өстәмә рәвештә dvor.tatar порталы эшли башлады, анда ишегалды территорияләренең эшләнгән план-схемалары турында җәмәгать фикер алышуы уздырыла. Шулай ук порталда төзекләндерүнең интерактив картасы ярдәмендә һәр ишегалдын кайсы елда төзекләндерү планлаштырылган икәнен белергә була.

*Җәмәгать инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь төзекләндерү*

*Халыкка беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү эшен камилләштерү*

2012 елдан башлап фельдшер-акушерлык пунктларын (алга таба – ФАП), патологоанатомия бүлекләрен төзү һәм сәламәтлек саклау объектларын капиталь төзекләндерү буенча чаралар тормышка ашырыла.

2020 елда 51 сәламәтлек саклау объекты, шул исәптән 43 ФАП һәм 7 табиблык амбулаториясе, 1 гомуми практика табибы офисы төзелде, 8 сәламәтлек саклау объекты капиталь төзекләндерелде һәм өстәмә җиһазландырылды. Гомуми финанслау күләме 330 млн сум тәшкил итә.

«Сәламәтлек» илкүләм проектының «Балалар сәламәтлеге системасын үстерү» федераль проекты буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургиясе үзәген төзү эшләре алып барыла, төзелеш эшләрен 2021 елда тәмамлау планлаштырыла.

Шулай ук программадан тыш берничә объект төзелде:

«Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасы, адресы: Казан шәһәре Җиңү проспекты урамы, 83 йорт (икенче чираты);

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Әлмәт филиалы радиология корпусы;

«Әлмәт шәһәренең перинаталь үзәкле балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия корпусы;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Чаллы филиалы бинасы.

*Мәгариф объектларын капиталь төзекләндерү һәм төзү*

2020 елда 3,1 млрд сумга 172 объект, шул исәптән 39 мәктәп (36 муниципаль, 1 кадет, 2 коррекция), 89 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (шул исәптән 2 сендә төзекләндерү-реставрация эшләре башкарылды) төзекләндерелде, 44 объектта функциональ зоналар төзекләндерелде. 2021 елда 2,0 млрд сумга 213 объектны

төзекләндерү планлаштырылган.

5 030 урынга исәпләнгән 27 мәктәпкәчә белем бирү объекты (шул исәптән «Демография» илкүләм проекты кысаларында 5 030 урынга исәпләнгән 22 балалар бакчасы) һәм «Мәгариф» (1 224 урынга исәпләнгән 2 мәктәп) һәм «Торак һәм шәһәр мохите» (1 224 урынга исәпләнгән 2 мәктәп) илкүләм проектлары кысаларында 4 896 урынга исәпләнгән 4 мәктәпне кертеп, 8 798 укучыга исәпләнгән 10 гомуми белем бирү объекты төзелде.

*Ресурс үзәкләрен капиталь төзекләндерү*

Татарстан Республикасында 2014 елдан башлап һөнәри белем бирү ресурс үзәкләрен капиталь төзекләндерү программасы гамәлгә ашырыла. 2020 елда 681,4 млн сумга 17 объект капиталь төзекләндерелде.

*Тулай торакларның уку корпусларын капиталь төзекләндерү*

Программа республика уку йортлары студентлары өчен уңайлы яшәү шартлары һәм аларның уку процессына керәп китүе һәм үз мөмкинлекләрен тормышка ашыра алуы өчен заманча шартлар булдыруны тәэмин итү максатларында эшли. 2020 елда 190,15 млн сумга 3 объект төзелде.

*Авыл мәктәпләрендә санитария узеллары биналарын капиталь төзекләндерү*

Программада авыл мәктәпләрендәге санитария узеллары биналарын санитария нормалары нигезендә җиһазландыру, эчке һәм тышкы суүткәргечләрне һәм канализацияне төзекләндерү, табигый вентиляция урнаштыру каралган. 2020 елда 111,1 млн сумга 271 объект төзекләндерелде.

*Яшүсмерләр клублары челтәрен капиталь төзекләндерү*

Яшүсмерләр клублары челтәрен капиталь төзекләндерү программасы 2013 елдан тормышка ашырыла. Шушы чор эчендә 2020 ел программасын исәпкә алып, республикада 141 яшүсмерләр клубы төзекләндерелде. Инженерлык челтәрләре алмаштырылды, санузеллар, юыну бүлмәләре, дәрес бүлмәләре һәм заллар ясалды, фасадлар һәм биналарга керү урыннары төзекләндерелде, җиһазлар яңартылды. 2020 елда 100 млн сумга 16 объект төзекләндерелде.

2021 елда 100 млн сумга 11 объектны төзекләндерү планлаштырыла.

*Балаларны сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү*

Программа 2014 елдан бирле тормышка ашырыла. 2020 елда 7 объект капиталь төзекләндерелде, 7 объект төзелде, 1 объект реконструкцияләнде. Финанслауның гомуми күләме 1 160,0 млн сум тәшкил итте.

*«Универсаль спорт мәйданчыклары төзү» программасы*

2020 елда 93 объект, шул исәптән 86 универсаль спорт мәйданчыгы, мебель, инвентарь һәм җиһазлар белән 6 блоклы модульле чаңгы базасы, 20х40 метрлы каркас-тент капламы булган 1 ябык футбол манежы һәм административ бина төзелде. Гомуми финанслау күләме 427,4 млн сум тәшкил итте.

«Спорт – тормыш нормасы» федераль проекты кысаларында түбәндәге эшләр башкарылды:

түбәндәгеләр сатып алынды:

Аксубай шәһәр тибындагы поселогы һәм Аксубай муниципаль районында футбол кыры өчен ясалма түшәү комплекты;

Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре, Белоглазов урамы, 62а йорт адресу буенча урнашкан «Футбол буенча спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесенең футбол кыры өчен ясалма түшәү комплекты;

Казан шәһәре, Гагарин урамы, 56 йорт адресы буенча урнашкан Казан шәһәренең «Тасма» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе стадионы өчен җиңел атлетика йөгерү юллары комплекты;

түбәндәгеләр сатып алынды һәм монтажланды:

Чаллы шәһәре, Рәис Беляев проспекты, 60 (13-12) йорт адресы буенча урнаштыру өчен ясалма футбол кыры комплекты;

Казан шәһәре, Рихард Зорге урамы, 71 адресы буенча урнаштыру өчен ясалма футбол кыры комплекты;

түбәндәгеләр төзелде:

Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында универсаль спорт залы;

Чаллы шәһәрендә ябык йөзү бассейны;

Чаллы шәһәрендә ясалма боз җәелгән ябык каток;

Түбән Кама шәһәрендә тренировкалар өчен футбол манежы.

Моннан тыш, 2020 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түбәндәгеләр төзелде һәм эксплуатациягә тапшырылды:

5 универсаль спорт залы (Буа шәһәре, Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылы, Мамадыш шәһәре, Сарман авылы, Тукай муниципаль районының Түбән  Суыксу авылы);

бассейнлы спорт комплексы (Нурлат муниципаль районы);

2 ябык йөзү бассейны (Биектау авылы һәм Мөслим авылы);

тренировкалар өчен футбол-регби манежы (Казан шәһәре, Чуйков урамы);

2 тренировкалар өчен футбол манежы (Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре);

2 ясалма боз җәелгән ябык каток (Балык Бистәсе муниципаль районы, Лаеш шәһәре).

*Мәдәни билгеләнештәге объектлар төзү һәм төзекләндерү*

Муниципаль берәмлекләрдә тормыш сыйфатының дәрәҗәсен күтәрү, халыкның мәдәни хәзинәләребездән файдалана алуын һәм үзенең иҗади мөмкинлекләрен күрсәтә алуын тәэмин итү максатларында мәдәни билгеләнештәге объектларны төзү һәм төзекләндеү  программалары тормышка ашырыла.

2020 елда гомуми суммасы 197,8 млн сумга 12 мәдәни объект төзелде һәм 427,0 млн сумга 37 мәдәни объект төзекләндерелде.

«Мәдәният» илкүләм проектының «Мәдәни мохит» федераль проекты кысаларында 8 авыл мәдәният йорты төзелде.

«Мәдәниятне һәм туристлыкны үстерү» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәре, Низаметдинов урамы, 29 йорт адресы буенча урнашкан Чаллы дәүләт татар драма театры өчен бинаны реконструкцияләү эшләре төгәлләнде.

Шулай ук программадан тыш чаралар да тормышка ашырылды:

түбәндәге төзекләндерү-реставрация эшләре:

Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарае (Дербышки поселогы, Совет урамы, 18 йорт);

«Созвездие-Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә булышлык күрсәтү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе бинасы (Казан шәһәре, Гладилов урамы, 49 йорт);

«Казан» милли мәдәни үзәге бинасында Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең зур китапханәсен урнаштыру (уку залы булган);

Тимерюлчылар мәдәният сарае бинасын капиталь төзекләндерү эшләре (Казан шәһәренең Юдино торак массивында).

2021 елда «Мәдәният» илкүләм проектының «Мәдәни мохит» федераль проекты кысаларында 3 авыл мәдәният йорты (Кукмара муниципаль районының Чишмә-Баш һәм Аш-Бузи авылында, Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авылында) һәм 2 мәдәни үсеш үзәге (Алабуга һәм Зеленодольск шәһәрләрендә) төзү планлаштырыла.

«Мәдәниятне һәм туристлыкны үстерү» дәүләт программасы кысаларында Чаллы шәһәренең «Мастеровые» рус драма театры төзү планлаштырыла.

Шулай ук «Казан Богородица монастыре комплексын саклау кысаларында Казан Изге Ана иконасы соборын торгызу (яңадан төзү)» программадан тыш объект буенча эшләрне төгәлләү планлаштырылган.

*Сыер абзарларын, яшелчә саклау урыннарын, машина-трактор паркларын, ындыр табакларын капиталь төзекләндеү һәм силос-сенаж траншеяларын төзү*

2020 елда 171 сыер абзары, 67 машина-трактор паркы, 7 яшелчә-бәрәңге саклау урыны, 128 ындыр табагы хуҗалыгы, 12 тавык фермасы, 12 ат фермасы капиталь төзекләндерелде, 77 силос-сенаж траншеясы (финанслауның гомуми суммасы 200 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 60 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 140 млн сум.), 6 сыер абзары һәм 1 сарык фермасы (финанслауның гомуми суммасы 333,3 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 100 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 233,3 млн сум) төзелде.

*Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен капиталь төзекләндерү*

Республиканың социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру максатында 2015 елдан социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен капиталь төзекләндерү программасы тормышка ашырыла. Әлеге программа эшли башлаган вакыттан 2019 елга кадәр республикада 153 объект төзекләндерелде.

2020 елда 37 объект төзекләндерелде (121,3 млн сум бүлеп бирелде).

6 интернат-йорт;

2021 елда 100,0 млн сумга 29 объектны төзекләндерү планлаштырыла.

*Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирлекләре советлары биналарын төзү һәм капиталь төзекләндерү*

2020 елда 11 объект төзелде, гомуми суммасы 100 млн сумга 21 объект төзекләндерелде.

*Татарстан Республикасы муниципаль архивлары биналарын капиталь төзекләндерү*

2020 елда 50,0 млн сумга 7 муниципаль архив бинасы төзекләндерелде.

*Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе һәм Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре карамагындагы учреждениеләр биналарын капиталь төзекләндерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру кысаларында 2013–2019 елларда 259 объект капиталь төзекләндерелде. 2020 елда 31 муниципаль районда 41 объектка 60,0 млн сумга капиталь ремонт ясалды.

2021 елга гомуми бәясе 50 млн сум булган 25 объектта эшләр планлаштырылган.

*Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы карамагындагы биналарны капиталь төзекләндерү*

2020 елда 150,0 млн сумга 3 объект төзекләндерелде.

*Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы урманчылыклар, кишәрлек урманчылыклары һәм урман хуҗалыклары биналарын капиталь төзекләндерү*

2020 елда урманчылыкларның 11 бинасы, янгын-химия станциясе өчен 2 гараж һәм «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең урман хуҗалыгы һәм экология факультеты бинасы төзекләндерелде, гомуми суммасы – 70,5 млн сум.

*Россия милли гвардия гаскәрләре федераль гаскәрләре идарәсе объектларын капиталь төзекләндерү*

2020 елда 111,4 млн сумга 14 объект төзекләндерелде.

*«Уңайлы мохит» программасы*

2020 елда мәгариф өлкәсенең 12 объекты (9 муниципаль берәмлектә), шул исәптән 5 гомуми белем бирү, 5 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм 2 балаларга өстәмә белем бирү объекты җайлаштырылган. Программаны финанслауның гомуми күләме 2020 елда 16,5 млн сум тәшкил итте, шуларның 9,57 млн сумы федераль бюджет акчалары исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 6,93 млн сум.

## Торак-коммуналь хуҗалык

*Күпфатирлы йортларга идарә*

Республикада торак фондының мәйданы 106,54 млн кв. м тәшкил итә, шуның 93,6% ы шәхси милектә (99,7 млн кв. м), 4,79 - муниципаль (5,1 млн кв. м), 1,61 - дәүләт (1,7 млн кв. м) милкендә.

17 534 күпфатирлы йорттан (алга таба - КФЙ) 61 111,4 мең кв. м торак биналар мәйданы:

84,75 % (14 860 КФЙ) идарәче компанияләр идарәсендә;

13,39 % - торак милекчеләре ширкәтләре һәм торак-төзелеш кооперативлары идарәсендә (2 348 КФЙ);

1,86% - турыдан-туры идарәдә (326 КФЙ).

Идарәче компанияләр эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә КФЙ идарәсе эшчәнлеге лицензия нигезендә гамәлгә ашырыла. 2021 елның 1 гыйнварына - 328 идарәче компаниянең КФЙ га идарә итүгә лицензиясе бар.

«Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы тарафыннан «Белемле кулланучы мәктәбе» халыкка торак хуҗалыгы турында мәгълүмат бирү буенча эш алып барылды. Халыкның төрле төркемнәрен максатчан укытуның мультиформат алымнары эшләнде. КФЙ биналарының милекчеләренә түләүсез укыту һәм консультация бирү, шул исәптән дистанцион оештырылды. «Белемле кулланучы мәктәбе» программасы буенча 546 КФЙ рәисе, КФЙ советы әгъзалары һәм актив торак милекчесе укыды.

*Күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү*

Тармакның төп проблемаларыннан берсе – торак фондының нык дәрәҗәдә тузган булуы. 2020 елда Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары уртак милегенә капиталь ремонт уздыруга финанслауның гомуми күләме 6,47 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 1,36 млрд сум, муниципаль берәмлекләр бюджеты акчалары – 1,08 млрд сум, гражданнар акчасы – 4,03 млрд сум. Гомуми мәйданы 6,4 млн кв метр булган 1 063 күпфатирлы йортта капиталь ремонт үткәрелде, аларда 243 меңнән артык граждан яши.

*«Яшәү өчен яраксыз торак фондын эзлекле рәвештә киметүне тәэмин итү» федераль (төбәк) проекты*

Татарстан Республикасы территориясендә «Яшәү өчен яраксыз торак фондын эзлекле рәвештә киметүне тәэмин итү» федераль проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 29 мартындагы 242 номерлы карары белән 2019–2025 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасы расланды.

2020 елда 226 кеше күчерелде, 2 176,4 кв метр авария хәлендәге торак бетерелде. Чараларны финанслау күләме 144,6 млн сум тәшкил итте, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды акчалары

исәбеннән – 71,66 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 72,96 млн сум.

*ТКХ объектларын модернизацияләү*

*Блок-модульле пар казаннары урнаштыру, газ белән тәэмин итү инженер челтәрләрен төзү һәм хосусый җылылык системасына күчү*

Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарында һәр фатирны аерым җылыту системасына һәм блоклы пар казаннары урнаштыруга күчү программасы 2005 елдан бирле ягулык-энергетика ресурсларын рациональ куллану, югары чыгымнар таләп итүче икътисадый яктан отышлы булмаган пар казаннарын бетерү, челтәрләрдә югалтуларны киметү, республика шәһәрләре һәм районнары җылылык белән тәэмин итү системаларының нәтиҗәлелеген арттыру, алдынгы энергиясаклагыч технологияләр кертү, халыкның яшәү шартларын яхшырту, шулай ук кайнар су белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтү максатларында тормышка ашырыла.

2020 елда әлеге максатларга 162,2 млн сум акча тотылды, 1 353 фатир хосусый җылыту системасына күчерелде, 29 блок-модульле пар казаннары урнаштырылды, 13,8 км тоташтыргыч, боҗралы һәм фасад газүткәргечләре төзелде.

*Бюджет өлкәсе объектларын җылылык белән тәэмин итүче пар казаннары биналарында казаннарны алыштыру*

2014 елдан социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итә торган пар казаннарының ышанычлы һәм нәтиҗәле эшләвен арттыру, электр энергиясе ресурсларын куллануны киметү максатларында социаль-мәдәни өлкә объектларындагы пар казаннары биналарында казаннарны алыштыру программасы тормышка ашырыла. 2020 елда финанслау күләме 69,9 млн сум тәшкил итте, 65 объектта пар казаннары җиһазлары монтажланды, 43 муниципаль берәмлектә 138 казан алмаштырылды.

*Авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итү*

Татарстан Республикасы торак пунктларында хуҗалык һәм эчәр су белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итүнең сыйфатын арттыру максатларында «Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү» программасы тормышка ашырыла.

2020 елда әлеге чыгымнарга 589,3 млн сум күләмендә финанслар бүлеп бирелде, 153,5 км суүткәргеч челтәре, 28 су башнясы, 21 артезиан скважинасы төзелде (реконструкцияләнде).

Татарстан Республикасында 3 000 су алу җайланмасы кулланылышта, шул ук вакытта хуҗалык итүче субъектлар 1 220 су алу чыганагыннан лицензия буенча су ала, шулардан 996 лицензия авыл җирлекләрендә халыкны су белән тәэмин итү өчен бирелгән, ә калган лицензияләр хуҗалык алып бару өчен су белән тәэмин итүгә яисә предприятиеләрне техник яктан су белән тәэмин итүгә бирелгән. Судан файдалануга килешү төзелмәгән чишмәләр саны – 306 берәмлек.

*Чистарту корылмаларын модернизацияләү һәм канализация челтәрләрен капиталь төзекләндерү*

2020 елда «Чистарту корылмаларын модернизацияләү һәм канализация челтәрләрен капиталь төзекләндерү» программасы чараларына 317,1 млн сум күләмендә финанслар бүлеп бирелде, 26 юынтык суларны агызу объекты һәм канализация челтәрләре төзекләндерде.

*Коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтләрендә каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар булдыру һәм су белән тәэмин итү*

2020 елга программаны тормышка ашыру өчен 100 млн сум бүлеп бирелде. Программа кысаларында 55 су җыю савытларын алмаштырды, 23 артезиан скважинасы бораулганды, 23 насос монтажланды, 62 коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтендә (алга таба – КББШ) 11,45 км суүткәргеч салынды, контейнерлар кую өчен 58 мәйданчык әзерләнде, 159 контейнерны урнаштыру, 43 мәйданчык бункерлар кую өчен әзерләнде һәм 19 муниципаль районда 100 КББШдә 63 бункер урнаштырылды.

*Җәмәгать урыннарын үстерү*

«Шәһәрдә уңайлы мохит формалаштыру» өстенлекле проекты кысаларында җәмәгать урыннарын үстерү программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2020 елда 2 768,4 млн сумга 61 объект төзекләндерелде, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 1 231,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 1 536,6 млн сум.

Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр арасында уңайлы шәһәр тирәлеген булдыру буенча иң яхшы проектларның бөтенроссия конкурсы кысаларында 2020 елда конкурста җиңүче 3 муниципаль берәмлекнең проектлары тормышка ашырылды, конкурс җиңүчеләре булып – Җиңү һәм хезмәт даны паркы (Баулы шәһәре), «Энергетик» мәдәният йорты каршындагы үзәк мәйдан (Зәй шәһәре), Экстрим-парк (Лаеш шәһәре) танылды. Проектларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан 185 млн сум (грант) бүлеп бирелде. Проектларны гамәлгә ашыру буенча барлык чаралар 2020 елда конкурс шартлары нигезендә тәмамланды. 2019 елгы конкурс кысаларында Мамадыш шәһәре «Табигать-спорт комплексы» проекты белән конкурста җиңүче булды, ул 60 млн сум күләмендә грант алды (2019 елда эшләрнең бер өлеше тәмамланды).

*Авыл торак пунктларында яктырту җиһазларын төзекләндерү программасы*

Электр энергиясеннән сакчыл һәм нәтиҗәле файдалану җиһазларын кулланышка кертү хисабыннан электр энергиясен куллануны киметү, халыкка яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру һәм республикада урамнарны яктыртуны нормада билгеләнгән таләпләргә китерү максатларында 2014 елда яктырту җиһазларын төзекләндерү программасы эшли башлады.

2020 елда программаны финанслауга 225 млн сум бүлеп бирелде. 252 км электр белән тәэмин итү линиясе төзелде, 17 электр энергиясен исәпкә алу һәм көйләү приборы, Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегендә (537 торак пунктта) 12 715 яктырткыч алмаштырылды һәм куелды.

*Хосусый инвестицияләр җәлеп итү*

Торак-коммуналь хуҗалыкка хосусый инвестицияләр җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала:

коммуналь инфраструктура системаларын, шәһәр җирлекләрен һәм шәһәр округларын җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемаларын комплекслы үстерү программаларын системалы актуальләштерү;

торак-коммуналь хуҗалык объектларын җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вакытында теркәү һәм хуҗасыз объектларга хокукларны рәсмиләштерү;

җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә тарифларны җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чараларын гамәлгә ашыру;

унитар предприятиеләр нәтиҗәлелегенең расланган критерийлары нигезендә аларга идарә нәтиҗәсез дип танылган дәүләт һәм муниципаль предприятиеләр милкен концессиягә тапшыру.

Республикада су белән тәэмин итү, юынтык суларны агызу һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә 154 концессия килешүе төзелде һәм эшләп килә, шул исәптән 36 – су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә, 110 – җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә, 8 – каты коммуналь калдыкларны эшкәртү өлкәсендә.

2020 елда Татарстан Республикасында су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә 4 оешманың – «Водоканал» МУП (Казан шәһәре), «Чаллыводоканал» ҖЧҖ (Чаллы шәһәре), «Әлмәт-Водоканал» АҖ (Әлмәт муниципаль районы), «Бөгелмә-Водоканал» ҖЧҖ (Бөгелмә муниципаль районы) инвестиция программалары расланды.

Башлангыч мәгълүматларга караганда, 2020 елда су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә инвестицион программалар буенча үтәлеш 939,8 млн сум тәшкил итә, шулардан су белән тәэмин итү буенча – 127,2 млн сум, юынтык суларны агызу буенча – 812,6 млн сум.

## Татарстан Республикасында агломерацияләрне үстерү

***Казан агломерациясе***

Казан агломерациясендә төп үзгәрешләр тотрыклы структура булдыручы транспорт каркасын төзүгә кагылышлы алып барылачак. Моңа тизлекне сакларга мөмкинлек бирүче автомобиль юллары, Казан янында әйләнгеч яңа автомобиль һәм тимер юллары төзү, шулай ук Гребени авылы янында Идел аша стратегик күпер салу кирәк. Казан шәһәреннән көньяктарак Идел аша күпер салу Лаеш районын үстерүгә мөмкинлекләр ачачак. Иделнең уң ярында урнашкан Югары Ослан муниципаль районы агломерация процессларында актив катнаша. Экосистеманы саклап калу – «яшел» технологияләр, аз катлы йортлар төзү, рекреация һәм ял оештыру функцияләрен файдалану бу территорияне үзләштерүнең төп шарты булып тора.

Үзгәртеп корулар түбәндәге проектлар кысаларында алып барыла:

*«Казан шәһәрендә тимер юл боҗра хәрәкәтен оештыру»*. Проектны гамәлгә ашыруның якынча бәясе 22,4 млрд сум тәшкил итә. Түбән Новгородның «Росжелдорпроект» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Нижегороджелдорпроект» проект институты тарафыннан 15 млн сумга проектка техник-икътисадый бәяләү

эшләнде. Башлангыч этапта Юдино ст. – Дәрвишләр ст. һәм Яңа Аракчино ст. районындагы съезд участогында өченче юл төзү планлаштырыла, бу «Казан» халыкара аэропорты – Казан 1 ст. – Казан 2 ст. бару һәм кайту маршруты буенча шәһәр яны поездларының хәрәкәтен тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

«Алабуга» МИЗ территориясендә Kastamonu компаниясенең МДФ-плитәләр җитештерү заводы динамик рәвештә үсә. «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ продукциясенең 60% ы Россиядә сатыла, 40% - Европа, Азия һәм Латин Америкасының 27 иленә экспортка җибәрелә.

2020 елның февралендә Kastamonu компаниясе КМ1 стандартына туры килү декларациясен алды. Документ МДФ-плитәләрнең КМ1 ут чыдамлыгы классына Fire-resistance гаризасы белән туры килүен раслый, аның нигезендә төзелеш материалы януның, ялкынсынуның, төтен ясалуының һәм агулылыкның түбән күрсәткечләренә ия. Мондый күрсәткечләр җитештерүдә махсус утка чыдам өстәмәләр куллану исәбенә ирешелә.

2020 елның мартында Kastamonu компаниясе Урман попечительләр советының FSC сертификатын алды, ул җитештерүченең Россиядә сертификацияләнгән үзагач ташу чылбыры стандарты таләпләренә туры килүен раслый. FSC сертификациясе үзагач җитештерүче урман хуҗалыгының урман торгызу эшләрен башкаруын һәм урман сертификациясенең өстәмә экологик һәм социаль критерийларын үтәвен аңлата.

«С.П.Титов исемендәге Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» ХЯАҖ Россия целлюлоза-кәгазь сәнәгатенең иң эре предприятиеләре унлыгына керә. Предприятие картон-кәгазь фабрикасын модернизацияләү буенча озак сроклы проектны гамәлгә ашыра. 2020 елда кәгазь фабрикасын кәгазь - продукциянең бәдрәф һәм санитария-гигиена төрләре нигезен арттыру буенча модернизацияләүне проектлау башкарылган. Бу проектны гамәлгә ашыру 2021 – 2023 елларда башкарылачак һәм кәгазь фабрикасының җитештерү куәтләрен 15 %ка кадәр арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Моннан тыш, 2020 елда ENGICO фирмасының (Италия) эре габаритлы гофротөргәген җитештерү буенча комплектлы линияне файдалануга тапшыру, шулай ук EMBA-175QS фирмасы EMBA Machinery AB (Щвеция) кече габаритлы гофротартмалар җитештерү линиясен файдалануга тапшыру гамәлгә ашырылды.

«Хәят Кимья» ҖЧҖ, «Алабуга» МИЗ гамәлдәге резиденты, 2019 елда санитар-гигиена кәгазе (туалет кәгазе, салфеткалар, кәгазь сөлгеләр) чыгару заводының икенче чиратын гамәлгә ашыруны төгәлләде. Җитештерүне киңәйтү чыгарыла торган продукция күләмен елына 65 мең тоннадан 140 мең тоннага кадәр арттырырга мөмкинлек бирде. 2020 елның ноябрендә җитештерү куәте 180 м/минутка кадәр булган ZK-03 яңа салфетка линиясе урнаштырылды. 2020 елда компания «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, «А.Ф. Агафонов исемендәге Республика клиник инфекция хастаханәсе» ДАССУ, «Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ хәйрия ярдәме күрсәткән: аларга үз продукциясенең партиясен тапшырган.

Drylock Technologies компаниясе (Бельгия) – гигиена продукциясен әйдәп баручы җитештерүче һәм тәэмин итүче – «Алабуга» МИЗ территориясендә балалар, хатын-кызлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен шәхси гигиена чараларын җитештерү буенча «Драйлок Текнолоджиз» ҖЧҖ проектын гамәлгә ашыра. 2020 елда бала аслыгы-трусиклар җитештерү линиясе яңартылды, бу линиянең җитештерүчәнлеген 40% ка арттырырга мөмкинлек бирде. Моннан тыш, сменага якынча 190 мең данә җитештерүчәнлекле гигиена продукциясе җитештерү буенча яңа линия урнаштырылган (кулланышка 2020 елның декабрендә кертелгән). Компания

PRIVATE LABEL AWARDS премиясендә «Үз сәүдә маркалы иң яхшы чит ил җитештерүчесе (СТМ) 2020» һәм PRIVATE LABEL AWARDS премиясенең «Контракт производствосын динамик үстерү һәм СТМ 2020» номинациясендә II дәрәҗә Лауреаты булды. Халыкка беренче кирәк булган товарларны, шәхси саклау чараларын тоткарлыксыз китерү кысаларында компания булган җиһазларда гигиеник битлекләр җитештерүне оештыру буенча оператив эш алып барды. Битлек әзерләү өчен халыкара куркынычсызлык стандартларына туры килә торган югары сыйфатлы материал кулланылган. Җитештерү куәте тәүлегенә 250 мең данә тәшкил иткән.

***Җиңел сәнәгать***

Республиканың җиңел сәнәгать предприятиеләре 10,7 млрд сумлык продукция төяп озатты. Шул ук вакытта текстиль җитештерүдә төяп җибәрелгән продукция күләме 4,4 млрд сум тәшкил итте, кием җитештерүдә - 5,6 млрд сум, сәнәгать җитештерүе индексы тиешенчә 132,4% һәм 114,5 %.

Тире, күн эшләнмәләр җитештерү һәм аяк киеме җитештерү предприятиеләре тарафыннан 0,7 млрд сумлык продукция төяп җибәрелгән, сәнәгать җитештерүе индексы 75,4% тәшкил иткән.

Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу белән бәйле хәлнең начарлануы сәбәпле, җиңел сәнәгать предприятиеләре (тегү цехлары булган башка тармаклар) тарафыннан көнгә 310 меңнән артык эшләнмә әзерләү белән тукыма гигиена маскалары җитештерү буенча оператив эш оештырылды. Бу эшкә 80нән артык предприятие җәлеп ителде. Медицина учреждениеләре хезмәткәрләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән көненә 20 мең комплектка кадәр бер тапкыр кулланыла торган саклагыч кием чыгару оештырылды.

2020 елның апрелендә «Азнакай Киемнәре» АҖ бер тапкыр кулланыла торган гигиена битлекләре җитештерү буенча автомат линия урнаштырды.

«Эластик заводы» ҖЧҖ «Росхимзащита» корпорациясе» АҖ адресына медицина билгеләнешендәге 347 тонна тукылмаган киндер китерде, предприятие тарафыннан чыгарылган комбинезон һәм мондый тукымадан ясалган халатларны сатуның гомуми күләме 18 мең данәдән артык тәшкил итте.

Медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш билгеләнешендәге яңа буын синтетик материаллар чыгара торган «Полиматиз» АҖ һәм »Эластик заводы» ҖЧҖ 2020 елда алдагы еллар белән чагыштырганда шактый арттырылган тукылмаган киндер җитештерү буенча ирешелгән югары күрсәткечләрне 2021 елда да саклап калырга планлаштыралар. «Эластик заводы» ҖЧҖ 2021 ел ахырына СМС төрендәге (күп катлы полипропилен тукылмаган материал) тукыма җитештерү буенча яңа линия эшләтеп җибәрү проектын гамәлгә ашыруга күчәргә, шулай ук «медицина» һәм «гигиена» маржиналь базарларында тукылмаган материал һәм аннан эшләнмәләрне сату күләмнәрен арттырырга планлаштыра.

«Здравмедтех-Поволжье» ЯАҖ - сыйфатлы заманча тукылмаган материаллардан медицина ярдәменең югары технологияле төрләрен күрсәткәндә кулланыла торган бер тапкыр кулланыла торган медицина киеме һәм эчке кием ассортименты, махсуслаштырылган операция комплектлары җитештерүче. 2020 елда продукцияне чыгару 8 млн берәмлек эшләнмәләр тәшкил иткән, 879,3 млн сумга продукция төяп җибәрелгән. Хәзерге вакытта предприятиенең куәте ай саен йогышлы

авыруларны дәвалаучы табибның саклану киеме комплектының 100 меңнән артык берәмлеген җитештерергә мөмкинлек бирә. Предприятие җитештерү күләмнәрен 2020 ел белән чагыштырганда 10%ка арттырырга, шулай ук бер тапкыр кулланыла торган медицина битлекләре җитештерү буенча яңа линия эшләтеп җибәрергә планлаштыра.

«Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы» ҖЧҖ - Россиядә оек-оекбаш эшләнмәләрен иң эре җитештерүчеләрнең берсе. Фабриканың эшләнмәләре «Носкофф» сәүдә маркасы астында чыгарыла. Предприятие шулай ук махсус кием һәм урын-җир комплектлары чыгара. 2020 ел йомгаклары буенча төяп җибәрелгән продукция күләме 250 млн сум тәшкил иткән.

«Кукмара тегү фабрикасы» АҖ, җил һәм дымдан саклый торган махсус сеңдермәле югары сыйфатлы тукымалардан, шулай ук экологик чиста полиэфир сүсләреннән торган, югары җылылык саклау сыйфатларына ия булган GRAFELITE җылыткычы полотносыннан (турыдан-туры фабрикада уникаль җиһазларда эшләнә) файдаланып балалар һәм өлкәннәр киеме эшләп чыгаруда махсуслашкан.

«Кукмара киез итек комбинаты» АҖ традицион киез итекләр белән беррәттән декоратив элементлар белән резиналанган табанлы киез аяк киеменең заманча модельләрен, шулай ук өлкәннәр һәм балалар өчен натураль йоннан ясалган эшләнмәләр чыгара. 2021 елда комбинат «Светофор», «Обувь России», «Пешеход» сәүдә челтәрләре белән хезмәттәшлекне киңәйтергә планлаштыра.

«Азнакай Киемнәре» АҖ һәм »Бөгелмә тегү фабрикасы» ҖЧҖ – эре нефть компанияләре, төзелеш оешмалары өчен дә, мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары өчен дә махсус сеңдермәләре булган (су этеп җибәрүче, май-суга чыдам, утка чыдам һәм җилдән саклаучы) тукымалардан махсус кием чыгаручы алдынгы предприятиеләр. 2021 елда «Азнакай Киемнәре» АҖ трикотаж әйберләр җитештерү линиясен киңәйтү өчен яңа җиһазлар сатып алуны планлаштыра.

«Авалон продакшн» ҖЧҖ - Peppy Woolton бренды астында балалар өчен оек-оекбашлар җитештерү буенча елына 1 млн пар эшләнмәләр җитештерә торган «М-7» индустриаль паркы резиденты. Фабрика шулай ук күп кенә балалар киемнәре җитештерүчеләрнең үз сәүдә маркалары астында эшләнмәләр җитештерү мәйданчыгы булып тора. Җитештерелә торган продукцияне алга җибәрү һәм кулланучыларның киң даирәсен колачлау максатында предприятие 2021 елда X5 Retail Group заманча ваклап сату компаниясе белән хезмәттәшлекне җайга салырга планлаштыра. Предприятие даими нигездә «Дочки-сыночки», «Верный», «Монро», «Кари», «Метро», «Лента», «Ашан» челтәр оешмалары, Wildberries, Lamoda маркетплейслары һәм төрле интернет-мәйданчыклары белән хезмәттәшлек итә.

«БАРС аяк киеме компаниясе» ҖЧҖ - Чистай шәһәрендәге АСИҮТ резиденты - «Эш аяк киеме җитештерүнең яңа производствосын оештыру» проектын тиредән, полимер материаллардан һәм эшкәртелгән каучуктан гамәлгә ашыра. Предприятие 2020 елда 380 мең пар эш аяк киеме чыгарган. 2021 елга төп бурычлар - ассортиментны һәм җитештерү күләмен арттыру, шулай ук яңа бина ачу һәм яңа куәтләрне гамәлгә кертү.

Җиңел сәнагать предприятиеләренең күбесе кече бизнес предприятиеләренә карый, алар кулланучылар, җитештерү-техник һәм махсус билгеләнештәге

товарларның киң ассортиментын җитештерәләр. Мәктәп формасын эшләү - Казан шәһәрендә «ИРЭН» тегү остаханәсе» ҖЧҖ, «Унисервис-Уңыш плюс» ҖЧҖ, Чаллы шәһәрендә «Бросско» ҖЧҖ, «Мәктәп Модасы» ҖЧҖ, «Триада» ҖЧҖ, Түбән Кама шәһәрендә «Түбән Кама тегү фабрикасы» ҖЧҖ эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе. Коммерциячел оешмалар өчен спорт һәм корпоратив киемнәр эшләү - «Алга» ҖЧҖ эшчәнлегендә төп юнәлеш.

***Эчемлекләр җитештерү***

2020 елда алкоголь һәм сыра кайнату эчемлекләрен эре һәм урта җитештерүчеләр 24,5 млрд сумлык продукция җитештергән, сәнәгать җитештерүе индексы 107,4% тәшкил иткән.

Азык-төлек чималыннан ректификацияләнгән 5,3 млн дал спирт җитештерелгән (2019 ел дәрәҗәсенә карата 90%), аракы - 7,8 млн дал (87%), сыра - 54,8 млн дал (123,5 %).

«Татспиртпром» АҖ - Россия Федерациясендә иң эре алкоголь компанияләренең берсе. «Татспиртпром» АҖ продукциясен алга чыгаруның нәтиҗәле чарасы булып «Алкоторг» дистрибьютор компаниясе һәм «Арыш мае» алкомаркетларының фирма республика ваклап сату челтәре тора. Компания продукциясе Россия Федерациясенең барлык төбәкләрендә дә тәкъдим ителгән. Предприятие экспортны актив үстерә. Компания продукциясе АКШ, Канада, Кытай Халык Республикасы, Япония, Көньяк Корея, Германия, Венгрия һәм башка илләргә җибәрелә. 2020 елның сентябрендә Шанхай шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) «EGMA (SHANGHAI) BUSINESS DEVELOPMENT CO. LTD» компаниясе «Татспиртпром» АҖнең беренче фирма кибетен ачты, анда килүчеләр продукциянең киң ассортименты белән таныша алалар. «Татспиртпром» АҖ продукциясе сыйфатының югары стандартлары халыкара күргәзмәләрдә һәм конкурсларда берничә тапкыр билгеләп үтелде.

2020 ел дәвамында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга каршы көрәш чорында Татарстан Республикасы дәвалау учреждениеләре хезмәткәрләренә һәм пациентларына ярдәм итү максатларында компания әлеге учреждениеләр адресына 100 мең шешә эчәргә яраклы «Святая Чаша» суын түләүсез бирде.

«АБ ИнБев Эфес» АҖ филиалы Казан шәһәрендә заманча сыра кайнату җайланмалары, тизйөрешле бүлү линияләр белән җиһазландырылган, барлык җитештерү процесслары алдынгы технологик чишелешләр кулланып башкарыла. Завод шуның белән уникаль, аның турыдан-туры сыра җитештерүдән тыш, үзенең солод производствосы, шулай ук ПЭТ преформалар һәм термоусадкалы пленка җитештерү цехлары да бар. Яңа заманча җиһазлар һәм программа белән тәэмин итү заводка компаниянең билгеле брендларын чыгарырга мөмкинлек бирә: «Иске тегермәнче», «Ак аю», Gold mine Beer, «Жигулевское бочковое» һәм башкалар. 2020 елда Казан филиалында сыраның яңа сортларын чыгара башлыйлар: Löwenbräu, «Старый мельник светлое», «Сибирская корона классическое».

2020 елның маенда яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга каршы көрәштә ярдәм күрсәтү максатларында «АБ ИнБев Эфес» АҖ Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 3 мең санитайзер тапшырылган.

«Булгарпиво» ААҖ Чаллы заводы сыра кайнату, алкогольсез эчемлекләр, табигый әчегән квaслар, минераль һәм эчә торган сулар җитештерә. Компания продукциясе Россия Федерациясенең 30 төбәгендә һәм якын чит илләрдә сатыла. Хәзерге вакытта компаниянең ассортимент портфеленә 45 төрдән артык продукция керә, шул исәптән сыраның билгеле брендлары: «Булгарпиво», «Бархатное», «Пшеничное», «Пятницкое», «Немецкое», «Английский эль», «Ирландский эль», «Шотландский эль» һәм башкалар. 2020 елда «Булгарпиво» ААҖ Камчатка төбәгенә, Кыргызстан һәм Эстония Республикаларына, Беларусь Республикасына сыра продукциясен китерә башлады. Предприятие Россиянең эре ритейлерлары белән эшлекле элемтәләрне җайга салу буенча актив эш алып бара. 2020 елның августында компания «Кызыл & Ак» сәүдә челтәре белән хезмәттәшлек турында килешү имзалады.

2020 елның апрелендә Чаллы шәһәренең медицина персоналына һәм дәвалау учреждениеләре пациентларына ярдәм итү максатыннан компания әлеге учреждениеләр адресына «Эдельже» эчәргә яраклы суын куйган. 2020 елның сентябрендә предприятие «Эфир» телеканалы оештырган «Исәнме мәктәп» балалар бәйрәмен оештыру өчен үз продукциясен бирде.

2020 елда Чаллы моношәһәре территориясендә «Булгарпиво» ААҖ эчемлекләр җитештерүне яңартуга һәм киңәйтүгә юнәлтелгән инвестицион проектны гамәлгә ашыру тәмамланды. Инвестицияләрнең гомуми күләме 1 млрд. сумнан артып китте, 92 яңа эш урыны булдырылды.

**Агросәнәгать комплексы**

2020 елда барлык төр хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясенең тулаем күләме 263,4 млрд сум тәшкил итте, 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырмача бәяләрдә үсеш темпы - 104%. Үсемлекчелек продукциясен җитештерү 2019 ел белән чагыштырганда чагыштырма бәяләрдә - 6,6 %ка, терлекчелектә - 1,5 %ка үсте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы республиканың авыл хуҗалыгы тармагының төп программа документы булып тора.

Республикада ашлык, шикәр чөгендере, май, яшелчә-бәрәңге һәм җиләк-җимеш субкластерлары уңышлы эшләп килә. Һәр субкластер үсемлекчелек продукциясен җитештерүнең рентабельлеген арттыру буенча төгәл чаралар күрүне күздә тота.

Үсемлекчелекнең кластерлы үсешен гамәлгә ашыру товар чималының бөтен күләмен диярлек республика предприятиеләрендә эшкәртүне һәм агросәнәгать комплексының һәр субкластерында беренчел чималдан ахыргы продукциягә кадәр өстәлмә бәяне арттыруны күздә тота.

Шикәр чөгендере, майлы культуралар һәм бөртеккә кукуруз кебек маржиналь культураларга аерым басым ясалды, ул терлекчелектә шактый өстәмә продукция алуны тәэмин итә.

2020 елда республиканың авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан башлангыч-керем авырлыгында 5,57 млн тонна ашлык суктырылган (эшкәрткәннән

соң 5,2 млн тонна авырлыгында), бу 2019 ел дәрәҗәсеннән 23,1%ка күбрәк. Ашлык җитештерүнең артуы уңдырышлылыкның 17,1%ка артуы һәм җыелган мәйданнарның 6,2%ка артуы белән аңлатыла. Бу күләм он тарту һәм икмәк пешерү предприятиеләрен икмәк пешерү өчен чимал, ә республика терлекчелеген - тупланган азык белән тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Кыр эшләрен планлаштыруны җиңеләйтү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм «Россельхозцентр» федераль дәүләт бюджет учреждениесе Татарстан Республикасы филиалы белән берлектә, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының вебсервис булып торучы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе этапларын нәтиҗәле файдалану, планлаштыру һәм тикшереп тору өчен, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне күзәтү һәм мониторинглау өчен билгеләнгән геомәгълүмат системасы кертелде.

2020 елда төп техник культуралы шикәр чөгендеренең тулаем җыемы 23,3%ка кимеде һәм 2,15 млн. тонна тәшкил итте. Эшкәртүгә юнәлдерелгән чөгендер-шикәр субкластеры җирле чимал белән тулысынча тәэмин ителгән.

323,5 мең тоннадан артык яшелчә җыелган. Бәрәңге 1,17 млн тонна җитештерелгән.

Бүген авыл хуҗалыгы республика халкын үзенең сыйфатлы һәм арзанлы продукциясенең төп төрләре белән тәэмин итә. 2020 елда 16 авыл хуҗалыгы ярминкәсе көне оештырылды (Казан шәһәрендә һәм республиканың башка эре шәһәрләрендә). 1,1 млрд сумлык продукция җитештерелде.

Республикада сөт, ит һәм аквакультура кебек субкластерлар уңышлы эшләп килә. Һәр субкластер терлекчелек продукциясен җитештерүнең рентабельлеген арттыру буенча конкрет чаралар күрүне күздә тота.

2020 ел нәтиҗәләре буенча республика сөт җитештерү буенча Россиядә 1 нче урында тора, терлек һәм кош ите җитештерү буенча - 7 нче урында. Республиканың барлык категорияләре хуҗалыкларында 1 935 мең тонна сөт савылган (2019 ел дәрәҗәсенә карата 102,1 %).

Республиканың нәсел хуҗалыклары сөтчелек юнәлешендә эшләп килүче һәм яңа проектларның җитештерү куәтләрен югары генетик потенциалы булган таналар белән тәэмин итә ала. Сөт терлекчелеге системасын җитештерүнең югары интенсив рәвешләренә күчерү исәбенә сөт җитештерү күләмнәренең артуына ирешү планлаштырыла: энергия куәте көчле һәм югары протеинлы азыкларны куллану, барлык технологик процессларны модернизацияләү, терлекләр авыруларына каршы профилактика һәм көрәшү өчен ветеринария препаратларын актив куллану, югары квалификацияле зооветеринария белгечләрен әзерләү.

Тармакта бара торган инновацион процесслар шартларында терлекчелек фермаларын һәм комплексларын төзү эше дәвам итә. 2020 елда 6,4 мең башка исәпләнгән 16 яңа ферма һәм комплекс файдалануга тапшырылган.

2021–2022 елларда 22 мең башка исәпләнгән 19 инвестицион проектны гамәлгә ашыру дәвам итәчәк, 9 мең башка исәпләнгән 10 яңа сөт комплексы төзү планлаштырыла. Заманча сөтчелек комплекслары төзелеше сөт җитештерү үсешен

тәэмин итә һәм ел саен җитештерүне 2-3% дәрәҗәсендә арттыру өчен база формалаштыра.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасы дәүләт заказы агентлыгы» АҖ базасында  авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча ике электрон сәүдә мәйданчыгы zakazrf.ru һәм tattis.ru эшли  (zakazrf.ru сәүдәдә катнашу принцибы буенча, шартнамәләрне турыдан-туры төзү принцибы буенча электрон товар-мәгълүмат системасы). Моннан тыш, Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге (Татпотребсоюз) район кооперацияләре аша халык җитештерә торган продукцияне сатып ала, аннары үз кибетләре челтәре аша, шулай ук авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә сата.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы республика продукциясен сәүдә челтәрләренә чыгару буенча даими эш алып бара. Бүгенге көндә барлык сәүдә челтәрләрендә республика товар җитештерүчеләренең продукциясе бар.

***Хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм***

Хуҗалык итүнең кече формалары - 468 мең шәхси ярдәмче хуҗалык, 4 мең фермер хуҗалыгы һәм 300дән артык авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы. Аларга ярдәм чараларын гамәлгә ашыру «Хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла һәм гаилә фермалары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, крестьян фермер хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары форматында товар продукциясен җитештерүне оештыру һәм үстерү аша авыл территорияләрен тотрыклы үстерүне күздә тота.

2020 елда кече хуҗалыкларга дәүләт ярдәме 3,2 млрд сумнан артык тәшкил итте. Нигезендә - фермерларга һәм кооперативларга грантлар (1,4 млрд сум), шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр (486,5 млн сум).

2020 елда «Татарстан Республикасында яшь фермерларга ярдәм» һәм «Татарстан Республикасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» программалары буенча конкурслар үткәрелде. 260 һәм 350 млн сум финанслау күләме белән конкурста сайлап алуда тиешенчә 66 һәм 25 җиңүче билгеләнде.

Авыл хуҗалыгы продукциясен халыктан сатып алу күләмен арттыру өчен республикада сату, әзерләү һәм эшкәртү буенча 301 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы төзелде. Авылларда хуҗалыкларның кече формаларын кредитлау мәсьәләләрен хәл итү өчен 9 авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативы теркәлгән.

2015 елдан башлап «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» программасы федераль катнашында кооперативның матди-техник базасын модернизацияләүгә (җитештерү биналарын, төзелмәләрен, бүлмәләрен,  цехларын сатып алуга һәм торгызуга, җитештерелә торган продукциянең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазландыруга, әзерләү, саклау, эшкәртү, сортировкалау, сую, беренчел эшкәртү һәм кош-кортны суыту өчен билгеләнгән җиһазлар сатып алуга, ит һәм кош итен сатуга, төяүгә, бушатуга, транспорт белән тәэмин итүгә, махсуслаштырылган транспорт, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, модульләр, авыл хуҗалыгы продукциясе өчен контейнерлар сатып алуга) юнәлтелә. 2020 елда

күрсәтелгән программа буенча 178,2 млн сумлык 15 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы грант откан.

«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән 2020 елда 486,5 млн сум күләмендә субсидияләр бүлеп бирелгән, шул исәптән:

кредитлар буенча процент ставкасын каплау - 9,5 млн сум;

сөт юнәлешендә мини-фермалар төзү - 89,2 млн сум;

товар һәм нәселле таналар һәм беренче бозаулар сатып алу - 6,6 млн сум;

кош-корт (каз, үрдәк, күркә һәм бройлер чебиләр) бәбкәләре сатып алу - 21,9 млн сум;

бер яшьтән зуррак савым сыерлары, ана кәҗәләр һәм кәҗәләр тоту һәм сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрү - 350,9 млн сум;

өч яшьтән өлкәнрәк бияләрне тоту - 8,4 млн сум.

2019 елдан «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына булышлык күрсәтү» илкүләми проекты составында «Фермерларга ярдәм итү системасын булдыру һәм авыл кооперациясен үстерү» федераль проекты гамәлгә ашырыла. Төбәк проектын финанслау өч юнәлеш буенча гамәлгә ашырылды:

«Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә грантлар - 289,3 млн сумлык 64 грант алучы;

авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр (23 кооператив 29,2 млн сум алган);

«Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» ДБУ чыгымнарын агымдагы эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле финанслашу, аңа 8,8 млн сум юнәлдерелгән.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын үстерү аша продукцияне сату һәм аны эшкәртү мәсьәләләрен хәл итүгә аерым игътибар бирелә. 2020 елда авыл хуҗалыгы кооперативларына өстәмә рәвештә 2 728 яңа әгъза җәлеп ителде. Кооперация әгъзаларының гомуми саны 7 меңнән артып китте. 2020 елның гыйнвар-сентябрь айларында акчалата керем 2019 елның тиешле чорына карата 2,5 тапкырга арткан һәм 4,6 млрд сум тәшкил иткән (2019 елның гыйнварында - 1,8 млрд сум). Авыл хуҗалыгының барлык өлкәләрендә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары төзү бурычы куелды. Илкүләм проектны гамәлгә ашыру һәм кече һәм урта эшмәкәрлеккә, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм күрсәтү халыкның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга кызыксынуын арттыруга һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

***«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасы***

2020 елда Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 3 084,9 млн сум акча җибәрелде, шул исәптән федераль бюджеттан - 1 328,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 1 040,4 млн сум, җирле бюджетлардан - 40,3 млн сум, бюджеттан тыш акчалардан - 675,5 млн сум.

Финанслау юнәлдерелде:

гражданнарның торак шартларын яхшыртуга - 410,2 млн сум, бу файдалануга 21,8 мең кв. метр торак кертергә һәм 315 гаиләне торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде;

торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелешендә финанс ярдәме күрсәтүгә - 217,2 млн сум. Бу 91 гаилә өчен 6,4 мең кв. метр торакны файдалануга тапшырырга мөмкинлек бирде;

торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерүнең инженер инфраструктурасын һәм проектларын үстерүгә - 351,5 млн сум. 6,86 км газ бүлү челтәре, 24 км суүткәргеч челтәр төзелде һәм торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү буенча 10 проект гамәлгә ашырыла;

авыл территорияләрен төзекләндерүгә - 791,8 млн сум. 500 дән артык проект гамәлгә ашырылды. Финанслау муниципаль районга 1 объектка 2 млн сумга кадәр бирелә һәм объектның смета бәясенең 70%тан артыгын тәшкил итә;

«Авыл ипотекасы» программасын гамәлгә ашыруга. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында кредитлар бирү күләме буенча алдынгы урыннарны били, торак сатып алу һәм төзү өчен 1 600 дән артык гаиләне акча белән тәэмин итә. Бирелгән кредитларның гомуми күләме 3,6 млрд сум тәшкил итте;

авыл торак пунктларын гомуми файдаланудагы автомобиль юллары белән тоташтыручы автомобиль юлларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә («Авыл территорияләрендә транспорт инфраструктурасын үстерү» ведомство проекты) - 527,6 млн сум. Бу республиканың 6 торак пунктын 15,6 км озынлыктагы юллар белән тоташтырырга мөмкинлек бирде;

су агызу челтәрләрен төзүгә («Авыл территорияләренең заманча йөзе» ведомство программасы) - 70,9 млн сум. 10,3 км су агызу челтәре төзелгән.

## Сәүдә комплексы

Татарстан Республикасының ваклап сату һәм күпләп сату сәүдәсендә якынча 320 мең кеше эшли, бу икътисадта эшләүчеләрнең 16,5 %ын тәшкил итә, ваклап сату буенча 17,4 меңнән артык предприятие, 27 ваклап сату базары, 5,2 мең җәмәгать туклануы предприятиесе, шулай ук 6 мең чамасы көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиесе эшли.

Хәзерге вакытта республика буенча мең кешегә исәпләгәндә сәүдә мәйданнары белән тәэмин ителеш 857,5 кв. м тәшкил итә (Татарстан халкының сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин ителеш нормативы 603,1 кв. м).

2020 ел нәтиҗәләре буенча ваклап сату әйләнеше 926,3 млрд сум тәшкил итте, бу 2019 ел дәрәҗәсенә карата бәяләрдә 93,9% тәшкил итә. Җан башына ваклап сату әйләнеше 237,6 мең сум тәшкил итте (2019 елда - 244,2 мең сум).

Ваклап сату әйләнеше структурасында товарларның азык-төлек төркеме өлеше 45% тәшкил итте (2019 елда - 44,8%), азык-төлек булмаган товарлар өлеше - 55 % (55,2 %).

Ваклап сату әйләнеше 92,9% ка стационар сәүдә челтәрендә (базардан тыш) эшчәнлек алып баручы сәүдә оешмалары һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан формалаштырылды, базарлар өлеше 7,1% тәшкил итте.

Ваклап сату товар әйләнешенең кимүенә халыкның сатып алу сәләте кимү сәбәп булды, бу яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу фонында халыкның реаль акча керемнәре дәрәҗәсенең кимүенә, шулай ук сәүдә предприятиеләренең эш режимы буенча чикләүләр кертелүгә бәйле.

Шул ук вакытта пандемия һәм чикләү чаралары 2020 елның март ахырыннан онлайн-кибетләргә яңа сатып алучылар агымын тәэмин итте. 2020 елда республикада интернет-сәүдә өлеше артты: 2019 елда 2 %тан 2020 ел йомгаклары буенча 3,7 %ка кадәр (Татарстанстат мәгълүматлары).

Бүгенге көндә республикада «Вайлдберриз» ҖЧҖ компаниясенең эре күпләп сату-бүлү үзәге эшли. Проектның беренче чиратын сафка бастыру белән компания тарафыннан эшкә 1 600 дән артык кеше кабул ителгән. Икенче чират төзелеше тәмамланып килә. Күрелгән чаралар эш урыннары санын арттырырга мөмкинлек бирәчәк, интернет-сәүдәнең алга таба үсешенә һәм әлеге базарда продукцияне республика тәэмин итүчеләре йөзендә яңа катнашучылар барлыкка килүгә китерәчәк.

Татарстанда хәзерге вакытта «Озон» компанияләр төркеме» ҖЧҖнең 2 күпләп сату-бүлү үзәге эшли. Алабуганың моношәһәре территориясендә X5 Retail Group компаниясе икенче күпләп сату-бүлү үзәге ачты. Төзелгән эш урыннарына 355 кеше җәлеп ителгән.

2020 елда җәмәгать туклануы әйләнеше 36,2 млрд сум (2019 елда - 47,7 млрд сум), яки 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 73,6% тәшкил итте.

Республика халкына 262,6 млрд сумлык түләүле хезмәтләр күрсәтелгән, яисә 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырмача бәяләрдә 87,4% (шул исәптән 36,5 млрд сумлык көнкүреш хезмәтләре күрсәтелгән).

2020 елның декабрендә куллану бәяләре индексы 2019 елның декабренә карата 104,8% тәшкил итте, шул исәптән азык-төлек товарларына - 107,1%, азык-төлек булмаган товарларга - 104,9%, хезмәт күрсәтүләргә - 101,8 %.

# ИНСТИТУТЛАР. ЭШМӘКӘРЛЕК

## Стратегик планлаштыру

Татарстан Республикасында 2020 елда стратегик планлаштыру эше дәвам иттерелде. Республиканың стратегик үсешенең төп юнәлешләре 2015 елда кабул ителгән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә салынды, аңа 2019 елда, илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны исәпкә алып, үзгәрешләр кертелде. Стратегиянең төп өч приоритеты:

кеше капиталын булдыру һәм туплау;

аны үстерү өчен уңайлы пространство булдыру;

икътисадта кеше капиталына ихтыяҗ булган һәм уңышлы эшли алган иҗтимагый институтлар булдыру.

Кеше капиталын юнәлтү буенча республика программалары кысаларында мөһим эш башкарылды. Стратегия-2030 (2015 – 2020 еллар) гамәлгә ашыру чорында:

29,5 меңнән артык укучы өчен 42 яңа мәктәп, 25 мең сабый өчен 150 балалар бакчасы гамәлгә кертелде;

521 мәктәп һәм 468 балалар бакчасы ремонтланган;

179 мәдәни объект, 812 физкультура һәм спорт объекты төзелде;

1 115 сәламәтлек саклау объекты төзелде һәм капиталь ремонтланды.

Стратегияне гамәлгә ашыру башланганнан бирле 283 меңнән артык татарстанлы дөньяга килде.

Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга республикада төзелгән спорт инфраструктурасы һәм халыкара спорт чараларын уздыру ярдәм итә. Республикада системалы нигездә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр халык санының 49,5 %ын тәшкил итте.

Соңгы 5 елда республика халкының гомер озынлыгы 2 елдан күбрәккә артты. Поликлиникаларны модернизацияләүнең масштаблары буенча моңарчы күрелмәгән ике еллык программасы тормышка ашырылды. Ул тәмамлангач, хастаханә комплексларының стационарларын ремонтлау буенча яңа бишьеллык программа старт алды.

Республика халкының яшенә карамастан, мәгариф өлкәсендә өзлексез белем бирү системасын тәэмин итүдә эшне билгеләп үтәргә кирәк, аның кысаларында түбәндәгеләр төзелгән:

3 «Кванториум» балалар технопаркы, «Кванториум» мобиль технопаркы, булачак галимнәрне һәм инженерларны әзерләү буенча яшьләр инновацион иҗатының 19 үзәге;

икътисадның реаль секторы өчен Worldskills стандартлары буенча кадрлар әзерләү гамәлгә ашырыла торган 41 ресурс үзәге;

Моннан тыш, «Өченче яшь университеты» проекты гамәлгә ашырылды, аның кысаларында Стратегияне гамәлгә ашыру чорында 47 мең кеше укыды.

Стратегиядә милли мәгариф системасын үстерүгә аерым игътибар бирелде. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясе 2016 елдан бирле гамәлгә ашырыла. Болгар ислам академиясе ачылды. 2019 елда «Адымнар - белемнәргә һәм татулыкка юл» полилингваль белем бирү комплексы

концепциясе расланды. Республикада мондый комплекслар челтәрен булдыру планлаштырыла - 2024 елга алар алты: Казан шәһәрендә ике һәм Чаллы, Түбән Кама, Алабуга һәм Әлмәт шәһәрләрендә берешәр. 2020 елның 1 сентябрендә Казан һәм Алабуга шәһәрләрендә полилингваль мәктәпләр ишекләрен ачты.

Яшьләр үзидарәсе институтларына ярдәм итү һәм аларны үстерү өчен шартлар тудыру «Яшьләр парламенты», «Яшьләр хөкүмәте» проектлары аша гамәлгә ашырыла. «Кадрлар резервы», «Югарыга!» конкурсы, «Студентлар лигасы», Студентлар отрядлары, Эшләүче яшьләр берлеге, «Сәләт» хәрәкәте, «Созвездие-Йолдызлык», «Наше время - Безнең заман», «Алтын каләм – Золотое перо» фестивальләре проектлары ярдәмендә актив яшьләргә ярдәм итүнең нәтиҗәле системасы формалашты. Тулаем алганда, Стратегияне гамәлгә ашыру талантлы яшь белгечләргә Татарстанда эшләргә этәргеч бирүче шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Стратегиянең икенче приоритетына ирешү өлешендә - аны гамәлгә ашыру чорында кеше капиталын үстерү өчен уңайлы пространство булдыру:

14,9 млн кв. м артык торак гамәлгә кертелде;

социаль ипотека программасы буенча 20 меңнән артык гаилә өй туен билгеләп үтте;

443 җәмәгать киңлеге төзекләндерелде;

икенче ел «ҖӘЙ - БАЛАЛАРГА» балалар лагерьларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү комплекслы программасын гамәлгә ашыру дәвам итә.

Территорияләр бәйләнешен арттыру өлешендә:

1 095 км юл төзелгән һәм реконструкцияләнгән;

республиканың 26 меңнән артык кешесе яшәгән 185 торак пункты юллар белән тоташтырылган.

Стратегиянең икътисад үсешеннән башка билгеләнгән максатларына – Стратегиянең өченче приоритетына ирешеп булмый. Монда иң эре предприятиеләрнең инвестицион проектларын гамәлгә ашыру уңышны билгеләүче фактор булып тора. Хәзерге вакытта республика өчен мөһим стратегик проектлар нефть-газ химиясе, машина төзелеше комплексларында, энергетикада, авыл хуҗалыгында һәм башка тармакларда гамәлгә ашырыла.

«Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисадый зоналарын актив үстерү дәвам итә.

Шул ук вакытта алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре яңа үсеш ноктасы булды (Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Зеленодольск һәм Менделеевск шәһәрләрендә), аларны төзү Стратегия-2030 белән каралмаган иде. АСИҮТ үзләренең нәтиҗәлелеген раслады, бюджетка аларның резидентларыннан керемнәр бирелгән ташламалар суммасыннан 2 мәртәбә артты.

Республикада 100 инфраструктура объекты эшли, шул исәптән 80 сәнәгать мәйданчыгы һәм 20 сәнәгать паркы. «Химград» технополисы һәм «Мастер» Кама индустриаль паркы кебек эре сәнәгать мәйданчыклары динамик үсештә.

Икътисадны үстерүнең төп ресурсы булып эшмәкәрлек экосистемасын үстерү тора. Республикада эшлекле активлыкны арттыру, шул исәптән эшмәкәрләрнең дүрт фундаменталь элементка: базарларга, инфраструктурага, финанс ресурсларына, мәгълүмат һәм мәгариф мәйданчыкларына керүен тәэмин итү буенча элек башланган эш дәвам итә.

**Илкүләм проектлар**

2018 елның 7 маенда Россия Федерациясе Президенты «2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 204 номерлы Указга кул куйды, ул илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга старт бирде, ил үсешенең төп юнәлешләрен билгеләп.

Россиядә 12 илкүләм проект гамәлгә ашырыла, Татарстан Республикасы 11 проектны гамәлгә ашыруда катнаша. Аларның һәркайсы билгеле бер юнәлештә: медицина, мәгариф, демография, эшмәкәрлек, торакның сыйфаты, җәмәгать киңлекләрен модернизацияләү һәм башка мәьәләләрдә тормышны сыйфатлы яхшырту өчен җавап бирә.

Россиянең озак вакытлы сәясәтен яңа мәсьәләләр, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәләрен бетерү кысаларында, шулай ук Россия Федерациясенең алгарышлы үсешен гамәлгә ашыру, ил халкы санын арттыру, гражданнарның яшәү дәрәҗәсен күтәрү, аларның яшәү һәм талантын ачу өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр расланганнан соң, Россия Федерациясе Президенты «2030 елга кадәр Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указга кул куйды, анда ул илнең 2030 елга кадәрге ирешеләчәк, кризиска бәйле рәвештә кичектерелгән төп милли максатларын раслады.

2020 ел кеше капиталын үстерүгә, яшәү өчен уңайлы мохит булдыру һәм яңа технологик нигездә ил халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән илкүләм проектларны гамәлгә ашыруның икенче елы булды. Республикада 50 төбәк проекты уңышлы гамәлгә ашырылды, аларның чараларына 31,4 млрд сум күләмендә лимит билгеләнде:

финанслау буенча килешүләр кысаларында - 26,7 млрд сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән - 22,8 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 3,9 млрд сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар - 4,7 млрд сум.

Ел нәтиҗәләре буенча 30,7 млрд сум үзләштерелгән (еллык план күрсәткечләренең 97,8%ы). Бюджетка 684,7 млн сум (федераль бюджет - 504,5 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты - 180,2 млн сум) кайтарылган, шул исәптән сатып алуларда һәм төзелештә экономия 150,3 млн сум, субсидияләр буенча экономия - 534,4 млн сум тәшкил итә.

Төбәк проектларын гамәлгә ашыру турында төзелгән килешүләр кысаларында 2020 елда 200 күрсәткеч буенча максатчан күрсәткечләр билгеләнгән, ел нәтиҗәләре буенча күпчелек өлеше үтәлгән. 2020 елда илкүләм проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

Арча муниципаль районында Яңа Чүриле авылында 97 урынга исәпләнгән психоневрологик интернатның торак корпусы файдалануга тапшырылган;

республика муниципаль берәмлекләрендә ГТО нормативларын тапшыру өчен 9 мәйданчыкта махсус җайланмалар урнаштырылган һәм республика муниципаль районнарының гомуми белем бирү мәктәпләрендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен 6 спорт залы ремонтланган;

төзелгән:

9 спорт объекты (Чаллы шәһәрендә боз сарае һәм ябык йөзү бассейны, 5 футбол кыры, Васильево шәһәр тибындагы поселогында универсаль спорт залы һәм Казан шәһәрендә «Тасма» стадионында җиңел атлетика йөгерү юллары);

4 гомуми белем бирү мәктәбе, 12 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, тагын 1 мәктәп төзелә башлады (Казан шәһәре, Николай Ершов урамы, «Арт Сити» торак комплексы, 2021 елда тапшыру планлаштырыла);

7 ФАП төзелде, Казан шәһәрендә балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәген төзү башланды, 31 балалар поликлиникасында балаларга уңайлы булуны тәэмин итә торган эчке пространстволарның оештыру-планлаштыру карарлары төзелде;

шәһәр мохитенең 51 объекты төзекләндерелгән;

261,6 км юл норматив хәлгә китерелгән;

12 чистарту корылмасы һәм яңгыр канализациясе төзелде һәм реконструкцияләнде, нефтьле пычранулы җирләрне рекультивацияләү (Шәмәрдән авылы) уздырылды һәм 2 рөхсәтсез чүплек (Прости авылы һәм Минзәлә шәһәре) бетерелә башлады;

8 авыл мәдәният йорты төзелде, Чаллы шәһәрендә Курчак театрына капиталь ремонт ясалды;

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен 94 фатир сатып алынган;

«Казан талантлар ачык университеты 2.0» КБАО һәм «Дуслык» республика олимпиада үзәге» ДАМУ (Казан шәһәре) базасында сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү үзәге һәм педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын өзлексез арттыру үзәге (Казан шәһәре) капиталь ремонтланды.

2020 елда җиһазлар сатып алу гамәлгә ашырылды һәм республика учреждениеләренең һәм оешмаларының матди-техник базасы яхшырды, ярдәм чаралары һәм социаль түләүләр күрсәтелде, гражданнарны укыту үткәрелде.

2021 елда илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга 30,6 млрд сум юнәлдерү планлаштырыла:

финанслау буенча килешүләр кысаларында - 25,1 млрд сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән - 22,5 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 2,6 млрд сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар - 5,5 млрд сум.

2019 елга планлаштырылган:

төзү:

16 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы;

гомуми белем бирү мәктәбе (Казан шәһәрендә «Салават күпере» ТК, 2021– 2022 еллар объекты);

Кукмара шәһәрендә спорт залы;

3 мәдәният йорты һәм 2 мәдәни үсеш үзәге (Алабуга һәм Зеленодольск шәһәрләре, 2021–2022 еллар объектлары),

гомуми белем бирү мәктәбен эксплуатациягә кертү (Казан шәһәрендә «Арт Сити» ТК, 2020 – 2021 еллар объекты);

капиталь ремонт:

авыл җирлегендә урнашкан 2 спорт залы (Мөслим һәм Саба муниципаль районнары);

2 балалар музыкаль мәктәбе;

57 парк һәм скверны төзекләндерү;

су белән тәэмин итүнең 2 тышкы челтәре объекты, өске суларны чистарту буенча 1 корылма, 1 биологик чистарту корылмалары объекты, 1 су әзерләү станциясе һәм су җыю узелы белән 1 су белән тәэмин итү системасы төзү һәм реконструкцияләү;

«Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУ территориясендә балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәге төзелешен тәмамлау (Казан шәһәре);

3 су объектын: Державин авылында буаны (Лаеш муниципаль районы), Мишә елгасы кушылдыгын (Никольский авылы) һәм Вятка елгасын (Мамадыш шәһәре) чистарту;

2 санкцияләнмәгән чүплекне рекультивацияләүне төгәлләү (Минзәлә шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы Прости авылы, 2020 – 2021 еллар объектлары);

авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен 100 фатир сатып алу;

185 км га якын юл челтәрен ремонтлау һәм төзү.

## Эшкуарлыкка ярдәм итү

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекнең 153,2 мең субъекты (алга таба – КУЭ субъектлары) эшчәнлек алып бара. Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгульләр саны (шәхси эшмәкәрләрне исәпкә алып) - 533,3 мең кеше. Әлеге күрсәткечләр буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында 1 нче урынны һәм Россия Федерациясендә 6 нчы урынны алып тора.

2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу белән бәйле тискәре хәлгә бәйле рәвештә, КУЭ субъектларына түбәндәге юнәлешләр буенча шактый ярдәм күрсәтелде:

кече бизнесның планлы тикшерүләренә мораторий кертү (бу компаниягә административ йөкләнешне киметте);

зыян күргән тармакларның кече һәм урта компанияләре өчен салым һәм иминият кертемнәрен түләүне кичектереп тору;

хезмәт хакы түләүгә кредитлар бирү;

ташламалы микрозаймнар бирү («Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» КБМО);

«Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО поручительлек бирү юлы белән банк кредитларына керү;

КУЭ субъектлары һәм азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп җиткерү комиссиясе кредитлары буенча процент ставкасын субсидияләү («Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлекне яклау һәм үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» ДКУ);

дәүләт мөлкәтен арендалаган өчен түләү буенча кичектерү;

онлайн-семинарлар һәм укыту программалары оештыру һәм башкалар.

Моннан тыш, кече бизнеска ярдәм итү һәм аны популярлаштыру максатларында ел дәвамында түбәндәге чаралар уздырылды:

үз-үзләренә эшләүче гражданнар өчен аларның продукциясе күргәзмәсе белән ике форум (2020 елның сентябрендә һәм декабрендә);

«Россиянең яшь эшмәкәре-2020» конкурсының төбәк этабы. Конкурста сайлап алу йомгаклары буенча 8 номинациядә 24 җиңүче билгеләнде. «Россиянең яшь эшмәкәре-2020» бөтенроссия конкурсы финалында Татарстан Республикасының 4 вәкиле җиңүче булды;

социаль эшмәкәрләрнең онлайн-слеты. Чара «Микрофабрикалар.Казан.Онлайн» виртуаль күргәзмәсе кысаларында узды;

Татарстан укучылары өчен бизнес-лагерь, анда бизнес алып бару буенча республика экспертлары эшмәкәрлек эше нигезләренә өйрәткән.

2020 елда 5 төбәк проекты буенча «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына ярдәм» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыру дәвам итте:

1) Эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару шартларын яхшырту;

2) КУЭ субъектларының финанс ресурсларыннан, шул исәптән ташламалы финанслардан файдалануын киңәйтү;

3) КУЭ субъектлары акселерациясе;

4) Фермерларга ярдәм итү системасын булдыру һәм авыл кооперациясен үстерү;

5) Эшмәкәрлекне популярлаштыру.

31 меңнән артык КУЭ субъекты һәм үзмәшгуль гражданнар консультация ярдәме алды. «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО карамагына КУЭ субъектлары үз бизнесларын үстерү өчен 7,9 млрд сумнан артык финанс чарасы җәлеп итте. 13 меңнән артык физик зат эшмәкәрлекне популярлаштыруга юнәлтелгән чараларда катнашты, шуларның 2,3 меңнән артыгы бизнес алып бару нигезләренә өйрәтелде, 330дән артык субъект үз эшмәкәрлек эшчәнлеген башлады.

2020 елның декабрендә күрсәтелгән илкүләм проектның яңа структурасы кысаларында 4 федераль проект расланды:

1) Үзмәшгуль гражданнар тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру;

2) Җиңел старт алу һәм бизнес алып бару өчен шартлар тудыру;

3) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары акселерациясе

4) КУЭ субъектлары һәм үзмәшгуль гражданнар тарафыннан адреслы сайлап алу механизмы һәм читтән торып ярдәм чараларын һәм махсус сервислар алу мөмкинлеге булган цифрлы платформа булдыру.

***Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасын үстерү***

Хәзерге вакытта республикада 1 511 резидент эшчәнлек алып бара торган 100 ярдәм инфраструктурасы объекты (80 сәнәгать мәйданчыгы һәм 20 сәнәгать паркы) бар, 32 меңнән артык эш урыны булдырылган. Сәнәгать паркларын (мәйданчыкларын) үстерү эш урыннарын булдыруга һәм модернизацияләүгә, тотрыклы салым түләүләренә, авылда кече бизнесны эш белән тәэмин итүнең альтернатив төрләрен, социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерүгә, хезмәткә мотивация формалаштыруга, квалификацияле хезмәткәрләрне җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Инфраструктураның төп звенолары түбәндәгеләр:

«Химград» технополисы (2020 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча: гомуми эшләүче 9,3 мең кеше булган 318 резидент, табыш - 33,9 млрд сум, салым түләүләре күләме - 4,1 млрд сум);

«Мастер» Кама индустриаль паркы (2020 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча: гомуми эшләүче 10,7 мең кеше булган 300 резидент, резидентлар табышы - 87,4 млрд сум, салым түләүләре күләме - 8,6 млрд сум);

«Казан» агросәнәгать паркы (2020 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча: гомуми эшләүче 1,2 мең кеше булган 252 резидент, резидентлар табышы - 1 094 млн сум, салым түләүләре күләме - 15 млн. сум);

сәнәгать мәйданчыклары һәм сәнәгать парклары (2020 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча - 644 резидент, 11,5 мең эш урыны, 43,8 млрд. сумлык продукция төяп җибәрелгән, салым түләүләре күләме - 3,7 млрд. сум).

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы карары кысаларында 2020 елда индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге инфраструктура объектларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә чыгымнарны субсидияләү буенча федераль бюджеттан индустриаль парклар инфраструктурасын булдыруга акчалар җәлеп ителде:

«Алабуга» СҖТ МИЗ» - 1,6 млрд сум;

«Алабуга-2.Нефтехимия» - 3,2 млрд сум.

Күрсәтелгән карар кысаларында 2021 елда әлеге индустриаль паркларның инфраструктурасын булдыруга федераль бюджеттан җәлеп итү планлаштырыла:

«Алабуга» СҖТ МИЗ» - 2,1 млн сум;

«Алабуга-2.Нефтехимия» - 5,1 млрд сум.

2020 елда сәнәгать паркларының һәм мәйданчыкларының идарәче компанияләренә һәм аларның резидентларына ярдәм итү өчен «Төзелеш» заемы һәм «Аренда» заемы кебек продуктлар эшләнде.

«Төзелеш» заем продукты кысаларында сәнәгать паркларының һәм мәйданчыкларның идарәче компанияләренә һәм резидентларына инженерлык инфраструктурасын, биналарны һәм корылмаларны төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә 30 млн сумга (5 % ка) кадәр заемнар бирелгән. Ярдәмне барлыгы 200 млн сумлык 1 идарәче компания һәм 10 резидент алды.

«Аренда» заем продукты кысаларында сәнәгать паркларының һәм мәйданчыкларның идарәче компанияләренә арендадан алынмаган керемнәр күләмендә инфраструктураны үстерүгә заемнар бирелде. Әлеге программа кысаларында «Мастер» Кама индустриаль паркы резидентлары җитештерә торган аренда түләве буенча түләүләрне кичектерү максатында «Мастер» Кама индустриаль паркы идарәче компаниясе 76,7 млн сум ярдәм алды, ул 1 елга срок белән башкарылды.

2020 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының 24 сәнәгать паркын һәм мәйданнарын аккредитацияләү буенча 5 чара оештырылды һәм уздырылды.

Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына ташламалы ставка буенча арендага бирү максаты белән 1 004 күчемле һәм күчемсез дәүләт һәм муниципаль мөлкәт объектларының исемлеге расланды.

***Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү институтлары***

***Финанс ярдәме***

*Ташламалы микрозаем.* 2020 елда «Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» КБОның микрофинанслау үзәге икътисадның реаль секторында эшләүче КУЭ субъектлары (аеруча зыян күргән тармакларда эшчәнлек алып бармаган) өчен ташламалы ярдәм механизмнары гамәлгә ашырылды. Программа шартлары буенча ярдәмне 2020 елның 1 апреленә штат санының кимендә 90% дәрәҗәсендә мәшгульлекне саклап калган, шулай ук табышны 2019 елның уртача айлык керемenә карата 30% ка киметкән КУЭ субъектлары алырга мөмкин иде.

Шулай ук «Үстерү» программасында катнашучы индивидуаль үсеш картасы булган КУЭ субъектларына, экспортка юнәлтелгән КУЭ субъектларына, шулай ук югары уку йортларын тәмамлаучыларга микрозаемнар бирелде.

2020 елда Микрофинанслау үзәге тарафыннан 674 микрозайм (2019 ел - 399 микрозайм, үсеш - 69%) КУЭ субъектларына 1 235,0 млн. сумга (2019 ел - 934,6 млн сум, 32% ка үсеш) бирелде, шул исәптән 295,1 млн сумга 254 ташламалы микрозайм (еллык 1% ка) бирелде. Микрозаймнарның гамәлдәге портфеле - 1 655,9 млн. сум.

*Татарстан Республикасы* Гарантия фонды *җаваплылыкны үз өстенә алу.* «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО залог белән тәэмин ителмәгән очракта КУЭ субъектларының финанс йөкләмәләре буенча йөкләмәләр бирә. 2020 елда КУЭ субъектларына 1 761,0 млн сумлык (2019 ел - 1 473,7 млн сум, үсеш - 19,5% ка) 342 йөкләмә алынган (2019 ел - 247 йөкләмә, үсеш - 1,4 тапкырга), бу эшмәкәрләргә 7 944,0 млн сумлык заем финанславын җәлеп итәргә мөмкинлек биргән (2019 ел - 5 547,8 млн сум, үсеш - 43%).

Бердәм кредитлау үзәге эше нәтиҗәләрен аерым билгеләп үтәргә кирәк, ул эшмәкәрләргә заем акчаларын җәлеп итүгә онлайн-режимда гариза бирергә мөмкинлек бирә. Сораштырылган мөрәҗәгать итүчеләр саны - 965, банкка җибәрелгән заявкалар саны - 328, җәлеп ителгән кредитлар суммасы - 854,7 млн сум, хуплау проценты - 31 %.

*Төбәк лизинг компаниясе* (алга таба – ТЛК) лизингка базар бәясеннән 3 тапкыр түбәнрәк ставка белән җиһазлар алырга мөмкинлек бирә (нәтиҗәле ставка: ТЛК - 6 %, базар лизинг компанияләре - 18 %).

Җиһазларны ташламалы лизинглау программасы яңа сәнәгать, югары технологияле җиһазлар, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һәм саклау өлкәсендәге җиһазлар сатып алучы шәхси һәм кече эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итүгә юнәлтелгән.

ТЛК 2,5 млрд сумнан артык суммага 103 проект хупланды (2017 елдан җыелган керем белән). 2020 елда Татарстан Республикасы буенча 272,8 млн сумга 12 проект финансланды.

*«Туклану продуктлары һәм азык-төлек китерү сервислары хезмәтләре өчен түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» программасы.* 2020 елның 1 апреленнән 31 майга кадәр «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» ДКУ 2020 елда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына сервисларның азык-төлек продуктларын китереп җиткерү һәм ашау хезмәтләре (комиссияләре) өчен түләүгә бәйле фактта

башкарылган һәм документаль расланган чыгымнар кире кайтарды. Ярдәм итү чарасы гамәлдә булган вакытта 154 заявкага 28 млн сумлык уңай карар кабул ителде.

*«Россия кредит оешмаларына җәлеп ителгән кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» программасы.* «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» ДКУ 2020 елда 6 ай дәвамында КУЭ субъектларының гамәлдәге кредитлары (аеруча зыян күргән тармакларда эшчәнлек алып бармаган) буенча процент ставкаларын (Россия Үзәк банкының төп ставкасы күләмендә) субсидияләү буенча елына 1,5 млн сум күләмендә ярдәм чаралары күрсәткән. Шулай ук икътисадның реаль секторы оешмалары, сәнәгать парклары резидентлары һәм идарәче компанияләре, кече һәм урта бизнесның экспортка юнәлтелгән субъектларына, шулай ук үз портфелендә инвестиция максатларына юнәлтелгән кредитлары булган эшмәкәрләргә процент ставкаларын субсидияләү буенча да ярдәм чаралары күрсәтелде. Программаның тиешле шартларына ярашлы эшмәкәрләргә кредитлар буенча алар тарафыннан түләнгән барлык процентлар 2020 елның 1 гыйнварыннан 30 ноябренә кадәр бер алучыга максималь күләмдә субсидия күләме 5 млн сум булганда кире кайтарылды. Ярдәм чаралары гамәлдә булган вакытта 100 млн сумга 24 гариза уңай карар алды.

***Мәгълүмати-консультация һәм белем бирү, алга этәрү хезмәтләре, сертификацияләү, экспортка чыгу***

*Татарстан Республикасында экспортка юнәлтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – Экспортка ярдәм үзәге) ярдәм күрсәтүне координацияләү үзәге*

Экспортка ярдәм үзәге Татарстан Республикасының экспортка юнәлтелгән кече һәм урта предприятиеләренә республика продукциясен чит ил базарларына чыгару өчен комплекслы ярдәм күрсәтә. Аның эшчәнлегенең төп максаты - КУЭ яңа субъектларын экспорт эшчәнлеген алып баруга җәлеп итү, гамәлдәге экспортер-предприятиеләрнең тышкы икътисадый эшчәнлегенә ярдәм итү һәм экспорт күләмен арттыру (*акчалата эквивалентта).*

2020 ел нәтиҗәләре буенча Экспортка ярдәм үзәге тарафыннан КУЭ 656 субъектына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтелгән, шул исәптән 621 субъекты – «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында. Экспортка ярдәм үзәге ярдәмендә чит ил базарларына илкүләм проект кысаларында 175 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (шуларның 2019 елда - 94, 2020 елда - 81) чыкты, ул 33,24 млн АКШ долларына экспорт контрактлары төзеде.

2020 елда КУЭ уникаль 55 субъекты Экспортка ярдәм үзәге оештырган «Россия экспорт үзәге» АҖ экспорт мәктәбе» автоном коммерцияле булмаган өстәмә һөнәри белем бирү оешмасының мәгариф программасында катнашты.

Моннан тыш, 2020 елда халыкара электрон сәүдә мәйданчыклары линейкасы 9 га кадәр киңәйтелде (2019 елда - 3). Халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында продукция урнаштыру хезмәтен 100 дән артык КУЭ субъекты ала.

*«Минем бизнес» үзәге*

КУЭ ярдәм итү буенча илкүләм проектны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында КУЭ субъектларын яклау инфраструктурасы оешмалары белән идарә итүнең бердәм органы составында «Минем бизнес» үзәге төзелде, аның составына түбәндәгеләр кертелгән: *Эшмәкәрлеккә ярдәм үзәге, Бизнес өчен КФҮ, Социаль өлкә инновацияләре үзәге, Кластерлы үсеш үзәге.*

*Эшмәкәрлеккә ярдәм үзәге*

Республика КУЭ субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү максатларында 2013 елдан Эшмәкәрлеккә ярдәм үзәге (алга таба – Үзәк) эшли. Аның эшчәнлегенең төп максаты – Татарстан Республикасында КУЭ үсеше өчен уңайлы шартлар тәэмин итү. 2020 елда Үзәк тарафыннан 25 меңнән артык консультация бирелгән, 59 чара уздырылган, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Эшмәкәрләр көне;

үз продукциясе күргәзмәсен оештырып, үзмәшгуль гражданнарның 2 форумы;

«Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» АҖ эшләгән 18 тренинг («Финанс ярдәме» 5 тренингы, «Бизнес-эксперт: КУЭ Бизнес-навигаторы порталы» 4 тренингы, «Электрон коммерция» 4 тренингы, «Эшмәкәрлек әлифбасы» 2 тренингы, «Эшмәкәрлек мәктәбе», «Генерация бизнес идей», «Франшиза буенча бизнес» тренинглары), аларда 1 меңнән артык кеше катнашты;

яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга каршы чикләү чаралары кертү чорында Үзәк эшмәкәрләр һәм үзмәшгуль гражданнар өчен 25 мастер-класстан торган вебинарлар эшләтеп җибәрде, аларда 54 меңнән артык кеше катнашты;

Татарстан Республикасында интернет-сәүдәне үстерү максатыннан Үзәкнең илнең әйдәп баручы маркетплейслары OZON, Wildberries, KazanExpress белән берлектә маркетплейсларда эшләү мәсьәләләренә багышланган вебинарлары үткәрелде, аларда 2 меңнән артык эшмәкәр һәм үзмәшгуль гражданнар катнашты.

2020 елда Үзәктә республикада КУЭ ярдәм итү мәсьәләләре буенча кайнар линия эшли, ул чикләү чаралары кертү чорында үз эшчәнлеген аеруча актив башкарды. Аның операторлары тарафыннан 14 меңнән артык шалтырату эшкәртелгән.

*Бизнес өчен КФҮ*

2016 елда дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча КУЭ субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү максатларында Бизнес өчен күпфункцияле үзәк (алга таба – бизнес өчен КФҮ) төзелде.

Бизнес өчен КФҮ эшмәкәрләргә югары дәрәҗәдәге сервислы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итә. Әлеге проект мәгълүматны, хезмәтләрне һәм ярдәмне (дәүләт һәм муниципаль) күрсәткәндә эшмәкәрләргә вакытлыча чыгымнарны минимальләштерергә тиеш.

Бизнес өчен КФҮ төп бурычлары түбәндәгеләр:

бер тәрәзә принцибын гамәлгә ашыру - бизнес өчен КФҮ базасында барлык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәткәндә гражданнарга һәм юридик затларга кабул итүнең, теркәүнең һәм кирәкле документларны бирүнең бердәм урынын булдыру, гражданнарга һәм юридик затларга бер үк вакытта үзара бәйле берничә дәүләт һәм муниципаль хезмәт алу мөмкинлеген бирү;

дәүләт хезмәтләре федераль порталы, дәүләт хезмәтләре порталының төбәк сегменты белән мәгълүмат алмашуны оештыру;

эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» АҖ (КУЭ корпорациясе) һәм «Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе тарафыннан ярдәм программалары буенча мәгълүмат бирү.

Казан шәһәрендә Эшмәкәр йортында бизнес өчен флагман КФҮ эшли (Казан шәһәре, Петербург ур., 28 йорт), анда 6 кабул итү тәрәзәсе эшли. Эшмәкәрләр бер тәрәзә режимында 60 тан артык хезмәт алырга мөмкин. 2020 елда бизнес өчен КФҮ хезмәтләреннән 1 400 уникаль КУЭ субъекты файдаланган, аларга 5,3 меңнән артык хезмәт күрсәтелгән.

*Социаль өлкә инновацияләре үзәге*

Социаль эшмәкәрләргә ярдәм итү һәм аны үстерү, социаль өлкәдә перспективалы һәм стратегик проектларны һәм инновацияләрне популярлаштыру һәм нәтиҗәле алга җибәрү, шулай ук Татарстан Республикасында социаль проектларга һәм инициативаларга ярдәмнең сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәсен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Социаль тармагы инновацияләре үзәге (алга таба – СТИҮ) эшли.

2020 елда СТИҮ, эшсез халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү программасы кысаларында, гадәттәгечә, Казан (Идел буе) федераль университеты һәм Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән берлектә «Эшмәкәрлек эшчәнлегендә бизнес-планлаштыру» практик семинарлар уздырды. Укыту кысаларында тыңлаучылар булачак эшмәкәрлек эшчәнлегенең бизнес-планнарын эшли һәм аны яклау буенча тренинг уза. 2020 елда 90 кеше белем алды, шуларның 37 се үз бизнес-планнарын уңышлы яклады һәм шәхси эшмәкәрләр сыйфатында теркәлде, шулай ук 145,1 мең сум күләмендә субсидия алды.

Социаль эшмәкәрлек, социаль һәм социаль-эшмәкәрлек проектларын, агымдагы эшчәнлек һәм ярдәм чаралары мәсьәләләре буенча 500дән артык консультация уздырылды. Традицион рәвештә СТИҮ интернет-ресурсларда (сайт һәм социаль челтәрләр) актуаль мәгълүмат урнаштыру юлы белән мәгълүмати ярдәм күрсәтә, шулай ук дайджестның атна саен электрон җибәрелүләре гамәлгә ашырыла. СТИҮ хезмәткәрләре социаль эшмәкәрлек һәм проектлау буенча 16 белем бирү чарасы үткәрде һәм анда катнашты.

2020 елдан башлап, КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип тану һәм социаль предприятие статусына ия булган КУЭ субъектлары исемлеген төзү буенча эш башланды. Татарстан Республикасында 2020 елда Социаль предприятиеләр исемлегенә 12 КУЭ субъекты кертелде.

*Кече һәм урта бизнесның сатып алуларга мөмкинлеге*

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсендә эшмәкәрләрнең катнашуын киңәйтү максатларында 2020 – 2022

елларга «Кече эшмәкәрлек субъектларында һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларда урнаштырылган сатып алулар өлеше, сатып алуларның җыелма еллык күләменнән» индикаторының минималь рөхсәт ителә торган бусагасы 15 процентtan 30 %ка кадәр арттырылды.

2020 елда Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы zakupki.gov.ru мәгълүматлары буенча КУЭ субъектларыннан сатып алулар суммасы 69,8 млрд сум тәшкил иткән, бу 2019 ел күрсәткеченнән 3,2 млрд сумга күбрәк. КУЭ субъектларыннан сатып алулар өлешен арттыру максатларында республиканың иң эре заказчыларының сатулары планнарына мониторинг уздырыла (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 717-р номерлы боерыгы).

Әлеге заказчыларны сатып алу планнарында КУЭ субъектларыннан планлаштырылган сатып алуларның еллык күләменең кимендә 18%ы күләмендә сатып алуларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан бүлек булырга тиеш.

2020 елда күрсәтелгән заказчылар саны 4 оешмага арткан һәм 17 тәшкил иткән. Бу Идел буе федераль округында иң күп төбәк заказчылары. Ел дәвамында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эре заказчыларның сатып алулар планнарының 498 проекты каралды һәм килештерелде.

**Татарстан Республикасының 17 иң эре заказчысы**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | «Казметрострой» АҖ | 10 | «ТАТМЕДИА» АҖ |
| 2 | «Казэнерго» АҖ | 11 | «Татагролизинг» АҖ |
| 3 | «Челтәр компаниясе» АҖ | 12 | «Энергопрогресс» инженерлык үзәге» ҖЧҖ |
| 4 | «Татавтодор» АҖ | 13 | «ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» ТР ДАУ |
| 5 | «Татспиртпром» АҖ | 14 | «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү ДАМУ |
| 6 | «Татхимфармпрепараты» АҖ | 15 | «ИТ-парк» ДАУ |
| 7 | «Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» АҖ | 16 | «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ |
| 8 | «Республика инвестицияләр һәм новацияләр агросәнәгать үзәге» АҖ | 17 | «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергия саклау технологияләрен үстерү идарәсе» АҖ |
| 9 | «Таттелеком» ГАҖ | | |

2020 елда әлеге заказчылар тарафыннан КУЭ субъектларыннан 28,2 млрд сумга (51,6 млрд сумнан) сатып алуларның яртысыннан артыгы (54,6 %) башкарылган.

Кооперация элемтәләрен үстерү һәм эчке ихтыяҗны стимуллаштыру өчен Республика маркетинг үзәге (алга таба – РМҮ) уңышлы эшләп килә. 2020 елда РМҮ ресурсында Татарстанның 4 меңнән артык эшмәкәре 99 млрд сум күләмендә табыш алган. «Татарстан Республикасы дәүләт заказы агентлыгы» АҖ белән берлектә заказчылар һәм тәэмин итүчеләр өчен шушы системада эшләү принциплары буенча атналык бушлай укыту вебинарлары уздырыла.

## Дәүләт идарәсе

*Программа-максатчан идарә системасын камилләштерү*

Дәүләт программалары дәүләт бурычларын гамәлгә ашыруның һәм финанс ресурсларын бүлү һәм контрольдә тоту процессларын оптимальләштерүнең нәтиҗәле коралы булып тора. 2020 елда Татарстан Республикасының 32 дәүләт программасы гамәлгә ашырылды, аларны финанслауның факттагы күләме 353,4 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән - 56,3 млрд сум (15,9 %), Татарстан Республикасы бюджеты - 250,6 млрд сум (70,9 %), җирле бюджетлар - 3,1 млрд сум (0,9 %), бюджеттан тыш чыганаклар - 43,4 млрд сум (12,3 %).

2021 елда Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыруга 309,6 млрд сум акча юнәлдерү каралган, шул исәптән федераль бюджет чаралары исәбеннән - 37,4 млрд сум (12,1 %), Татарстан Республикасы бюджеты - 223,1 млрд.сум (72,1 %), җирле бюджетлар - 2,1 млрд сум (0,7 %), бюджеттан тыш чыганаклар - 47,0 млрд сум (15,1 %).

2020 елда һәм 2021 елга план чорына Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанслау турында мәгълүмат

| Т/с | Дәүләт программасы исеме | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел (план) |
| | 2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 63 755,7 | 62 534,0 |
| | 2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 52 140,6 | 33 530,8 |
| | 2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 29 206,6 | 33 362,7 |
| | 2013 - 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 19 159,6 | 14 903,9 |
| | 2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 86 406,5 | 79 810,9 |
| | 2014-2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 11 230,8 | 16 046,3 |
| | Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү (2020 – 2025 еллар) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 21 842,0 | 15 079,0 |

| Т/с | Дәүләт программасы исеме | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел (план) |
| | 2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | 9 033,5 | 4 080,4 |
| | 2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | 5 289,7 | 6 063,2 |
| | 2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 11 395,8 | 8 856,2 |
| | 2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 12 401,0 | 11 928,1 |
| | 2014 - 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 3 893,5 | 3 469,1 |
| | 2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 501,7 | 243,6 |
| | 2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы | 2 387,9 | 2 295,2 |
| | 2014 - 2025 –елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 5 361,6 | 4 160,8 |
| | Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру (2014 - – 2024 еллар) | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 1 794,9 | 1 825,0 |
| | 2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 5 381,9 | 2 156,0 |
| | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү (2014 - 2024 еллар) | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 1 349,6 | 965,9 |
| | Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 3 222,8 | 875,9 |

| Т/с | Дәүләт программасы исеме | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел (план) |
| | ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану (2014 - 2024 еллар) | | | |
| | 2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 707,7 | 604,8 |
| | 2013 - 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 1 881,0 | 1 277,0 |
| | 2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 61,5 | 123,4 |
| | 2015 - 2023 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 108,1 | 119,1 |
| | 2019 - – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль газ белән тәэмин итү компрессор станцияләрен төзү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 540,0 | 812,0 |
| | 2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | 234,8 | 363,1 |
| | 2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 37,1 | 58,5 |
| | 2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 31,7 | 35,6 |
| | Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу (2020 - 2023 еллар) | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 70,5 | 109,4 |
| | 2015 - 2023 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 5,7 | 8,8 |
| | 2016 – 2023 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты | 222,6 | 242,8 |
| | 2019 - 2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызны Татарстан Республикасына ирекле рәвештә күчерүгә ярдәм итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 1,2 | 1,1 |
| | Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохите булдыру (2018 – 2024 еллар) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 3 700,6 | 3 608,3 |

| Т/с | Дәүләт программасы исеме | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел (план) |
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга барлыгы, шул исәптән: | | | 353 358,2 | 309 550,9 |
| федераль бюджет | | | 56 308,9 | 37 367,4 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | 250 590,4 | 223 140,3 |
| җирле бюджетлар | | | 3 128,7 | 2 063,9 |
| бюджеттан тыш чыганаклар | | | 43 330,2 | 46 979,3 |

*Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре системасын үстерү*

Татарстан Республикасында һәр муниципаль районда, шәһәр округында, шулай ук 1 мең кешедән артык халкы булган Татарстан Республикасы авыл җирлекләрендә эшләүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) офисларының киң челтәре булдырылды.

Республиканың күпфункцияле үзәкләре системасына түбәндәгеләр керә:

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» ДБУ (алга таба – КФҮ ДБУ) республика филиаллары челтәре белән;

һәр муниципаль районда «Минем документлар» КФҮ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең 60 үзәге һәм Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә берничә офис;

Казан шәһәрендә 1 өстәмә офис (бизнес өчен КФҮ) түбәндәге адрес буенча: Петербург ур., 28 йорт (Эшмәкәр йорты);

Казан (Җиңү проспекты, 62\4) һәм  Чаллы (Сөембикә пр., 16 йорт) шәһәрләрендә Саклык банкы бүлекләре базасында 1 Хезмәт күрсәтү үзәге (ХКҮ);

халкы 1 мең кешедән артык булган авыл җирлекләрендә (җирлеккә барып хезмәт күрсәтелә) 281 КФҮ территориаль-аерымланган структур бүлекчәсе (ТАСБ - кабул итүнең читтән торып тәрәзәсе).

Хезмәтләрдән даими рәвештә файдалана алу мөмкинлеген арттыру өчен КФҮкабул итү офисларының санын арттыру буенча эш алып барыла.

2018 – 2019 елларда Казан шәһәрендә Дәрвишләр, Юдино микрорайоннарында, Совет районында (Җиңү проспекты, 214 йорт) «Салават күпере» торак комплексында 4 өстәмә үзәк, шулай ук Чаллы шәһәрендә зур офис ачылды. 2019 елның декабрендә Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында яңа КФҮ һәм Түбән Кама шәһәрендә КФҮ мини-офисы эшли башлады. 2021 елның февралендә Казан шәһәре үзәгендә КФҮ Вахитов бүлеге ачылды (Достоевский урамы, 35/10 йорт адресы буенча).

Татарстан Республикасында КФҮ үзәкләре мөрәҗәгать итүчеләргә (физик һәм юридик затларга) көн саен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең 250дән артык төрен норматив хокукый актларда билгеләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә бер тәрәзә принцибы буенча тәкъдим итә:

17 мәҗбүри федераль хезмәт күрсәтү;

66 тәкъдим ителгән (федераль, төбәк, муниципаль) хезмәт күрсәтү;

14 федераль хезмәт, аларны күрсәтү нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан мәгълүматны үз эченә алган документ тора;

федераль хакимият органнары, дәүләт корпорацияләре һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары хезмәтләре (Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте, Федераль салым хезмәте, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы (шул исәптән миграция, Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе линиясе буенча), Дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча федераль агентлык, Кеше хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль агентлык, Суд приставлары федераль хезмәте, Россия Федерациясе Пенсия фонды, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды, Россия Федерациясе Цифрлы үсеш министрлыгы, Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе);

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалары хезмәтләре (граждан хәле актларын теркәү органнары, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» ДБУ, «Татарстан Республикасының техник инвентарьлаштыру бюросы» АҖ);

муниципаль хезмәтләр;

гражданнар өчен башка өстәмә хезмәтләр (Алданган кертемчеләр һәм акционерлар федераль фондына гаризалар бирү, машина йөртүче картасын алу, электрон цифрлы имза әзерләү, күчермәләр ясау, килешүләр төзү, юридик консультация бирү буенча түләүле хезмәтләр).

2020 елда КФҮдә Федераль салым хезмәтенең, Россия Федерациясе Пенсия фондының, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, «Татарстан Республикасының техник инвентаризациясе бюросы» АҖ, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының өстәмә федераль һәм төбәк хезмәт күрсәтүләренең 51 төре өстәлде.

Гаризалар кабул итүдән һәм нәтиҗәләр бирүдән тыш, КФҮ гражданнарга барлыкка килә торган проблемалы мәсьәләләрне хәл итү өчен хакимиятнең кайбер органнары, мәсәлән, Роспотребнадзор, Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе хезмәткәрләре, «Тикшерелгән бизнес» порталы консультантлары белән «Скайп» видеосистемасы буенча турыдан-туры элемтәгә керү мөмкинлеген тәэмин итә. Республиканың һөнәри керемгә салым түләүчеләр (үзмәшгульләр) сыйфатында теркәү буенча пилот проектында катнашуы кысаларында теләсә кайсы КФҮ хезмәткәрләре теркәү процедурасын узуда ярдәм күрсәтәчәкләр.

барлык хакимият органнары һәм оешмалары белән КФҮ ДБУ үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешүләр төзелде.

Хезмәтләр исемлеге даими рәвештә киңәя, күрсәтелгән хезмәтләр саны арта: 2016 елда - 2,7 млн хезмәт, 2017 елда - 3,4 млн, 2018 елда - 3,7 млн, 2019 елда - 4,9 млн, 2020 елда - 5,2 млн хезмәт күрсәтелгән.

Мөрәҗәгать итүчеләргә уңайлы булсын өчен Бердәм белешмә хезмәте – КФҮ кол-үзәге (телефон: (843) 222-06-20), аның буенча барлык мәсьәләләр буенча атнага алты көн мөрәҗәгать итәргә мөмкин, мөрәҗәгать итүчеләргә документларның әзерлеге турында СМС-хәбәр итү гамәлгә ашырыла.

2018 елдан КФҮ аерым хезмәтләргә карата комплекслы сорату кысаларында документлар тапшыру кертелде, ул вакытта мөрәҗәгать итүче берничә хезмәт күрсәтүгә бер гариза бирә, бу кабул итү вакытын шактый киметә.

*Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мониторингы*

Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мониторингы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 елның 5 мартындагы 178 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне мониторинглау методикасын раслау турында» 2008 елның 4 августындагы 560 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү кысаларында гамәлгә ашырыла. 2020 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең 8 башкарма органында анализ ясалды. Аның нәтиҗәләре буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшне камилләштерү процедураларын оптимальләштерү, республика хакимият органнары һәм учреждениеләре адресына җитешсезлекләрне бетерү максатыннан бәяләмәләр җибәрелгән, даими рәвештә әлеге тәкъдимнәрнең үтәлешен мониторинглау уздырыла.

Әйтик, 2020 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан күрсәтелә торган барлык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләргә карата «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр» бүлегендә мәгълүмат урнаштыруның бердәм стандартын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең рәсми сайтларының тиешле бүлеген булдыру методикасы эшләнде. Әлеге методик тәкъдимнәр мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрында һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла торган белешмәләрне өч клик һәм белешмәләрне кабатлау зарурлыгын төшереп калдыру таләбен исәпкә алып формалаштырылды.

*Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары эшен координацияләү*

2020 елда Татарстан Республикасында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген түбәндәге дәүләт хакимияте башкарма органнары (алга таба – контроль-күзәтчелек органнары) гамәлгә ашырды:

21 төбәк контроле (күзәтчелеге) төрен гамәлгә ашыручы 16 контроль-күзәтчелек органы;

тапшырылган вәкаләтләр буенча контрольнең (күзәтчелекнең) 7 федераль төрен гамәлгә ашыручы 4 контроль-күзәтчелек органы;

32 төрле контрольне (күзәтчелекне) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының 13 территориаль органы.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы контрольнең (күзәтчелекнең) 28 төре буенча 18 контроль-күзәтчелек органнарына карата, шуларның 21 төбәк һәм 7 федераль дәрәҗәдән тапшырылган, координацияли, методик ярдәм күрсәтә, норматив хокукый актларга хокукый экспертиза уздыра һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 31 гыйнварындагы 147-б номерлы боерыгы белән расланган «Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделе (алга таба – Максатчан модель) үтәлешен мониторинглый.

2020 елда контроль (күзәтчелек) вәкаләтләре бирелгән контроль-күзәтчелек органнары (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе) белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Максатчан модель чараларын гамәлгә ашыру өчен өйрәтү методик материалларын аңлату һәм җибәрү буенча чаралар уздырылды.

Россия Федерациясендә уздырыла торган контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы кысаларында һәм 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы федераль законнарны гамәлгә ашыру максатларында республикада түбәндәге чаралар уздырылды:

Татарстан Республикасы хокукый актларын әзерләү һәм бастырып чыгару буенча чаралар планы («юл картасы») расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 сентябрендәге 1751-б номерлы боерыгы);

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле юл карталарын раслау эше оештырыла;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында даими рәвештә актуальләштерелә һәм урнаштырыла торган контроль-күзәтчелек чаралары уздырганда юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеген алып бару эше оештырылды.

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) үтәү йөзеннән, шулай ук Максатчан модель нигезендә:

уздырылган:

контроль-күзәтчелек органнары белән методологик эш, профилактика программаларын гамәлгә ашыру буенча докладларга 28 экспертиза, профилактика ведомство программаларына 28 экспертиза, хокук куллану практикаларын гомумиләштерүгә 82 экспертиза;

контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау;

14 контроль-күзәтчелек органнары әзерләгән дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында 17 докладка һәм 2019 елда уздырылган контроль-күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасының 43 муниципаль районы һәм 2 шәһәр округы әзерләгән Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашыруга тапшырылган муниципаль контрольне һәм дәүләт контролен башкару турында 109 докладка экспертиза. Татарстан Республикасында дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында тупланган җыелма докладлар «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштырылган;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 февралендәге 121 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планы («юл картасы») актуальләштерелде;

барлык контроль-күзәтчелек органнарына карата «А» төркеме, «Б» һәм «В» төркемнәренең төп күрсәткечләре билгеләнде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2020 елның 21 февралендәге 125 номерлы карары (алга таба – Дәүләт йөкләмәсе);

2020 елда Максатчан модельнең 4.1 күрсәткечен гамәлгә ашыру максатларында Дәүләт биремენә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе белән тулыландырылды, анда шул исәптән контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, аларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү тәртибе, әлеге күрсәткечләрнең казанышларын тикшереп тору һәм контроль (күзәтчелек) органнары хезмәткәрләренең казанышларына карап, кызыксындыру тәртибе өстәлде;

Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча «А» төркеменә карый торган контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зыян) китерүне минимальләштерүдә чагыла торган төп күрсәткечләре исемлеге актуальләштерелде;

эш оештырылган:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы функцияләре идентификаторы нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча гадәти болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасында кирәкле белешмәләрне вакытында һәм тулысынча тутырып баруны тәэмин итү буенча;

планлы тикшерүләр уздырганда хәвеф-хәтәр юнәлешле модельне кертү буенча: төбәк контроленең (күзәтчелегенең) 21 төреннән контрольнең (күзәтчелекнең) 20 төре буенча план тикшерүләре хәвеф-хәтәр чыгу куркынычын исәпкә алып уздырыла йә федераль законнар нигезендә үткәрелми;

2021 елда җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк контролен гамәлгә кертү планлаштырыла (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы).

2020 елда, киеренке санитар-эпидемиологик вәзгыятьне исәпкә алып, тикшерүләр өлешендә бизнеска йөкләнешне шактый киметкән кайбер карарлар кабул ителде.

Шулай итеп, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 98-ФЗ номерлы Федераль закон) белән 2020 ел ахырына кадәр гражданнар тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы сораулардан тыш, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын тикшерүгә мораторий кертелде. Шундый ук чаралар Татарстанда төбәк һәм муниципаль контрольгә карата да кертелгән (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 28 мартындагы 139 номерлы боерыгы).

98-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында контроль-күзәтчелек органнары 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.2 статьясының 1.1 өлешендә каралган планлы тикшерүләрне үткәрүне тыюга бәйле рәвештә тикшерүләрне төшереп калдыру өлешендә еллык тикшерүләр планына үзгәрешләр кerттеләр.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы карары нигезендә 2020 елга тикшерүләр планыннан барлык юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр төшереп калдырылды.

Татарстан Республикасында законнар белән җайга салу үзгәрешләренә бәйле рәвештә контроль-күзәтчелек чаралары саны кимү булды. Әйтик, 2020 елда кече һәм урта эшмәкәрлекне тикшерүгә мораторий кертү исәбенә 903 планлы һәм 757 планнан тыш (билгеләнгән, әмма гамәлдән чыгарылган) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының тикшерүләре гамәлдән чыгарылды.

Эшмәкәрлек эшчәнлегенең башка субъектларына да йөкләнеш кимегән (1 нче форма - «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасына контроль мәгълүматларына караганда, тикшерүләр саны 2020 елда 2019 ел белән чагыштырганда 6,4 тапкырга кимегән - 14 430 алып 2 226 тикшерүгә кадәр).

2020 елда уздырылган контроль-күзәтчелек чараларыннан дүрттән өче (2 726 планнан тыш тикшерүнең 1 969) саклана торган кыйммәтләргә, шул исәптән гражданнарның сәламәтлегенә һәм гомеренә зыян китерү куркынычы белән бәйле тикшерүләргә туры килә.

2019 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнгән «Профилактика» модуле (алга таба – Модуль) эшләвен дәвам итә. Квартал саен Модулда профилактик чаралар буенча рейтинг формалаша. Модулда төбәк контроленең (күзәтчелегенең) 21 төре буенча барлык 16 контроль-күзәтчелек органнары контроль-күзәтчелек һәм профилактик эшчәнлек алып бара.

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеген реформалаштыру кысаларында шулай ук контроль-күзәтчелек эшчәнлеген дистанцион мониторингка күчү буенча эш алып барыла.

Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы 2020 елның 1 декабрендә ТОР КНД «1 нче версиясе»ннән ТОР КНД «2

нче версиясе»нә мәгълүматларының миграциясе гамәлгә ашырылды.

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеген реформалау кысаларында бизнеска административ басымны киметү максатларында профилактика, тикшерү кәгазьләрен һәм хәвеф-хәтәр юнәлешле якын килүне куллану аша эшмәкәрләр белән хезмәттәшлекнең сервис моделен төбәк контроле-күзәтчелек органнары эшчәнлегенә кертү буенча эш алып барыла.

2018 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы инициативасы белән Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән берлектә оештырылган «Тикшерелгән бизнес» интернет-ресурсы бизнеска гамәлдәге законнар таләпләре турында оператив мәгълүмат бирүне дәвам итә. 2020 елның декабреннән «Тикшерелгән бизнес» интернет-порталында үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бизнестан кире элемтә алу өчен кыскача сораулык булган «Кире элемтә модуле» интерактив сервисы эшли башлады. Күзәтчелек органнары белән үзара хезмәттәшлек йомгаклары буенча эшмәкәрләрнең фикерләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы җыя. Алынган кире элемтә бизнесның инспектор визитыннан канәгатьлек дәрәҗәсен аңларга, тикшерү үткәргәндә күзәтчелек органнары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны ачыкларга мөмкинлек бирәчәк. Кире элемтә алу механизмы эшлекле климатны яхшыртуга һәм бизнеска административ басымны киметүгә юнәлдерелгән. 2020 елның декабрендә 43 бәяләмә тутырылган, шул ук вакытта сораштырылучыларның 93% үткәрелгән тикшерү белән канәгать. Сораштыру дәвам итә.

Проект федераль дәрәҗәдә хуплау алды:

2019 елда АСИ оештырган Россия Федерациясе субъектларының иң яхшы практикалары һәм социаль-икътисадый үсеш инициативалары конкурсында «Тикшерелгән бизнес» интернет-ресурсы «Цифрлы үсеш» номинациясендә җиңүче дип танылды. Практика «Смартек»та - социаль-икътисадый үсеш буенча төбәкләрнең нәтиҗәле идарә карарларын алмашу буенча цифрлы платформада урнаштырылган, бу ресурсны илнең башка субъектларына таратырга мөмкинлек бирде (2020 елда интернет-ресурс Новгород өлкәсендә һәм Хабаровск краенда кулланылды);

«Тикшерелгән бизнес» Татарстан практикасын Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин 2020 елның 13 ноябрендә «Яңа заман өчен көчле идеяләр» яңа проектларын эшләтеп җибәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы форумында хуплады.

Республикада Максатчан модельне гамәлгә ашыру буенча координатор-методолог буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан хокук бозуларны профилактикалау өлешендә зур эш башкарыла.

Эшмәкәрләргә уңайлы булсын өчен хакимият органнарының рәсми сайтларында «Дәүләт/муниципаль контроль (күзәтчелек)» дигән махсус бүлекләр булдырылган. Контроль-күзәтчелек органнары хезмәткәрләре өчен ел саен квалификация күтәрү курслары, вакыттан-вакытка түгәрәк өстәлләр, семинарлар уздырыла, законнарны аңлату буенча методик материаллар чыгарыла.

2020 елда республикада түбәндәге чаралар уздырылды:

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының контроль-күзәтчелек һәм рөхсәт итү эшчәнлеге департаменты директоры урынбасары К.Д. Никитин (29 гыйнвар) катнашында түгәрәк өстәл;

инспектор составының квалификациясен күтәрү буенча ике белем бирү программасы (28 – 30 гыйнвар һәм 12 – 14 август);

«Россия Федерациясендә эшмәкәрләрнең хокукларын коррупция практикаларыннан яклау» проекты кысасында «Россия Федерациясендә төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә контроль-күзәтчелек эшчәнлегенә хәвеф-хәтәр юнәлешле якын килү» ике көнлек тренингы - ПРЕКОП II (14 – 15 февраль);

федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре катнашында Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең һәм «Ачык Татарстан» проектын гамәлгә ашыруның сыйфатын күтәрү һәм һәркем алырлык итү буенча ведомствоара эш төркеме утырышы (10 апрель һәм 22 декабрь). Утырышлар йомгаклары буенча 2020 елда юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә һәм (яисә) алар тарафыннан файдаланыла торган, уртача, сизелерлек, түбән хәвеф-хәтәр категориясенә яисә куркынычның 4, 5, 6 классына кертелгән җитештерү объектларына карата контроль чаралар санын киметү турында тәкъдимнәр бирелде;

Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен кертү буенча чаралар планын («юл картасын») гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем утырышы (28 май, 17 июль һәм 30 июль);

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән «Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре» темасына видео-конференция элемтәсе форматындагы киңәшмә (6 октябрь).

*Җайга салу йогынтысын бәяләү*

2020 елда җайга салу йогынтысын бәяләү (алга таба – ҖСБ) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы алты Татарстан Республикасы норматив хокукый акты (алга таба – НХА) проектына карата үткәрелде. Эшмәкәрләрнең иҗтимагый оешмалары фикерен исәпкә алып, гавами консультацияләр нәтиҗәләре буенча өч проект буенча тискәре нәтиҗәләр әзерләнгән, проектлар эшләп бетерү өчен эшләүчеләргә җибәрелгән.

Даими нигездә НХАның факттагы йогынтысын бәяләү һәм экспертиза үткәрелә. 2020 елда ике НХА карата фактик йогынты бәяләве, бер НХА карата - экспертиза үткәрелде. Үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча җайга салуның сайланган ысуллары нигезле дип танылды.

Казан шәһәрендә ҖСБ процедурасы 2015 елның гыйнварыннан бирле уздырыла. 2020 елда ҖСБ процедурасы НХАның 90 артык проектына карата үткәрелгән.

2020 елда ҖСБ институты 29 муниципаль берәмлектә һәм Чаллы шәһәр округында гамәлгә кертелде. ҖСБ процедурасын гамәлгә кертү функциясе җаваплы затларга беркетелгән. Муниципаль дәрәҗәдә ҖСБ кертүне оештыру өчен методик материаллар җибәрелде.

Моннан тыш, ҖСБ институтын камилләштерү кысаларында төбәкләрнең дәүләт хакимияте органнарының федераль дәрәҗәдә норма чыгару процессында катнашу дәрәҗәсен күтәрү өчен 2018 елдан башлап норматив хокукый актлар

проектларын аларның Россия Федерациясе субъектларының икътисадый үсешенә һәм чыгым йөкләмәләренә йогынтысы предметына бәяләү кертелде. Россия Икътисади үсеш министрлыгының ҖСБ турындагы бәяләмәләрен әзерләгәндә, Россия Федерациясе субъектлары тәкъдимнәрен исәпкә алып, төбәкләрнең икътисадый үсешенә йогынты ясый торган нигезләмәләргә карата позиция мәҗбүри тәртиптә чагылдырыла.

Татарстан Республикасы әлеге эштә актив катнаша, 2020 елда 17 проект каралды, республиканың позициясен исәпкә алып, алга таба 3 проектка карата тискәре нәтиҗәләр формалаштырылды.

*«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы)*

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы төрле социаль әһәмияткә ия проблемалар, шулай ук бизнес проблемалары турында мәгълүматны үз эченә алган гражданнарның һәм эшмәкәрлек субъектларының белдерүләрен бастырып чыгару һәм карау системасыннан гыйбарәт. Система 2012 елның апрелендә эшли башлаган. Белдерүләр 62 категория буенча кабул ителә, шул исәптән территорияләрне төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык, юл хәрәкәтен оештыру, юлларны карап тоту, коррупциягә каршы тору, сәүдә, реклама, хезмәт мөнәсәбәтләре һәм башка өлкәләрдә, шул исәптән эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенә һәм аларның хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлегенә бәйле кагыйдәләрне бозу.

2020 елда «Халык контроле» мобиль кушымтасы 14 мең тапкырдан артык күчереп алынган, 76,5 меңнән артык мөрәҗәгать бастырылган, шуларның 59,4 меңе уңай хәл ителгән, бу 77,7% тәшкил итә, 12,2 мең (15,9%) планлаштырылган, эштә 0,9 мең мөрәҗәгать (1,2%), 3,9 мең мөрәҗәгать (5,2%) мотивлаштырылып кире кагылган.

Дәүләт сатып алулары

2020 елда Татарстан Республикасында икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итүгә, шул исәптән сатып алулар өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эш башкарылды. Аерым алганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елда заказчыларга төзелгән контрактның бәясен һәм аны үтәү срокларын үзгәртү, контрактның һәм гарантия йөкләмәләренең үтәлешен тәэмин итү таләпләрен билгеләмәү хокукын бирә торган боерыклары чыгарылды.

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) вәкаләтләре кысаларында Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан 50 млн сумнан артык башлангыч (максималь) бәясе белән үткәрелә торган сатып алулар мониторингы нәтиҗәләре буенча 33 бозу ачыкланды. Анализ күрсәтүенчә, заказчылар тарафыннан аларның гомуми саныннан 45 проценты сатып алу объектын тасвирлаганда җибәрелә. Моннан тыш, Дәүләт комитеты тарафыннан республика гомуми белем бирү оешмалары өчен туклану продуктларын сатып алу буенча конкурс процедуралары мониторингы уздырылды, аның барышында Татарстан Республикасының 7 муниципаль берәмлегендә бозулар ачыкланды.

Хисап елында заказчыларга методологик ярдәм күрсәтү кысаларында Дәүләт комитеты тарафыннан, «Татарстан Республикасының Сатып алуларны үстерү үзәге» акционер җәмгыяте белән берлектә, 29 белем бирү чарасы оештырылды, аларда

заказчыларның 700дән артык белгече катнашты. Моннан тыш, ел саен сатып алулар өлкәсендә белгечләрнең белем дәрәҗәсен билгеләү һәм тәэмин итү максатларында Дәүләт комитеты автоматлаштырылган тест үткәрә, 2020 елда анда 3 200 белгеч катнашты.

Республикада Сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасын модернизацияләү һәм эшләп бетерү даими нигездә тәэмин ителә. Мәсәлән, 2020 елда, үтәлгән контрактларны, шулай ук кече сатып алулар буенча контрактларны исәпкә алып, товарлар бәяләрен анализлау функционалы уңышлы гамәлгә ашырылды. Шулай итеп, республика заказчылары кирәкле товарларны кайтартуга контрактлар бәяләрен нәтиҗәлерәк дәлилләячәк.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасының сатып алулары өлкәсендә Электрон документлар әйләнеше системасын кертү хисабына заказчылар белән кайтартучылар арасында төзелгән контрактлар буенча беренчел документлар белән юридик яктан әһәмиятле алмашу тәэмин ителә. 2020 елда сатып алулар өлкәсендә бердәм электрон хезмәттәшлек сервисын булдыру максатларында әлеге система белән Такснет һәм Тензор электрон документлар әйләнеше операторлары системалары арасында роуминг гамәлгә ашырылды. 2021 елда СКБ-Контур электрон документлар әйләнеше операторы белән роумингны гамәлгә ашыру планлаштырыла.

Коррупция куркынычларын минимальләштерү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан:

заказчылар тарафыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда куллана торган документларның 11 бертип формасы һәм контрактларның 24 формасы эшләнде;

дәүләт һәм муниципаль заказчыларына мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау турында белешмә-истәлекләр җибәрелде;

заказчыларга илкүләм проектларының төбәк өлешен гамәлгә ашыру максатларында төзелгән контрактлар буенча сыйфатсыз товар белән тәэмин итү куркынычлары турында мәгълүмат бирелде.

Бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларына караганда, республика заказчылары тарафыннан Контракт системасы турындагы закон нигезендә бастырып чыгарылган сатып алуларның гомуми суммасы 151,6 млрд сум тәшкил итте (бердәнбер кайтартучының сатып алуларын исәпкә алмыйча). Төзелгән контрактлар нәтиҗәләре буенча бюджет акчасын экономияләү 3,8 процент тәшкил итте. Шул исәптән муниципаль заказчылар тарафыннан гомуми суммасы 22,8 млрд сумнан артык булган сатып алулар бастырып чыгарылды. Төзелгән контрактлар нәтиҗәләре буенча бюджет акчасын экономияләү 6,4 процент тәшкил итте.

Ел йомгаклары буенча 169 млрд сумга, шул исәптән муниципаль заказчылар тарафыннан 30 млрд сумга контрактлар төзелде.

Кече күләмле сатып алулар буенча 12,8 млрд сумга контрактлар төзелде, бу төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтеннән 7 процент тәшкил итә.

2020 ел дәвамында гомуми суммасы 6,4 млрд сумга 983 үзәкләштерелгән сатып алулар башкарылды. Үткәрелгән сатып алулар процедуралары йомгаклары буенча бюджет акчасын экономияләү 8,3 процент тәшкил итте. Сатып алуларның гомуми күләменнән контрактларның 75 проценттан артыгы республика оешмалары белән төзелде.

Республиканың 10 муниципаль районы өчен тукленуны оештыруга (493 млн

сумга) һәм сөт продукциясе белән тәэмин итүгә (518 млн сумга) үзәкләштерелгән сатып алулар үткәрелде.

Аерым юридик затлар өчен килешүләр кысаларында гомуми суммасы 9,57 млрд сумга 700дән артык сатып алулар урнаштырылды. Үткәрелгән конкурентлы сатып алулар нәтиҗәләре буенча бюджет акчасын экономияләү 21 процент тәшкил итте.

2020 елда кайтартучылар тарафыннан тәкъдим ителә торган товарның туры килү-килмәвенә сатып алулар мониторингы оештырылды, анда контракт бәясе 25 проценттан да күбрәк төшкән иде.

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү

Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү ел саен (2007 елдан башлап) Россия Федерациясе Президентының тиешле указларын үтәү кысаларында үткәрелә.

Ел саен дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре (алга таба — федераль күрсәткечләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) докладлары формалаштырыла, аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары рейтингы төзелә.

Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү системасына даими рәвештә төзәтмәләр кертелә.

Хәзерге вакытта субъектлар эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган 20 күрсәткеч нигезендә уздырыла.

Башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эше белән индикатив идарә итү, дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк органнары тарафыннан куелган бурычларга ирешү эшен үтәли планлаштыру буенча нәтиҗәле төзелгән система Татарстан Республикасы өчен барлык кертелә торган үзгәрешләргә сизгер чара күрергә мөмкинлек бирә.

Министрлыклар һәм ведомстволар эшчәнлегенең максатлары, бурычлары һәм нәтиҗәләре бәйләнешен тәэмин итүнең төп инструменты булып Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеге индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе (алга таба — Идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе) тора.

Идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе республиканың социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә формалаштырыла һәм анда Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы һәм «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы указларында, Татарстан Республикасы Президенты Юлламасында, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый

үстерү стратегиясендә билгеләнгән өстенлекле бурычларның үтәлешен чагылдыра торган төп индикаторлар һәм төбәкләр рейтингы формалаштырыла торган федераль күрсәткечләр бирелә.

Идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана. 2020 елга ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2020 ел, 21 февраль, 125 нче карары белән расланды.

# ИННОВАЦИЯЛӘР

## Инновацияле үсеш

Хәзерге заман шартларында дөньякүләм икътисадый системага интеграцияләнгән конкурентлыкка сәләтле инновацион икътисадны формалаштыруның иң мөһим өстенлекләре булып технологик үсешне тизләтү, кластер сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт, фән һәм бизнес институтларының үзара тыгыз бәйләнеше ярдәмендә төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту тора.

2020 елда яңа коронавирус инфекциясе таралу белән бәйле тискәре зыяннарны кичергән икътисадны торгызу темпларын тизләтү һәм аның халыкара конкурентлыкка сәләтен арттыру өчен инновацион проектларга, компанияләрнең инновацион активлыгын, шул исәптән аларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү аша арттыруга ставка ясарга кирәк.

Кече һәм урта эшкуарлыкны технологик үстерүгә зур игътибар бирелергә тиеш. Аның үсеше өчен яңа эшләнмәләрне апробацияләү һәм гамәлгә кертү өчен грант чаралары рәвешендә өстәмә финанслау җәлеп итү зур ярдәм булып тора.

Республиканың эшләп чыгаручыларына ярдәм күрсәтү максатларында 2020 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы технологик компанияләрне үстерүгә һәм инновацияләрне коммерцияләштерү мәсьәләләрен хәл итүгә этәргеч бирә торган ярдәм күрсәтү программаларының киң комплексын гамәлгә ашыра торган Фәнни-техник өлкәдә предприятиеләрнең кече формаларын үстерүгә ярдәм күрсәтү фонды (алга таба — Инновацияләргә ярдәм күрсәтү фонды) белән актив хезмәттәшлек итте.

2020 елда Инновацияләргә ярдәм күрсәтү фонды белән эш йомгаклары түбәндәгеләр:

катнашуга республиканың 596 гариза бирүчесе җәлеп ителде;

119 инновацион проектка ярдәм күрсәтелде;

республика проектлары өчен гомуми суммасы 720,8 млн сумга (2019 елда – 648,5 млн сумга) федераль финанслау җәлеп ителде.

Моннан тыш, республикада хуҗалык һәм фәнни эшчәнлекнең барлык инфраструктура элементлары диярлек булдырылды, алар эшчәнлек төрләре, башкарыла торган функцияләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең характеры һәм күләме һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм итү ысуллары буенча аерылалар.

Республика инновация инфраструктурасы чылбырында төп звенолар булып, элеккечә, мәйданчыкларның специализациясен исәпкә алып, инновацион компанияләрне үстерүгә ярдәм итүче технопарк структуралары кала. Әлеге мәйданчыкларда республика үсешенең өстенлекле юнәлешләре: мәгълүмат технологияләре, химия һәм нефть химиясе, машина төзелеше продукциясе, медицина технологияләре һәм биотехнологияләр һ.б. буенча инновацияләр генерацияләнә. Әйтик, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның үз илебезнең программа тәэминатын эшләүдә специальләшкән ике мәйданчыгында (Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә) 2020 ел йомгаклары буенча 140тан артык компания эшләде. «Идея» инновация-җитештерү технопаркы, шулай ук кече инновацион

компанияләрнең үсеше өчен барлык шартларны тудыра торган мәйданчыгында 2020 елда 88 резидент эшләде. «КНИАТ» акционер җәмгыяте технопаркында 48 резидент урнаштырылды.

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2020 елның 15 гыйнварындагы Юлламасын үтәү йөзеннән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан инновацион үсеш институтларын реформалаштыру башланды, ул аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыруга һәм илкүләм максатларга ирешүгә юнәлдерелде.

Инновацион эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү, югары рисктагы технологик проектларны гамәлгә ашыру принципларының бердәм системасын булдыру максатларында, шулай ук 2020 елның 31 июлендәге 309-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 2020 елның 4 сентябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Төбәк инновацион үсеш институтлары исемлеге төзелде, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 ноябрь, б-2573 нче боерыгы белән әлеге институтларның эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары беркетелеп расланды.

2021 елда бу юнәлештәге эш стартапларны сайлап алу һәм аларга ярдәм күрсәтү буенча экспертиза үткәрү тәртибен, рискларны һәм рисклар белән идарә итү инструментларын бәяләү критерийларын, шулай ук рискларны бәяләү методикасын регламентлаштыра торган документларны эшләү юнәлешендә дәвам итәчәк. Болар барысы да дәүләт, үсеш институтлары һәм технологик эшкуарлар мәнфәгатьләре балансын саклап калырга мөмкинлек бирәчәк.

2020 елда фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне планлаштыруның үзәкләштерелгән инструментын формалаштыру һәм фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга дәүләт заказларын формалаштыру эше дәвам итте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 июль, 593 нче карары белән Инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе (алга таба – Хөкүмәт комиссиясе) составы һәм аның турында нигезләмә актуальләштерелде, ул кабул ителгән документ нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе линиясе буенча экспертиза үткән инновацион проектларны һәм фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне карап тикшерәчәк һәм аларны дәүләт программаларына кертүне тәкъдим итәчәк. Әлеге карар белән тәкъдим ителгән фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрнең һәм инновацион проектларның Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанс һәм матди-техник ресурсларга ихтыяҗын нигезләү мәсьәләләрен, шулай ук Татарстан Республикасында интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм индивидуальләштерү чараларына хокуклар белән идарә итү системасы нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләрен карап тикшерү өлешендә Хөкүмәт комиссиясенең функцияләре беркетелә.

Инновацион эшчәнлекнең алга таба үсеше интеллектуаль милек өлкәсен үстерү белән тыгыз бәйләнгән. 2016 елдан «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2016 –

2021 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлгә ашырыла. 2020 елда Ярдәмче программа 4 юнәлешне үз эченә алды:

предприятиеләрнең интеллектуаль милкенә хокуклар белән идарә итү системасын булдыру;

«Татарстан Республикасының интеллектуаль потенциалы» мәгълүматлар банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын (алга таба – «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы) эшләү һәм алып бару;

интеллектуаль милек өлкәсендә белем бирү чараларын үткәрү;

Татарстан Республикасы продукциясен Россия Федерациясеннән читкә чыгару кысаларында предприятиеләрнең патент стратегияләрен тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү.

Ярдәмче программада куелган бурычлар кысаларында 2020 елда «Экология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең, «Химпродукт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең, «Алтиком» сәүдә-сәнәгать компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кече һәм урта бизнес предприятиеләрендә интеллектуаль милек белән идарә итү өлкәсен тикшерү үткәрелде, аның торышы анализланды, шулай ук патент буенча төп технологик юнәлешләрне эзләүләр башкарылды. Бу эш йомгаклары буенча предприятиеләргә инновацион бизнес-процесслар белән идарә итү һәм аларны интеллектуаль милек белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасына тоташтыру буенча тәкъдимнәр бирелде.

2020 елда шулай ук «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын камилләштерү, модернизацияләү һәм тарату буенча эшчәнлек алып барылды. 2020 елның июнендә республика инноваторларына инновацион карарлар һәм перспектив проектлар булдыруда һәм аларны эшләтеп җибәрүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы платформасының рәсми презентациясе виртуаль режимда үткәрелде. Платформа интеллектуаль милек объектларын теркәү буенча консультацияләр алырга, инновацион бизнеска ярдәм күрсәтү чаралары турындагы мәгълүматтан файдаланырга, шулай ук Инновацияләргә ярдәм күрсәтү фондыннан грант алуга заявкалар формалаштырырга мөмкинлек бирә.

2020 ел дәвамында «Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан, «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы мөмкинлекләрен файдаланып, консультация, мәгълүмати һәм эксперт ярдәме күрсәтелде. Платформадан файдаланучылар өчен 20дән артык ачык сессия үткәрелде, 200дән артык проектка «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы платформасы аша ярдәм күрсәтелде.

Федераль дәрәҗәгә чыгару максатларында «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы «Яңа вакыт өчен көчле идеяләр» форумында катнашты, форумның төп максаты икътисадны һәм социаль өлкәне яңадан эшләтеп җибәрергә, илне үстерү буенча технологик стратегия эшләргә, шулай ук үз идеяләрен һәм проектларын гамәлгә ашыра, яңа икътисадый шартларда Россиянең тотрыклы үсешен тәэмин итәргә сәләтле практикаларны тиражлый башлауга әзер булган

командаларны оештырырга ярдәм итәчәк идеяләр эзләүдән тора. «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы форумда Россиянең барлык төбәкләре тарафыннан тәкъдим ителгән проектларының 1000-ТОПына (1 425 идеядән 119 нчы урын) керде.

Ярдәмче программа чараларын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү бурычларын хәл итү максатларында, 2020 елның 23 ноябреннән 25 декабренә кадәр «Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан, өстәмә һөнәри белем бирүче «Кадрлар әзерләү буенча төбәк уку-укыту үзәге» хосусый мәгариф учреждениесе белән берлектә, һөнәри яңадан әзерләүнең «Интеллектуаль милек объектларын коммерцияләштерү һәм алар белән идарә итү» белем бирү программасы буенча белем бирү чаралары үткәрелде.

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Интеллектуаль милек буенча федераль хезмәт арасында Татарстан Республикасында интеллектуаль милек өлкәсен үстерүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итү турында 2019 елның 10 июнендәге С-131-ОТ/Д01 номерлы өчьяклы килешүне үтәү кысаларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Patent Cooperation Treaty (PCT) процедурасы (халыкара патентлау) буенча интеллектуаль милек объектларына Татарстан Республикасыннан бирелгән заявкалар өлешен арттыру буенча йөкләмәләр кабул ителде.

Шуңа бәйле рәвештә 2020 елда, «Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе белән берлектә, Ярдәмче программаның «Татарстан Республикасы продукциясен Россия Федерациясеннән читкә чыгару кысаларында предприятиеләрнең патент стратегияләрен гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү» дигән яңа чарасы эшләнде. Аның кысаларында республиканың 11 предприятиесенә чит ил патентын бирү буенча төрле хезмәтләр күрсәтелде, алар техник чишелешнең патент сәләтен бәяләү һәм халыкара заявка бирүгә документлар комплектын әзерләү максатларында патент тикшеренүләрен үткәрүне үз эченә ала.

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

Татарстан Республикасының инновацион төбәк имиджын арттырырга һәм алдынгы позицияләрен ныгытырга;

тышкы базарларда продукция сатуны саклауны көчәйтергә;

өстәмә финанслау инструментын алырга (лицензия түләүләре, бозулар буенча компенсацияләр);

Татарстан Республикасы җитештерүенең гомуми күләмендә чимал булмаган продукция экспорты өлешен арттырырга;

республиканың бюджет барлыкка китерүче эре компанияләренә чит ил технологияләрен файдаланучы статусыннан технологияләр эшләүче статусына күчәргә;

дөньякүләм базарда инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттырырга.

Шулай итеп, заманча инновацион инфраструктура булу, норматив-хокукый базаны үстерү, актив дәүләт ярдәме күрсәтү һәм интеллектуаль милек базарын үстерү республикада инновацион активлыкны арттыру өчен уңай шартларны саклап калырга

мөмкинлек бирде.

***«Иннополис – югары технологияләр һәм инновацияләр шәһәре» флагман проекты***

***Шәһәрнең социаль инфраструктурасы***

2020 елда Иннополис шәһәре үзенең бишьеллыгын билгеләп үтте. Хәзер анда 5,2 меңнән артык кеше яши. Иннополиста төрле дәрәҗәдәге торак йортлар – күпкатлы йортлардан алып таунхауска һәм коттеджларга кадәр каралган. 1 572 фатирга исәпләнгән 22 күпфатирлы йорт төзелде, күчемсез мөлкәтнең 88 меңнән артык кв. метры арендага бирелде. Һәркем өчен заманча һәм кыйммәт булмаган уңайлы торак арендаларга һәм сатып алырга мөмкин.

Иннополиста резидентлар компанияләренең хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләре әгъзалары яшәү өчен беренче класслы социаль, мәгариф һәм спорт инфраструктурасы, һөнәри үсеш һәм үсү өчен киң мөмкинлекләре булган уникаль шәһәр мохите булдырылды. Шәһәрдә балалар бакчалары (шул исәптән хосусый), мәктәп, IT-лицей, спорт комплексы, медицина үзәге, балалар поликлиникасы, даруханәләр эшли, ашыгыч медицина ярдәме бригадасы кизү тора. Шәһәрдә уңайлы яшәү өчен «Бәхетле», «Пятерочка», «Магнит» һәм «Магнит Косметик» супермаркетлары, банклар, почта бүлекләре, күпфункциональ үзәкләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре, автомобиль юу урыннары, шиномонтаж, «Яндекс-Драйв» каршеринг-сервисы, хобби-үзәк, сәнгать мәктәбе һәм тел үзәге эшли.

2020 елның августында 2,2 мең кв. метр гомуми мәйданлы ике катлы бинада урнашкан ArtSpace яңа шәһәр киңлеге ачылды. ArtSpace – ул ял итү, белем алу, иҗат итү урыны, чаралар үткәрү һәм кинолар күрсәтү өчен зур залны, hack-space, коворкинг, театр студиясен, сынлы сәнгать студиясен, бию классын, тавыш яздыру студиясен, кафены үз эченә ала.

Иннополис шәһәре территориясендә полициянең участок вәкаләтле вәкиленең эше, шәхси саклау предприятиесенең мобиль төркеме ярдәмендә җәмәгать тәртибен саклау, шулай ук шәһәр халкы өчен хәрби исәпкә алу процессы оештырылды.

Шәһәрдә велосипедта йөрү өчен инфраструктура булдырылды. Автотранспорт чаралары өчен акыллы домофоннар һәм электр зарядлы станцияләр эшли. 2018 елдан шәһәр территориясендә «Яндекс.Такси» компаниясенең пилотсыз автомобильләре белән тест үткәрелә. 2 ел эчендә шәһәр халкы һәм кунаклары алардан якынча 12 мең тапкыр файдаланды.

Иннополис шәһәре халкы һәм кунаклары, махсус икътисадый зонасы резидентлары, хезмәткәрләре өчен Казан – Иннополис маршруты буенча пассажирлар йөртү оештырылды.

Иннополис шәһәренә күчәргә әзер булган 23 мең белгечнең резюмесы буенча мәгълүматлар базасы булдырылды. Шәһәрдә яшәүчеләрне эшкә урнаштыру мәсьәләсе буенча эш оештырылды.

Шәһәр халкының һәм сервис хезмәтләренең заявкаларын һәм мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу һәм контрольдә тоту системасы кертелде, яңа шәһәр халкына һәм кунакларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча «Консьерж сервис» бердәм хезмәте эшли.

Иннополиста 376 компания теркәлгән, алар тарафыннан 2020 елда барлык

дәрәҗәләрдәге бюджетларга 1,4 млрд сум (2019 елга караганда 820,6 млн сумга күбрәк) салым түләнде.

*Иннополис шәһәренең белем бирү инфраструктурасы*

Иннополис шәһәренең интеллектуаль үзәге булып «Иннополис» университеты тора, ул мәгълүмат технологияләре һәм робототехника өлкәсендә белем бирү, тикшеренүләр һәм эшләнмәләрдә специальләшә һәм Россия өчен уникаль: мәгариф, фән һәм бизнес ярашу моделе буенча эшли.

2020 елда «Иннополис» университетында уку өчен бакалавриат, магистратура һәм аспирантура программалары буенча 161 илдән 12 896 гариза керде. 244 кеше студент, 21 кеше аспирант булды. Бюджет урыннарына алынган студентларның бердәм дәүләт имтиханнары буенча уртача баллы – 95,7. «Югары икътисад мәктәбе» илкүләм тикшеренү университетының, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгының һәм «Яндекс» компаниясенең уртак мониторингы мәгълүматлары буенча, «Иннополис» университеты 2020 елда 1 курска укырга кергән студентларның бердәм дәүләт имтиханнары буенча иң югары уртача балл белән югары белем бирүче мәгариф оешмалары өчлегенә керде.

2020/2021 уку елында университетта 181 дисциплина буенча 804 студент белем ала. Уку «Информатика һәм исәпләү техникасы» бакалавриат программасы һәм магистратураның 4 программасы – «Программа тәэминатын эшләү белән идарә итү», «Компьютер куркынычсызлыгы һәм челтәрләре», «Робототехника һәм компьютер күз күреме», «Мәгълүматлар анализы һәм ясалма интеллект» буенча уза.

2020 елда «Информатика һәм исәпләү техникасы» дигән әзерлек юнәлеше буенча аспирантурага өченче сайлап алулар үткәрелде. Укулар инглиз телендә алып барыла. Укытучылар составы 24 илдән дөньякүләм мәгълүмат технологияләре индустриясендә эш тәҗрибәсе булган 251 фәнни-педагогик хезмәткәрдән тора.

2020 елда университетны 173 студент: 78 магистр һәм 95 бакалавр тәмамлады. Барлыгы «Иннополис» университеты тарафыннан 642 кеше чыгарылды. Университетны тәмамлаучылар түбәндәге әйдәп баручы ИТ-компанияләргә чакырулар алды: «МТС», «Дигинавис», «РТК Софт-Лабс», NNG, «БарсГруп», «Документлар әйләнеше системасы», «Портавита», «Маркетплейс Технологии», «Тинькофф», «Сбербанк», S7 һ.б. чакырулар алды.

«Иннополис» университеты Россиянең фәнни-тикшеренү эшчәнлеген коммерцияләштерү сыйфаты буенча иң уңышлы югары уку йортларының берсе дип санала. Университет интеллектуаль эшчәнлек буенча 178 нәтиҗә формалаштырды һәм аларны теркәүгә бирде. Университет портфелендә икътисадның реаль секторының түбәндәге әйдәп баручы компанияләре белән хезмәттәшлек итә торган 71 коммерция проекты бар: «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, «Норникель» гавами акционер җәмгыяте, «Россети» гавами акционер җәмгыяте, «РусГидро» гавами акционер җәмгыяте, «Северсталь» гавами акционер җәмгыяте һәм башкалар. Университетның уртак проектларының гомуми суммасы – 11 млрд сум.

2020 елның декабрендә «Иннополис» университеты структурасында ясалма интеллект институты төзелде, ул ясалма интеллект өлкәсендә гамәлдәге

лабораторияләрне һәм булган эшләнмәләрне һәм тикшеренүләрне берләштерде. Институт белгечләре «Газпром» гавами акционер җәмгыяте өчен геомеханик модельләштерү һәм торба эчендә диагностика ясау сервислары, «Росатом» дәүләт корпорациясе һәм «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте өчен ясалма интеллект кулланыла торган проектлар, урман һәм авыл хуҗалыгы өчен космоста һәм һавада төшереп алынган мәгълүматлар буенча объектларны тану өчен алгоритмнар өстендә эшлиләр. Институт базасында медицина сурәтләре буенча патологияләрнең автомат диагностика ясауның цифрлы платформасы булдырыла, шул ук вакытта медицина сурәтләрен анализлау сервислары Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәренең медицина оешмаларында пилот режимда кулланыла инде.

«Иннополис» университетында шулай ук бүленгән реестр системалары өлкәсендә алдынгы тикшеренү үзәге булдырылды. Үзәкнең төп бурычларыннан берсе – тулысынча верификацияләнгән блокчейн-платформа эшләү. Эшләнмәләр нәтиҗәләрен сәламәтлек саклау, финанс технологияләре, сәнәгать, энергетика, мәгариф, авыл хуҗалыгы тармакларында кулланырга планлаштырыла. Әйтик, үзәк кысаларында «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте өчен блокчейн технологиясе кулланыла торган «Һава судноларына ягулык салу» тармак проекты гамәлгә ашырыла. «Россия почтасы» акционер җәмгыяте өчен технологик компетенцияләр үзәге төзелде.

«Иннополис» университеты базасында «Робототехника һәм мехатроника компонентлары технологиясе» юнәлеше буенча Илкүләм технологик инициативаның Компетенцияләр үзәге эшли, аның эшчәнлеге фәнни тикшеренүләр үткәрүгә, робототехниканың өстенлекле юнәлешләре буенча белем бирү программаларын эшләүгә һәм, технологик консорциум белән берлектә, индустриаль проектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән. Үзәкнең консорциумына дөньяның 56 алдынгы технологик компаниясе һәм университеты керде. Шулар арасыннан иң мөһимлеләре: «Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте, «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте, «Газпром-нефть» гавами акционер җәмгыяте, «РУСАЛ» акционер җәмгыяте, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, KUKA Robotics җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, шулай ук Санкт-Петербург илкүләм тикшеренү мәгълүмат технологияләре, механика һәм оптика университеты, Ерак Көнчыгыш федераль университеты, Волгоград дәүләт техник университеты, Ижевск дәүләт техник университеты. Үзәк структурасында антропоморфлар һәм сәнәгать робототехникасы, барлык пилотсыз транспорт төрләре, нейрофән өлкәсендә өйрәнү һәм эшләнмәләр ясау белән шөгыльләнүче берничә лаборатория бар.

Университетта Россиянең түбәндәге иң эре компанияләре белән 63 фәнни-тикшеренү проекты гамәлгә ашырыла: «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, «Норникель» гавами акционер җәмгыяте, «Россети» гавами акционер җәмгыяте, «РусГидро» гавами акционер җәмгыяте, «Северсталь» гавами акционер җәмгыяте һ.б.

Биредә KIA Soul һәм Hyundai Santa Fe базасында җиңел транспорт һәм КАМАЗ автомобиле базасында йөк транспорты өчен үзләренең оча һәм җир өстендә йөри торган пилотсыз эшләнмәләре ясала. Пилотсыз җайланмалар тышкы тәэсир итә торган факторларга (юл шартларына, һава торышына, яктыртуга, хәрәкәттәге башка катнашучыларның гамәлләренә) чыдам булачак.

Университетта кабель роботы эшләнә, ул стадионнарда телевидениегә һәм киногa төшергәндә, эре габаритлы әйберләрне (корабльләр, самолетлар) җыю яки буяу, зур объектларның 3D-басмасын эшләү өчен, хәрәкәт симуляторларында, тернәкләндерү өчен экзоскелетлар эшләүдә кулланылырга мөмкин булган. Уникаль проект – склад хезмәткәрләренә ярдәм итә торган MR-системасы эшләнде.

Университет белгечләре тарафыннан биеклектән егылуга һәм бәрелгәннән соң эшкә яраклылыгын саклап калуга сәләтле дрон ясалды. Эшләнмәне Tensodrone дип атадылар. Прототибы заказга ясалган пружиналар белән карбон көпшәләрдән һәм кевлар җепләрдән эшләнде. Башка вак элементлары 3D-принтердан карбон һәм йомшак пластикта чыгарыла.

«Газпром» гавами акционер җәмгыяте белән килешү кысаларында университет белгечләре тарафыннан комплекслы геомеханик модельләштерү өчен үз илебез платформасының прототибы булдырылды. Система токымның геомеханик тасвирнамәләрен исәпкә ала, бу исә коллекторның фильтрация үзлекләре һәм сыешлыгы дөреслеген арттыра. Әлеге чишелеш чит ил программа тәэминатына бәйлелекне киметәчәк.

Илкүләм технологик инициативаның «Аэронет» юл картасы кысаларында университет тарафыннан, сурәтләрне анализлау өчен компьютер күз күремен һәм машина белән укуны кулланып, Татарстан Республикасының 4D-геомәгълүмат моделен булдыру проекты гамәлгә ашырылды. 2019 елның июненнән болыт геомәгълүмат платформасы саклау зоналарын мониторинглау, капиталь төзелеш объектларын тану, урман үзгәрешләрен, авыл хуҗалыгын мониторинглау сервислары өчен файдалануга кертелде.

«Иннополис» университетында авыл хуҗалыгы культуралары авыруларына оператив диагностика үткәрү һәм аларның үсешен фаразлау өчен «Телеагроном» системасын үстерү өстендә эшли. Университет экспертлары үсемлек авыруларының 50 мең эталонын җыйды. Пилот предприятиеләрендә технологияләрне апробацияләү күрсәтүенчә, аны куллану үсемлекләрне саклау чараларына һәм ашламаларга чыгымнарны 30 процентка киметергә мөмкинлек бирәчәк. Волгоград өлкәсе, Татарстан һәм Башкортстан республикаларының пилот хуҗалыкларына 5 авыл хуҗалыгы культурасы (арпа, арыш, солы, кишер һәм бәрәңге) буенча тәкъдимнамәләр бирелде. Агропредприятиеләр билгеләп үткәнчә, «Телеагроном»ны куллану нәтиҗәсендә бәрәңгенең уңдырышлылыгы – 30 процентка, ашлыкның уңдырышлылыгы контроль варианттан 40 процентка артты, туфракның иммунитеты 5 процентка яхшырды, бу лаборатория тикшеренүләре белән раслана. 2020 елда сервис Мари Иле Республикасының агропредприятиеләрендә кулланыла башланды.

«Иннополис» университеты Institutions Active in Technical Games Research уеннарын тикшерүче югары уку йортларының 100 дөньякүләм топына керде, 87 нче урын алды һәм бу исемлектә бердәнбер Россия югары уку йортларыннан булды. Әлеге тикшеренүләр белән университетта Ясалма интеллект лабораториясе шөгыльләнә.

2020 елда университет U-Multirank рейтингының «Уртак халыкара фәнни басмалар» категориясендә 8 нче урынны яулады, бу категориянең 25 топына кергән беренче Россия югары уку йорты булды.

«Иннополис» университеты Россиянең 153 алдынгы ИТ-компаниясе һәм

барлык дөнья буйлап 56 академик партнер белән хезмәттәшлек итә. Анда 15 лаборатория һәм 7 фәнни үзәк ачылды.

2020 елда университетның югары уку йортына кадәрге белем бирү идарәсе тарафыннан онлайн-форматта 13 олимпиада, конкурслар, турнирлар һәм хакатоннар уңышлы оештырылды һәм үткәрелде, аларда 12 661 кеше катнашты, төрле яшь төркемнәрендәге һәм уку юнәлешендәге 908 мәктәп укучысы өчен 27 белем бирү сменасы һәм җыен оештырылды.

Innopolis Open университетының үз халыкара олимпиадасы ел саен дүрт юнәлеш буенча уздырыла: информатика, мәгълүмати иминлек, математика, робототехника. Анда катнашу өчен югары уку йортына 18 илдән якынча 10 000 заявка керә.

2020 елның ноябрендә «Клик» кризиска каршы лидерлар әзерләү программасы буенча укыту тәмамланды. 20.35 Университет белән берлектә, «Иннополис» университетында 5 249 кеше – дәүләт компанияләре, федераль һәм төбәк хакимият органнары хезмәткәрләре укыды.

Россия Федерациясенең 64 субъектыннан 5 740 дәүләт хезмәткәре, дәүләт компанияләре, министрлыклар һәм ведомстволар хезмәткәрләре «CDO (Chief Data Officer) мәгълүматларга нигезләнгән идарә» һәм «CDTO (Chief Digital Transformation Officer) – цифрлы трансформация җитәкчесе» программалары буенча белем алды.

«Иннополис» университеты катнашында 2 120 кеше шәхси цифрлы сертификатлар бирү программасы буенча цифрлы компетенцияләргә бушлай укыды, 41 компаниядән («Сбербанк» гавами акционер җәмгыяте, X5 Retail Group, «ВТБ» гавами акционер җәмгыяте, «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, Русгидро һ.б.) 4 мең кеше заманча технологияләрне бизнес-процессларга кертү буенча корпоратив белем алуның 80 программасы буенча укыды.

2016 елдан ИТ-компанияләр өчен кадрларны тизләтеп әзерләү программалары буенча 18 мең заявка кабул ителде, көндезге һәм дистанцион уку форматлары буенча 522 белгеч әзерләнде, программаны тәмамлаучыларның 80 проценты Иннополис шәһәрендә эшләүче әйдәп баручы компанияләргә эшкә урнаштырылды.

«Иннополис» университетыннан тыш, шәһәрнең мәгариф инфраструктурасында «Иннополис мәктәбе» һәм «Иннополис лицее» дәүләт автоном мәгариф учреждениеләре аерым роль уйный.

*«Иннополис» махсус икътисадый зонасы*

«Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы (алга таба – «Иннополис» махсус икътисадый зонасы) Россия һәм халыкара ИТ-компанияләре проектларын үстерү үзәге булып тора. 2020 ел йомгаклары буенча аның территориясендә 101 резидент һәм 26 партнер эшчәнлек алып барды. Компанияләр тарафыннан 3,8 мең эш урыны булдырылды, 28 млрд сумнан артык акча инвестицияләнде (мәгълүматлар 2020 ел ахырына арта бара торган йомгак белән). Махсус икътисадый зона резидентлары һәм партнерлары арасында – Яндекс», Schneider Electric, «Магнит ИТ Лаб», «ИТ X5 Технологияләр» «Ачык мобиль платформа», ICL төркеме компанияләре, Россия Саклык банкы, Тинькофф Банк. Төп юнәлешләр арасында – ясалма интеллект, мәгълүмат куркынычсызлыгы, 4.0 индустрия, медицина технологияләре һәм финанс технологияләре өлкәләрендә

эшләнмәләр.

«Иннополис» махсус икътисадый зонасында салым ташламаларыннан тыш, компанияләргә югары квалификацияле белгечләр эзләүдә һәм аларны Иннополис шәһәрендә гамәлгә ашырыла торган проектлар өчен Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм БДБ илләреннән релокацияләүдә түләүсез ярдәм күрсәтелә. Шулай ук «Иннополис» махсус икътисадый зонасы компанияләргә белгечләрнең эшләнмәләренә тест үткәрү, һөнәри үсеше өчен шартлар тудыра.

2020 елда «Иннополис» махсус икътисадый зонасының Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов рәислегендәге Күзәтү советы 1,3 меңнән артык эш урыннары булдырачак 31 яңа компания проектларын хуплады, алар арасында – «Россия почтасы», «Альфа-Банк», «С7 Техлаб», «Акронис-Инфозащита», «Точка» банкы.

Иннополис шәһәре үсешенең яңа драйверы булып эре инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру булачак, иң мөһимнәренең берсе – «Росатом» дәүләт корпорациясенең «Иннополис» мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау үзәге. Проект «Росэнергоатом» концерны» акционер җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашырыла («Росатом» дәүләт корпорациясе составына керә). Мәгълүматлар эшкәртү үзәге гомуми куәте 16 МВт булган 2 000 стойкаларга кадәр киңәйтү мөмкинлеге булган 500дән алып 1 000гә кадәр сервер стойкаларына кадәр сыйдырачак. Төзелеше 2021 елның IV кварталында башланачак, файдалануга тапшыру 2022 ел ахырына планлаштырылды. «Иннополис» мәгълүматларны эшкәртү үзәге Идел буе федераль округында иң эреләрнең берсе һәм «Росэнергоатом» концерны» акционер җәмгыятенең мәгълүматлар эшкәртү буенча дүрт терәк үзәгенең берсе булачак.

2020 елдан «Иннополис» махсус икътисадый зонасында стартапларга ярдәм күрсәтү программасы гамәлгә ашырыла. Алар салым ташламаларыннан файдалана һәм яшь компанияләр өчен формалашу этабында кирәк булган сервислар пакетын ала. Сервислар бизнес-администрацияләү процессларын шактый гадиләштерергә, шулай ук акчаны экономияләргә, чишелешләрне эшләү өчен ресурслар тупларга мөмкинлек бирә.

2020 елның 9 июлендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В.Мишустин «Иннополис» махсус икътисадый зонасы технопаркында булды һәм Россиянең эре ИТ-компанияләре җитәкчеләре белән тармакны үстерү мәсьәләләре турында фикер алышты. Индустрия лидерлары – «Яндекс» компанияләре җитәкчеләре, Mail.ru Group, Telegram, «Касперский лабораториясе», «1С», Group IB компанияләре җитәкчеләре ИТ-секторны реформалаштыру буенча үз идеяләрен әйтте.

2020 елның декабрендә «Иннополис» махсус икътисадый зонасында 1,5 мең эш урынына исәпләнгән 28 мең кв. метрдан артык мәйданлы икенче технопарк – Н.И.Лобачевский исемендәге технопарк файдалануга тапшырылды. 2021 елның II кварталында анда беренче резидентлар компанияләрен урнаштыру планлаштырыла.

2019 ел йомгаклары буенча «Иннополис» махсус икътисадый зонасы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан Россиянең техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналары арасында иң нәтиҗәлесе дип танылды. Эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү 25 абсолют һәм чагыштырма микъдари күрсәткеч буенча башкарылды. Резидентларның эшчәнлеге, федераль һәм төбәк бюджетлары акчасын инфраструктура төзүгә кертү рентабельлеге, идарә органнары эшчәнлеге һәм

башка параметрлар исәпкә алынды.

Моннан тыш, 2020 елда «Иннополис» махсус икътисадый зонасы fDi magazine журналының Global Free Zones of the Year (Financial Times эшлекле газетасының бүлекчәсе) халыкара рейтингына керде, өч номинациядә алдынгы урыннарны яулады: «Хезмәткәрләр өчен инфраструктура», «5G гамәлгә кертү» һәм «Сизгер офис пространствосы».

*Фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү*

Татарстанның иң мөһим конкурент өстенлекләре рәтенә икътисадның шактый фәнни-техник потенциалы керә. Республиканың конкурентлы үсеш резервлары – университетлар, фәнни оешмалар, реаль сектор предприятиеләренең һәм яңа төзелгән фәнни һәм инновацион инфраструктура объектларының үзара тыгыз бәйләнешендә.

Республика фәнни комплексы соңгы еллар дәвамында үсешнең арта бара торган динамикасын үзгәрешсез күрсәтә. Республикада тикшеренүләр һәм эшләнмәләр белән шөгыльләнүче фәнни оешмалар һәм персонал саны югары дәрәҗәдә тотрыклыланды, югары квалификацияле фәнни-педагогик кадрлар әзерләү һәм аларны аттестацияләү системасы эзлекле рәвештә эволюцияләнә, фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләрнең матди-техник һәм финанс-икътисадый нигезләрен өзлексез ныгыту дәвам итә.

Тикшеренүләр һәм эшләнмәләр белән шөгыльләнүче персоналның штат саны 16 меңнән артык кеше тәшкил итә, алар арасында 13,2 мең кеше – штат хезмәткәрләре һәм якынча 3 мең кеше – гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча эшләүче хезмәткәрләр. Штаттагы фәнни хезмәткәрләрнең гомуми санында тикшеренүчеләр өлеше 53,7 процент, техниклар – 10,6 процент, ярдәмче персонал һәм башка хезмәткәрләр 35,7 процент тәшкил итә.

Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре өлкәсенең институциональ структурасы 39 фәнни-тикшеренү учреждениесеннән, 9 проект-конструкторлык бюросыннан, 36 югары уку йортыннан, 21 корпоратив фәнни-тикшеренү институтыннан һәм конструкторлык бюросыннан, шулай ук 24 оешмадан гыйбарәт. Фәнни үзәкләрнең гомуми саны буенча (129 берәмлек) Татарстан Россиянең Инновацион төбәкләре ассоциациясе әгъзалары составында алдынгы урыннарны били.

Фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләрен коммерцияләштерү мәсьәләләрендә югары мәктәпнең роле өзлексез көчәюе күзәтелә. Республиканың әйдәп баручы югары уку йортлары каршында 100дән артык кече инновацион предприятие төзелде.

Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструклык эшләре өлкәсендә мондый нәтиҗәләргә ирешү, күпчелек очракта, тикшеренүләрне һәм эшләнмәләрне дәүләт тарафыннан җайга салуга карата программалы-максатчан якын килү аркасында мөмкин булды, аның концептуаль нигезләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган, аның составында «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасы гамәлдә булган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасында бирелде.

Хәзерге вакытта 2017 – 2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга Татарстан

Республикасы мәгарифен үстерүнең тармак стратегиясе кабул ителде, ул 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 14 ноябрь, б-2957 нче боерыгы белән фән, технологияләр һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләре, шулай ук критик технологияләр исемлеге расланды, бу фәнни эшләнүләрне стимуллаштыруның төбәк моделенә тагы да төгәлрәк, акцентланган характер бирергә мөмкинлек бирә.

Тикшеренүләрнең һәм эшләнмәләрнең төбәк секторын үстерү процессларында югары уку йортлары зур роль уйный, аларга фәнни программаларны һәм проектларны фондлаштыруга еллык чыгымнарның җыелма күләменең якынча 30 проценты туры килә, бу Татарстанда фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыруның иң алдынгы һәм базар чынбарлыкларына адекват булган университет моделе формалашуның ышанычлы маркеры булып тора.

Мәгариф һәм фән үсешенә бәйле булган мәсьәләләрне карап тикшергәндә республика дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, мәгариф һәм фәнни оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында, шулай ук мәгариф һәм фәнни-техник үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтенең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Президенты каршында Мәгариф һәм фән буенча совет эшли. Әлеге киңәшмә органы Татарстанның дәүләт фәнни-техник сәясәтен гамәлгә ашыруга кагылышлы стратегик һәм оператив-тактик мәсьәләләр буенча гавами фикер алышу өчен иҗтимагый эксперт мәйданчыгы ролен үти.

Фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлекне популярлаштыру, шулай ук яшьләрнең тикшеренү һәм инновация активлыгын стимуллаштыру максатларында республикада шактый санда адреслы стимуллар һәм аларның фәнни эзләнүләрен бүләкләү һәм аларга ярдәм итү механизмнары кулланыла. Бу төрле конкурслар, фәнни премияләр, грантлар һәм стипендиаль программалар, мәсәлән:

Татарстан Республикасының махсус Дәүләт стипендиясе;

яшь галимнәргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы грантлары һәм премияләре;

«Мәгарифтә инновацияләр» һәм «Перспектива» номинацияләрендә «Илле иң яхшы инновацион идея» республика конкурсы;

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе стипендиясе;

студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре мэрының исемле стипендияләрен алуга конкурс.

2020 елда Татарстан Республикасы фәнни-белем бирү комплексының әйдәп баручы оешмаларыннан 24 яшь галим Россия яшь галимнәренең фәнни тикшеренүләренә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Россия Федерациясе Президенты грантларын алу конкурсында җиңде. Грантлар Россия Федерациясе фәнен, технологияләрен һәм техникасын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре буенча фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр уздыру чыгымнарын финанслау өчен, шулай ук Россиянең яшь галимнәренә – фәннәр кандидатларына һәм докторларына

һәм Россия Федерациясенең әйдәп баручы фәнни мәктәпләре коллективлары әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү өчен бүлеп бирелә.

2020 елда фән һәм техника өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясен генераль директор Е.Р.Ибраһимов җитәкчелегендәге «В.Б.Шнепп исемендәге НИИтурбокомпрессор» акционер җәмгыятенең галимнәр һәм инженерлар коллективы алды.

*«Фән» илкүләм проекты*

Татарстанның һәм тулаем илнең фәнни комплексын алга таба үстерү траекториясе киләчәктә «Фән» илкүләм проектын тормышка ашыру максатларында һәм бурычларында, өстенлекләрендә һәм динамикасында шактый биреләчәк. 2020 елда республика оешмалары аның мөһим чараларын үтәүдә сизелерлек уңышларга иреште.

Югары һөнәри белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба – Казан федераль университеты) тикшеренү учреждениеләре консорциумы җитәкчелегендә 2020 елда «Планетаның сыек углеводородлары запасларын рациональ үзләштерү» дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк төзү хокукын отты. Проект кысаларында тикшеренүләр һәм эшләнмәләр программасы планлаштырыла, алар Россия фәненә нефть ятмаларын разведкалау һәм эшкәртүнең иң актуаль мәсьәләләре буенча дөньяда лидер позицияләрен алырга, шулай ук нефть чыгаруның экологик яктан максималь экологик булуын тәэмин иткәндә дөнья базарында аның конкурентлык үзкыйммәтенә ирешү өчен технологияләр булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, 2020 елда Казан федераль университеты, шулай ук югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе һәм «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фән учреждениесе приборлар базасын киңәйтүне, реконструкцияләүне һәм технологик яктан яңадан җиһазландыруны тәэмин итә торган чараларны фондлаштыру өчен федераль бюджеттан якынча 600 млн сум акча җәлеп итте.

Республиканың берничә югары уку йорты инжиниринг үзәкләрен ачу конкурсында актив катнаша. Югары белем бирүче «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе Татарстан Республикасыннан җиңүче дип танылды. Аның каршында төзелгән инжиниринг үзәге фәнни эшчәнлек продуктларын коммерцияләштерү өчен өстәмә стимул булачак һәм ярдәм итәчәк.

*«Татарстан технологик инициативасы» флагман проекты*

Технологик трендлар һәм төп технологияләрдә һәм инновацияләрдә булган башлангычлар нигезендә Татарстан Республикасының акыллы икътисады кластерларын булдыру «Татарстан технологик инициативасы» комплекслы флагман проекты кысаларында гамәлгә ашыру күздә тотыла, ул акыллы икътисадның 10 инновацион кластерын үз эченә ала.

*«Акыллы материаллар»*

«Акыллы материаллар» инновацион кластеры, эре нефть-газ химиясе һәм

энергетика бизнесы, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, яңа полимер һәм композицион, наноструктурлаштырылган материаллар эшләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче яңа инновацион компанияләр төзү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелде.

2020 елда «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 март, 188 нче карары белән расланган 2020 – 2024 елларга һәм 2034 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексын үстерү программасы эшләнде, аның төп максаты – якындагы елларга функциональ материаллар (яңа һәм композицион материаллар, суперконструкцияле пластмассалар, функциональ өстәлмәләр) һәм урта һәм кече тонналы химия продукциясенең башка төрләрен үстерү өчен чимал һәм фәнни база булдыру.

Татарстан Республикасы, Мәскәү, Саратов, Тула, Ульяновск өлкәләре территориясендә UMATEX (Росатом) инициативасы буенча «Чиксез композитлар» төбәкара сәнәгать кластеры төзелде. 2018 елдан кластер Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Сәнәгать кластерлары һәм махсуслаштырылган оешмалары реестрына кертелде. Аның составына 9 республика предприятиесе керә: «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Татнефть-Пресскомпозит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «КАМАТЕК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ТАТ-Адвенира» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Алабуга-Волокно» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «РЕКОН» фәнни-җитештерү фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ЗАРЯД» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Пыялалы пластик торбалар заводы» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «СМП-Механика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте. Тагын бер предприятиене – углеводородлы-пыялалы җепселләрдән күләмле-армирлаштырылган тоташ тукымалы преформалар җитештерүчене – «СмартСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен (Казан шәһәре) кертү карала.

2021 елда «Алабуга» сәнәгать җитештертү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясендә «Алабуга-Волокно» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте предприятиесе тарафыннан 5 мең тоннага кадәр куәтле ПАН-прекурсор җитештерүе эшләтеп җибәреләчәк. Әлеге җитештерү Россия Федерациясендә композит материаллар җитештерүнең тулы чылбырын локальләштерү бурычын хәл итә, бәясе һәм сыйфаты буенча конкурентлы углеводород җепселләрен өзлексез җитештерүне гарантияли, импортны алмаштыру программасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итә.

*«Акыллы машиналар»*

«Акыллы машиналар» инновацион кластерын формалаштыру транспорт чараларын җитештерү юнәлешләрен һәм транспорт чараларын җитештерү өчен кулланыла торган җиһазларны конвергенцияләү өлкәсендә яңа инновацион компанияләр барлыкка килү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. 2020 елда «Эйдос-Робототехника» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте

– Россиянең сәнәгать роботларын һәм автоматлаштырылган чишелешләрне эшләп чыгаручысы һәм җитештерүчесе тарафыннан А12 роботы нигезендә реагентларны дозалаштыру буенча комплекс эшләтеп җибәрелде, коронавирсны ачыклау өчен тестлар үткәргәндә РНКны аеру өчен машина булдырылды.

2020 елның февралендә «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте «Челнок» дип аталган, машина йөртүче өчен кабинасы булмаган КАМАЗ-3373 электр пилотсыз йөк автомобиленә патент алды. Бу борт платформасы булган автоном аккумуляторлы электромобиль. Компаниянең яңа эшләнмәсе – үзәгендә урнашкан симметрияле платформа белән ике күчәрле шасси, аның ике күчәре дә борыла, бу зур булмаган участокларда маневр ясаганда мөмкин кадәр күбрәк борылырга мөмкинлек бирә.

*«Акыллы җиһазлар»*

«Акыллы җиһазлар» инновацион кластеры, нефть-газ химиясе, энергетика һәм машина төзелеше кластерларының төп предприятиеләре, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, электрон һәм технологик җиһазларның киң спектрын эшләү һәм җитештерү белән шөгыльләнүче инновацион компанияләрнең яңалары барлыкка килү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

«КАИ-Лазер» сәнәгать лазерлы технологияләренең төбәк инжиниринг үзәгендә фюзеляж ян паненленең яңа эретеп ябыштырыла торган югары технологияле корроззиягә чыдам алюминий эретмәсеннән конструктив-охшаш үрнәкләрен әзерләү буенча фәнни-тикшеренү эше үткәрелде. Хезмәттән файдаланучылар түбәндәгеләр мөмкин булырга мөмкин – авиация, суднолар төзелеше һәм сәнәгатьнең башка тармак предприятиеләре. Хәзерге вакытта утырма тягачлар асылмасының авыр итеп төялгән кронштейннарны лазер белән кисү һәм эретеп ябыштыру технологияләрен адаптацияләү эшләре алып барыла. Төп кулланучы – «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте.

2020 елда «Цифрлы технологияләр үзәге» акционер җәмгыяте тарафыннан 40 эре предприятиегә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына төгәл кою, өч үлчәмле бастыру һәм өч үлчәмле сканерлау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтелде.

Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техник институты – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фән учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе магнит кыры индукциясе 0.06 Тл булган «ТМР-0.06-КФТИ» магнит-резонанс томографларын эшләде. Бу аппарат Казан физика-техник институтында элегрәк эшләнгән 0.02 Тл «ТМР-0.02-КФТИ» томографының яңартылган варианты булып тора. Хәзерге вакытта Казан физика-техник институтында авыруларны һәм буыннар травмаларын диагностикалау өчен магнит кыры индукциясе 0.4 Тл булган яңа махсуслаштырылган томограф эшләнә. Томограф «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге тарафыннан «Градиент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән берлектә эшләнә. Машина укый торган ысуллар ярдәмендә, шулай ук патологияләрне диагностикалау өчен машина укуны куллану мөмкинлекләрен кулланып, томографик сурәтләрнең сыйфатын яхшырту (тавышны әкренәйтү, төгәллекне арттыру) мөмкинлеге буенча эксперименталь тикшеренүләр үткәрелде. Магнит кыры индукциясе 0.4 Тл булган махсуслаштырылган травматологик магнит-

резонанс томографында куллану өчен тикшеренү вакытын кыскартуга юнәлдерелгән импульс программалары булдырылды. Уйлап чыгару өчен патент (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының югары белем бирүче «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе белән берлектә) һәм Электрон исәпләү машинасы өчен программаны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (Казан дәүләт медицина академиясе – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирүче «Россия медицина өзлексез һөнәри белем бирү академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалы белән берлектә) алынды.

*«Акыллы мәгълүмат технологияләре»*

Заманча мәгълүмат технологияләре Татарстан Республикасы икътисадының төрле өлкәләрендә кертелә һәм шәһәрләрнең һәм, тулаем алганда, төбәкнең цифрлы үсеше дәрәҗәсен арттыру, куркынычсызлык, көндәлек бурычларны автоматлаштыру, энергия һәм ресурсларны саклауны тәэмин итү һ.б. өчен интеллектуаль чишелешләрне куллануга юнәлдерелгән.

2009 елдан Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә «112» бердәм номеры (алга таба – 112 системасы) буенча кичектергесез оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасы эшли. Республикада 112 системасы үзәкләштерелгән төзелеш схемасына ия. Республиканың бөтен территориясендә барлык мобиль һәм билгеләп куелган элемтә операторлары абонентларыннан «112» номеры буенча чакыруларны кабул итү ике чакыруларны эшкәртү үзәгендә – Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә рус һәм татар телләрендә тәүлек режимында алып барыла. Вакыйгалар турында мәгълүмат муниципаль берәмлекләрнең кичектергесез оператив хезмәтләренә һәм бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтләренә махсус программа тәэминатында формалаштырыла торган вакыйгалар карточкаларын диспетчерлаштыру юлы белән тапшырыла.

2020 елда «112» номерына 1 372,4 мең шалтырату кабул ителде, 961,8 мең вакыйгалар карточкасы (2019 ел дәрәҗәсенә карата 118 процент) ясалды. Иң күп санда мөрәҗәгатьләр медицина ярдәме күрсәтү (49 процент) буенча, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы эшчәнлеге юнәлеше (26 процент) буенча, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы линиясе (25 процент) буенча керә. «112» номерына шалтыратулар ашыгыч хезмәтләргә кергән барлык шалтыратуларның 50 процентын тәшкил итә.

2020 ел йомгаклары буенча 112 системасының телефония базасында универсиададан соң складларда калган 500 Avaya 1603SW телефоны ярдәмендә Татарстан Республикасы поликлиникаларының эчке телефония системасы җәелдерелгән. Моннан тыш, «112», «103», «122» һәм «8800» (COVID) һәм поликлиника челтәре чакыруларын эшкәртү үзәкләре шалтыратуларының эчке интеграциясе (гомуми файдаланудагы телефон челтәренә чыкмыйча, номерны җыю мөмкинлеге) тормышка ашырылды.

Электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы

Татарстан Республикасында 2005 елдан бирле гамәлдә. Ул Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, бюджет оешмаларында эш башкару һәм документлар әйләнеше процессларын автоматлаштыру өчен билгеләнгән. 2020 ел ахырына электрон документлар әйләнешендә 45 меңнән артык кулланучы теркәлде, гомуми күләме 61 терабайттан артып киткән 18,7 миллионнан артык документ (2006 елдан) булдырылды.

Модернизацияләү кысаларында электрон документлар әйләнешенә читтән торып керүне оештыру тәэмин ителде; гражданнарга аларның мөрәҗәгатьләре буенча хәбәрнамәләр җибәрүне автоматлаштыру эшләренең беренче этабы гамәлгә ашырылды, законнар чыгару эшчәнлеген тәэмин итүнең автоматлаштырылган ярдәмче системасында рольләрне һәм хокукларны чикләү тәэмин ителде.

2021 елга электрон документлар әйләнешен «Россия почтасы» акционер җәмгыяте системасы белән интеграцияләү; гражданнарга аларның мөрәҗәгатьләре буенча хәбәрнамәләр җибәрүне автоматлаштыру эшләренең икенче этабын гамәлгә ашыру; гражданнар мөрәҗәгатенә җаваплар җибәрүне автоматлаштыру, килештерү срогы үтәлмәгәндә йөкләмәләр исемлеген автомат рәвештә килештерү функцияләрен булдыру планлаштырылды.

2023 елга 4.0 нче бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасының яңа версиясенә күчү планлаштырыла, ул документларны тулы текст нигезендә эзләү, контроль документларны үтәү буенча җитәкчеләр өчен дашбордларны күрсәтү, гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча йөкләмәләрнең үтәлешен анализлау һәм билгеле бер маршрут буенча документларны килештерү мөмкинлеген бирәчәк.

*«Smart-мәгариф»*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрүнең шәхсиләштерелгән системасы турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 6492/14 номерлы боерыгы нигезендә 2016 елдан республикада мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү буенча шәхсиләштерелгән модель гамәлгә ашырыла, аның аша ел саен квалификация күтәрү программаларын гамәлгә ашыру хокукына лицензиясе булган 19 оешма базасында якынча 20 мең педагог белем ала. Казан федераль университеты, өстәмә һөнәри белем бирүче «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты төп оешмалар булып тора, анда укытучыларның 80 проценттан артыгы белем ала.

Республикада гамәлгә ашырыла торган модельнең төп идеясе шунда ки, һәр педагог курсларның темаларын һәм эчтәлеген формалаштыру этабында да да, шулай ук «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында программаларны сайлау этабында да катнаша. Бу максатларда «Квалификация күтәрү» модуле булдырылды. Шәхси кабинетлар аша педагоглар үз һөнәри үсеше траекториясен сайлап алуны гамәлгә ашыра.

**Сәламәт яшәү рәвеше**

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелек сәламәтлеге үзәкләренең, иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту буенча төбәк һәм муниципаль программаларның яңа моделен гамәлгә кертү буенча 20 пилот проектына, шулай ук «Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә (сәламәт тукълануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны кертеп) мотивацияләү системасын формалаштыру» төбәк проектында каралган эш урыннарында сәламәтлекне ныгыту буенча корпоратив программаларга кертелде.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Йогышлы булмаган авыруларны профилактикалауны оештыру һәм гамәлгә ашыру һәм медицина оешмаларында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чараларын үткәрү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 октябрендәге 1177н номерлы боерыгы (2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керде) нигезендә республикада Казан, Әлмәт, Зеленодольск, Түбән Кама шәһәрләрендә 4 җәмәгатьчелек сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәгенең эше оештырылды.

Республиканың 22 муниципаль берәмлегендә халык арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту буенча муниципаль программалар расланды (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гомуми саныннан 48,8 процент; проект кысаларында индикатор – 20,0 процент).

Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәткәрләрнең сәламәтлеген ныгыту буенча корпоратив программалар эшләү һәм кертү гамәлгә ашырыла.

«Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятендә скрининг программалары тормышка ашырылды (эш бирүчеләр акчасы исәбеннән). Ел саен «Хатын-кызлар сәламәтлеге», «Ир-атлар сәламәтлеге», «Ир-атлар кардиоскринингы» программалары буенча медицина тикшерүләре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары һәм башкарылганда мәҗбүри башлагыч һәм даими медицина караулары (тикшерүләре) үткәрелә торган эшләр исемлеген һәм Авыр эшләрдә һәм зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләгән хезмәткәрләрне мәҗбүри башлангыч һәм даими медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 12 апрель, 302н боерыгы белән нигезендә медицина тикшерүләре билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «2020 елда тематик профилактик декадалар үткәрү турында» 2019 елның 19 ноябрендәге 2261 номерлы боерыгы кысаларында берничә профилактик чара гамәлгә ашырылды. Тематик республика акцияләре, конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләр, матбугат конференцияләре, Бөтенроссия мәгълүмат кампанияләрендә, шул исәптән онлайн-форматта катнашу оештырылды. 2020 елда сәламәт яшәү рәвеше, йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау, дөрес туклану, хәрәкәт активлыгының файдасы турында текст һәм видео рәвешендәге тематик материаллар «Республика җәмәгатьчелек сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең рәсми сайтында урнаштырылды.

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән хезмәттәшлек итү дәвам итә. «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең «Медицина» махсуслаштырылган программаларында, «Татарстан-Яңа Гасыр» телеканалының «Исәнмесез», «Манзара» программалары кысаларында «Сәламәтлек» рубрикасында, «Эфир» телеканалының «Сәламәтлекнең гади рецептлары»

программасында тематик материалларны киң яктырту оештырыла.

Республиканың наркология хезмәте тарафыннан эчкечелекне һәм алкоголизмны, шул исәптән гомуми белем бирү мәктәпләренең өлкән сыйныфлар, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучылары, Татарстан Республикасының югары уку йортлары студентлары арасында беренчел профилактикалау чаралары, сәламәтлек саклау, мәгариф, эчке эшләр өлкәсендә белгечләр өчен наркологик авыруларны профилактикалау буенча укыту-методик семинарлар үткәрелә.

Тернәкләндерү программаларында коммерциячел булмаган оешмалар һәм традицион дини конфессияләр вәкилләре актив катнаша. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте һәм Казан Епархиясе арасында өчьяклы килешү кысаларында бәйлелек белән авыручы кешеләр арасында бергәләп эш алып барыла.

**«Экотуклану»**

Татарстан Республикасында органик авыл хуҗалыгын үстерү буенча максатчан эш алып барыла. Органик авыл хуҗалыгы – «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләре җыелмасы, аларны гамәлгә ашырганда әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итүгә, кешенең сәламәтлеген ныгытуга, туфракның уңдырышлылыгын саклауга һәм торгызуга юнәлдерелгән алымнар, ысуллар һәм технологияләр кулланыла.

2020 елның 1 гыйнварыннан «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 280-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керде.

Республика органик җитештерүенең хокукый базасын һәм органик авыл хуҗалыгын үстерү өчен уңайлы шартлар тудыруга булышлык күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршында республика дәүләт хакимияте органнары вәкилләрен, галим-практикларын һәм фермерларын берләштерә торган Органик продукция (2018 елның 3 августындагы 280-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә җитештерүе туры килә торган экологик чиста авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек) җитештерү буенча иҗтимагый совет үз эшчәнлеген дәвам итә.

2021 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта кабул ителгән «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проекты эшләнде.

Татарстан Республикасында «Татарстанның органик продукты» органик продукция җитештерүен ихтыярый сертификацияләү системасы эшли, аның башкарма органы булып «Республика «Тест-Татарстан» сертификацияләү методик үзәге» ябык акционер җәмгыяте тора. Сертификация узган органик продукция товарын җитештерүчеләр бердәм дәүләт органик продукция җитештерүчеләр реестрына кертелә һәм аларга үз продукциясен органик продукциянең «Органик» бердәм билгесе белән маркалау хокукы бирелә.

**«Тотрыклы энергетика»**

Кластерны үстерү заманча эре энергетикада (акыллы генерация һәм акыллы челтәрләр, яңа аккумуляторлар һәм үткәргечләр һ.б.) яңа технологияләр һәм энергиянең тотрыклы чыганакларын (кояш энергиясе, җил һәм су энергиясе, атом энергиясе, биомассадан һәм көнкүреш калдыкларыннан алына торган энергия) куллану нигезендә инновацион тотрыклы энергетика үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасының барлык кулланучыларын электр һәм җылылык энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү, шулай ук конкурентлык сәләтен арттыру һәм энергетика тармагын тотрыклы үстерүне тәэмин итү өчен энергия системасының җитештерү объектларын модернизацияләү һәм яңа куәтләр кертү беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия.

Соңгы елларда Татарстанда 4 эре энергетика станциясе модернизацияләнде, бу энергетика системасы куәтен 1,2 ГВтка (Казан җылылык электр централе - 2 – 220 МВт, «Түбән Кама җылылык электр централе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – 350 МВт; Казан җылылык электр централе - 3 – 394,4 МВт; Казан җылылык электр централе - 1 – 246 МВт) арттырырга мөмкинлек бирде.

2020 елда «ТАИФ» акционер җәмгыяте «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыятендә ПГУ-495 МВт төзү проектын гамәлгә ашыруны дәвам итте. Моннан тыш, 2023 елда «Казаноргсинтез» гавами акционер җәмгыяте мәйданчыгында 250 МВт суммар электр куәте белән пар-газ җайланмасын төзү планлаштырыла.

Җылылык электр станцияләрен модернизацияләү проектлары буенча узган сайлап алулар йомгаклары нигезендә «Татэнерго» акционер җәмгыятенең Зәй дәүләт район электр станциясендә 850 МВт куәтле пар-газ җайланмасы төзү проекты (2025 елга) тормышка ашырыла. 2020 елның 8 сентябрендә Зәй дәүләт район электр станциясенең яңа пар-газ җайланмасына беренче таш салу тантанасы булды.

Республикада өстенлекле юнәлешләр арасында – углеродсыз энергетиканы, аерым алганда, җил энергетикасын үстерү. Хәзерге вакытта Россиядә җил энергетикасы базарында төп катнашучылар, потенциаль инвесторлар – «Новавинд» акционер җәмгыяте компанияләре («Росатом» дәүләт корпорациясенә керә), «Энел Россия» гавами акционер җәмгыяте белән актив хезмәттәшлек алып баруны гамәлгә ашыра. Яңартыла торган энергия чыганаклары буенча проектларны үстерү кысаларында хезмәттәшлек турында берничә документка (5 килешүгә, 2 юл картасына) имза куелды. Шул ук вакытта җил электр станцияләрен төзү өчен җир кишәрлекләре бирү мәсьәләләре актуаль булып тора.

Республиканың электр челтәре хуҗалыгын модернизацияләү эше дәвам итә. Әйтик, 2020 елда, реконструкциядән соң, ТАССРның 100 еллыгы исемендәге 220 кВ «Зеленодольск» ярдәмче станциясе файдалануга тапшырылды. Беренчел җиһаз һәм, Россиядә беренче тапкыр, реле саклау һәм автоматика җайланмалары функцияләре белән дистанцион идарә итү системасын эшкә кертү модернизация үткәрүнең үзенчәлеге булып тора. Нәтиҗәдә, «Зеленодольск» Россия электр челтәре комплексында иң заманча ярдәмче станцияләрнең берсе булды.

2020 елның августында «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте филиалында – Буа электр челтәрләрендә Югары Ослан район электр челтәренең яңа җитештерү

базасы ачылды һәм 110 кВ Югары Ослан ярдәмче станциясе файдалануга тапшырылды. «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалында Актаныш район электр челтәренең яңа җитештерү базасы ачылды.

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте тарафыннан түбәндәгеләр реконструкцияләнеп бетте:

Куралово-Печище 35 кВ һава линияләрен реконструкцияләп, 110 кВ Югары Ослан ярдәмче станциясе;

110 кВ Идел буе ярдәмче станциясе;

110 кВ Узловая-Исмәгыйль һава линияләре.

Федераль законнар таләпләре нигезендә электр энергиясен исәпкә алуны автоматлаштыру эше үткәрелә. Бөтен республика буенча 2018 елдан электр энергиясен исәпкә алуның интеллектуаль приборлары билгеләнә. 2020 елда «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятендә юридик затларда һәм шәхси йортларда 83 мең интеллектуаль исәпкә алу приборы урнаштырылды. «Татэнергосбыт» акционер җәмгыятендә 33 районның күпфатирлы йортларында 18,4 мең интеллектуаль исәпкә алу приборы урнаштырылды.

Кулланучыларны өзлексез электр белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру, электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыру эшләрен башкару, төп җиһазларны һәм бүлү челтәрләрен яңа заманча технологияләргә күчерү компаниянең 2021 елга өстенлекле бурычларыннан булып кала.

**«Биосистемалар»**

Республика агросәнәгать комплексын фәнни яктан тәэмин итү өчен зур потенциалга ия.

2020 елда Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Актаныш, Минзәлә, Мөслим һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы төренең күптөрлелеген ачыклау буенча фәнни-тикшеренү эше уздырылды, аның йомгаклары үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын мониторинглауны гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып барганда, шулай ук төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган яңа табигать территорияләрен булдырганда кулланыла.

Татарстанда төрле селекция үзәкләренең бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларының 65 сорты районлаштырылды. «Селекция казанышларын сынау һәм саклау буенча дәүләт комиссиясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы 900 сорт үрнәге буенча 30 авыл хуҗалыгы культураларының сортларын сынауны гамәлгә ашыра. 2018 – 2020 елларда бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның 19 сорты районлаштырылды.

Татарстан фәнни-тикшеренү авыл хуҗалыгы институты – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фән учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе (алга таба – Татарстан фәнни-тикшеренү авыл хуҗалыгы институты) 15 авыл хуҗалыгы культурасы буенча (уҗым арышы, уҗым бодае, уҗым тритикале, сабан бодае, арпа, сабан рапсы, борчак, соя, карабодай, тары, бәрәңге, кукуруз, алмагач, чия, слива), орлыкчылыкта 13 культура буенча селекция алып бара.

Татарстан фәнни-тикшеренү авыл хуҗалыгы институты тарафыннан 200дән артык сорт һәм гибрид булдырылды. Тикшеренүләрнең яңалыклары Россия Федерациясенең селекция казанышларына һәм уйлап табуларга 194 патенты белән яклана, шуларның 53се – гамәлдә. Хәзерге вакытта Россия Федерациясенең дәүләт селекция казанышлары реестрына Россиянең 32 төбәгендә кулланыла торган 100дән артык сорт һәм гибрид кертелгән.

2018 – 2020 елларда Татарстан Республикасы предприятиеләре тарафыннан биологик препаратлар куллану 1,5 мәртәбә артты. Җитештерелә торган продукциянең ассортименты шактый киң һәм эчке базарның биологик препаратларга булган ихтыяҗын тулы күләмдә каплый. Республикада биопрепаратлар җитештерү белән «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы, «Биопрепаратлар» фәнни-җитештерү институты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм Bionovatic компанияләр төркеме шөгыльләнә.

**Электрон рәвештә хезмәт күрсәтү**

Дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү республиканың өстенлекле бурычларыннан берсе булып кала. Татарстанда дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү uslugi.tatarstan.ru Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (алга таба – Портал) һәм «ТР хезмәтләре» мобиль кушымтасы аша, шулай ук үз-үзеңә хезмәт күрсәтүнең мәгълүмати терминаллары аша оештырылды.

Порталда электрон хезмәтләр күрсәтү өчен түбәндәге төп функционал гамәлгә ашырылды: электрон сораулар җибәрү, хезмәт күрсәтүгә электрон рәвештә гариза бирү, теләсә нинди банк карталары белән хезмәт күрсәтүләргә online-түләү, электрон чиратларга язылу мөмкинлеге.

Хәзерге вакытта 307 электрон хезмәт һәм сервис гамәлгә ашырылды. 2020 елда 290 миллионнан артык электрон хезмәт күрсәтелде:

250 миллионнан артык электрон сораулар башкарылды;

18 миллионнан артык электрон чиратка язылу гамәлгә ашырылды;

хезмәтләр күрсәтү өчен 10 миллионнан артык электрон гариза тапшырылды;

27 млрд сумнан артык түләүләр башкарылды.

Порталны һәм мобиль кушымтаны үстерү кысаларында 2020 елда түбәндәге чаралар башкарылды:

Лилия дип аталган тавыш ярдәмчесе кулланышка кертелде;

түбәндәге сервислар һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге булды:

беренче бала туу буенча айлык түләүгә гариза бирү;

ведомстводан тыш саклау өчен түләү;

транспорт картасын тулыландыру;

судларга язылу;

кулланучыларга салым бурычлары турында мәгълүмат бирү;

Apple Pay аша түләү өстәлде;

түбәндәгеләр белән интеграцияләү гамәлгә ашырылды:

Порталның «Бердәм дәүләт граждан хәле актлары язулары реестры» мәгълүмат системасы белән;

«ТР хезмәт күрсәтүләре» мобиль кушымтасының Huawei Pushkit белән;

түбәндәгеләр өстәлде:

Touch ID/FACE ID буенча мобиль кушымтага керү мөмкинлеге;

шәхси кабинетта файдаланучыны телефон номеры буенча керә торган шалтырау ярдәмендә авторизацияләү ысулы;

«Яңалыклар» бүлеге булдырылды һ.б.

**«Цифрлы икътисад» илкүләм проекты**

Татарстанда «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының 5 төбәк проекты гамәлгә ашырыла: «Мәгълүмати иминлек», «Цифрлы дәүләт идарәсе», «Цифрлы технологияләр», «Мәгълүмат инфраструктурасы» һәм «Цифрлы икътисад өчен кадрлар».

**Мәгълүмати иминлек**

2020 елда проектны гамәлгә ашыру кысаларында:

республика мәгълүмат системаларын саклауның, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарын саклауның сертификацияләнгән чаралары сатып алынды;

77 хакимият органында мәгълүмати иминлек буенча документлар комплектын актуальләштерергә ярдәм итә торган DocShell системасы гамәлгә кертелде;

10 министрлык һәм ведомство белгечләре «Мәгълүмати иминлек» программасы буенча яңадан әзерләү курсларын (520 аудитор сәгате) үтте;

хакимият органнары җитәкчеләренең 30 урынбасары мәгълүмати иминлек буенча семинар тыңлады.

**Цифрлы технологияләр**

Перспектив инновацион чишелешләр һәм Татарстан Республикасының сәнәгать предприятиеләренә һәм оешмаларына кертү өчен үтәли цифрлы технологияләр өлкәсендә проектлар булдыручы, цифрлы трансформацияләү үткәрүгә әзер булучы белгечләр эзләү һәм үстерү максатларында 2020 елның 24 ноябреннән 11 декабренә кадәр ел саен үткәрелә торган «Цифрлы чемпионнар мәктәбе» чарасы уздырылды. Әлеге чара эчтәлеге буенча технологик стартапларны тизләтеп үстерүгә һәм аларны гамәлгә ашыруга ярдәм итә торган преакселерацион программа булып тора. Чарада үзләренең инновацион чишелешләрен тәкъдим иткән 15 стартап катнашты.

**Мәгълүмат инфраструктурасы**

Проект кысаларында социаль әһәмиятле объектларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтыру гамәлгә ашырыла.

2019 елда Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы Татарстан Республикасының 1 913 социаль әһәмиятле объектын тоташтыру өчен җепселле-оптик элемтә линияләре буенча электрон аукцион үткәрде. Аукционда «Таттелеком» гавами акионер җәмгыятенең төбәк элемтә операторы җиңүче булды, аның белән 1 101 млн сум кыйммәтле контракт төзелде. Татарстан Республикасында социаль әһәмияткә ия объектларны тоташтыру 2019 – 2021 елларда этаплап уздырыла.

2020 елда Интернет челтәренә 733 социаль әһәмияткә ия объект (2019 елда – 498) тоташтырылды, алар арасында 613 объект – Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы заказы буенча этаплап тоташтыру планы нигезендә, 120 объект – өстәмә исемлек буенча. Өстәмә 120 социаль әһәмияткә ия объектны тоташтыру буенча барлык кирәкле эшләр тәмамланды, элемтә хезмәтләре 2020 елның 1 декабреннән күрсәтелә. Хәзерге вакытта 2021 елга социаль әһәмияткә ия объектлар исемлеген верификацияләү эше алып барыла.

**Цифрлы икътисад өчен кадрлар**

Проектның төп бурычы – цифрлы икътисад өчен халыкның цифрлы грамоталылыгын һәм компетенцияләрен күтәрү, талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтү юлы белән югары квалификацияле кадрлар әзерләүне тәэмин итү.

Проект кысаларында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга, ягъни Казан федераль университетында Югары мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар мәктәбе студентларын «Программалы инженерия» юнәлеше буенча укытуга грантлар бирү гамәлгә ашырыла.

«Цифрлы икътисад» коммерциячел булмаган автоном оешмасындагы «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» эш төркеменең 2020 елның 5 октябрендәге карары белән Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең 48 төбәге арасына керде, аның нигезендә шәхси цифрлы сертификатлар бирүнең дәүләт системасында катнашуы расланды. Программаны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча республиканың 3 517 кешесе цифрлы икътисадта таләп ителә торган юнәлешләр буенча квалификация күтәрү программалары буенча дистанцион һәм электрон форматта белем алды.

2020 елда «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесенең (алга таба – «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесе) ИТ-академиясе ике мәйданчыкта өлкән яшьтәге тыңлаучылар өчен түбәндәге белем бирү программалары буенча көндезге укулар уздырды: «Javaда программалаштыру», «Интернет-маркетинг» (Казан шәһәрендә); «Javaда программалаштыру», «C#да программалаштыру», «PhPта программалаштыру», «Pythonда программалаштыру», «SEO-продвижение» (Яр Чаллы шәһәрендә).

Яр Чаллы шәһәрендә «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесе мәйданчыгында «Л.Я.Карпов исемендәге Химия заводы» акционер җәмгыяте (Менделеевск шәһәре) хезмәткәрләре өчен «Профессиональ Excel» юнәлеше буенча корпоратив көндезге укулар уздырылды.

Казан шәһәрендә «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесе мәйданчыгында, Россия Банкы белән берлектә, Javaда программалаштыру буенча укулар уздырыла, аны уңышлы тәмамлаган чыгарылыш укучылары Россия Банкына эшкә урнашачак.

«ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесенең Компетенцияләрне үстерү үзәге «Персональ цифрлы сертификат» федераль белем бирү программасында катнашты, аның кысаларында Россиянең 150дән артык шәһәреннән 560 тыңлаучы таләп ителә торган уку юнәлешләре буенча, шул исәптән 140 кеше онлайн-форматта курслар узды.

«ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесендә балалар өчен белем бирү курсларына һәм мәктәп укучылары һәм студентлар белән һөнәри юнәлеш буенча эшләүгә аерым игътибар бирелә. 2020 елда «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесе

һәм «Барыбыз өчен игелекле дөнья» («Добрый мир для всех») коммерциячел булмаган автоном оешмасы арасында килешү төзелде, аның нигезендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар түләүсез нигездә белем ала (2020 елда 10 кеше укыды). Моннан тыш, балалар өчен түбәндәге уку юнәлешләре буенча курслар уздырыла:

ITQ (Innovation Technology Quality) ял көне мәктәбе (Яр Чаллы шәһәре) 2016 елдан 6 яшьтән алып 12 яшькә кадәрге мәктәп укучыларын һөнәри юнәлеш бирү буенча эш алып бара. Һәр яшь төркеме өчен укытуның уникаль һәм һәркем файдалана алырлык методикасы эшләнде;

«Мәктәп укучылары өчен Pythonda программалаштыру» курсы (2020 елның гыйнварында эшли башлады);

«Робототехника» курсы (Яр Чаллы шәһәре) Legoдан төрле роботлар төзергә һәм программалаштырырга ярдәм итә, шулай ук мисалны эшли торган модельгә кадәр чишеп бетерергә өйрәтә;

программалаштыру нигезләрен өйрәнү буенча «Кодвардс» курсы кече мәктәп яшендәге балалар өчен билгеләнгән;

«Androidта мобиль кушымталар эшләү» курсы. Программаның эчтәлеге балаларның мобиль җайланмалар һәм программалар белән практик эшләүгә кызыксынуын үстерү, мобиль җайланмаларны программалаштыруның төп кагыйдәләре һәм ысуллары турында күзаллауларны формалаштыру, укучыларда модельләштерү һәм экспериментлар ясау барышында логик фикерләүне, конструкторлык сәләтен үстерү максатларында, Android операцион системасы өчен мобиль җайланмаларны программалаштыру нигезләренә өйрәтүне күздә тота.

Кадрлар әзерләүдә «Иннополис» университеты актив катнаша. «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль проекты кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Иннополис» университеты каршында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә белгечләр әзерләү буенча терәк үзәк төзү турында карар кабул ителде. Әлеге эш кысаларында цифрлы нигездә үстерүгә бәйле яңа белем бирү программалары төзеләчәк, алар буенча төрле өлкәләрдә профессионаллар әзерләү, шулай ук бөтен Россия буенча югары һәм урта һөнәри уку йортлары укытучыларының квалификациясен күтәрү планлаштырыла.

«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасы буенча «Иннополис» университеты 6,5 млрд сумнан артык гомуми суммага берничә проект (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 декабрендәге 2110 номерлы карары) алып бара.

«Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2019 елдан 11 меңнән артык кеше укыды.

## ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ

### Җир һәм су ресурсларын нәтиҗәле файдалану

2020 елда республика милкендәге җир кишәрлекләрен реализацияләүдән Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр керү 468,9 млн сум тәшкил итте. Сервитут билгеләү турындагы килешүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына 2,4 млн сум акча керде.

2020 елның 1 гыйнварына республика милкендәге һәм арендага бирелгән җир кишәрлекләренең гомуми мәйданы 3 548,5 гектар тәшкил итә. 2020 елда республика милкендәге җир кишәрлекләрен арендалаудан Татарстан Республикасы бюджетына 75,1 млн сум акча керде.

Җирле бюджетлар керемнәре структурасында җир кишәрлекләрен арендалаудан (2 662,3 млн сум) һәм аларны гамәлгә ашырудан (901,5 млн сум) алынган керемнәр аеруча чагыштырма авырлыкка ия.

Республика җирле үзидарә органнары карамагындагы муниципаль мөлкәттән һәм җирләрдән файдалану нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, 2020 елда өч еллык чорга салым булмаган керемнәрне объектлап планлаштыру гамәлгә ашырылды, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән төзелгән шартнамәләр буенча җир кишәрлекләре һәм мөлкәт өчен аренда түләве буенча керүләргә һәм бурычларга айлык мониторинг үткәрелде.

2020 елда муниципаль берәмлекләр бюджетлары алдында мөлкәт һәм җир кишәрлекләре өчен аренда түләве буенча бурычларны киметү мәсьәләсе актуаль булып калды. 2021 елның 1 гыйнварына мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча җирле бюджетлар алдында бурычлар суммасы 518 млн сум тәшкил итте, шул исәптән мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча – 39,9 млн сум, җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча – 478,1 млн сум. 2020 ел дәвамында бурычларның гомуми суммасы 125 млн сумга артты, шул ук вакытта мөлкәтне арендалау буенча бурыч 7,3 млн сумга кимеде, җир кишәрлекләрен арендалау буенча бурыч 132,3 млн сумга артты.

Җир кишәрлекләрен арендалау буенча бурычлар Татарстан Республикасының 17 муниципаль берәмлегендә: Әгерҗе, Азнакай, Алексеевск, Әлки, Апас, Әтнә, Баулы, Бөгелмә, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Кама Тамагы, Лаеш, Питрәч, Саба, Спас муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә артты.

Мөлкәтне арендалау буенча бурычлар суммасының кимүе республиканың 10 муниципаль берәмлегендә: Әгерҗе, Азнакай, Әтнә, Бөгелмә, Буа, Чүпрәле, Зәй, Зеленодольск, Менделеевск муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә күзәтелә.

*Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен территориаль планлаштыру документлары*

2021 елның 1 гыйнварына республикада 224 муниципаль берәмлек составына керә торган 861 торак пунктның (барлыгы республикада 913 муниципаль берәмлектә 3 119 торак пункт) чикләре кадастр исәбенә куелды.

292 җирлекнең генераль планнары эшләнә, аларны кабул итү 997 торак пунктның чикләрен исәпкә куюны тәэмин итәчәк. 2024 ел ахырына кадәр тагын 397

җирлекнең генераль планнарын эшләү һәм, димәк, 1 261 торак пунктның чикләрен кадастр исәбенә кую планлаштырыла.

«Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесендә 80 (Саба, Әтнә, Тукай, Кукмара, Кама Тамагы, Әлмәт, Лаеш, Балтач, Чүпрәле муниципаль районнарының) генераль планнар проекты эшләнә. Территориаль планлаштыру материалларын стандартлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан, «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, берничә документ эшләнде:

муниципаль берәмлекләрнең генераль планнарын һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләүгә техник биремнәрнең бертип формалары;

муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын әзерләгәндә (корректировкалаганда) һәм раслаганда Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары гамәлләре тәртибе турында методик тәкъдимнамәләр;

муниципаль берәмлекләрнең генераль планнары проектларын әзерләү буенча методик тәкъдимнамәләр;

муниципаль берәмлекләрнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре документациясе составын, эчтәлеген һәм аны рәсмиләштерүне стандартлаштыру буенча методик тәкъдимнамәләр.

Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын стандартлаштыру документларның сыйфатын яхшыртырга, аларның бердәмлеген тәэмин итәргә һәм аларны Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча мәгълүмат системасына кертү бурычын гадиләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

2020 елда Саба муниципаль районы тарафыннан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән муниципаль милеккә 14,5 гектар мәйданлы 4 җир кишәрлеге сатып алынды. Республика милкенә җир кишәрлекләре сатып алынмады.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәсез файдалану иң кискен проблемаларның берсе булып калу дәвам итә. Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча, 2020 елның 1 декабренә Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге файдаланылмый торган җирләрнең 107,5 меңнәр артык гектары ачыкланды, алардан бары 35,5 мең гектары гына авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертелде.

*Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына җир кишәрлекләрен кертү*

2020 елда Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына Казан шәһәре территориясендә 177,41 гектар гомуми мәйданлы 12 җир кишәрлеге кертелде.

*Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү һәм «ДОМ.РФ» акционер җәмгыяте белән хезмәттәшлек итү*

Ана капиталы белән беррәттән җир кишәрлеген түләүсез алу мөмкинлеге күп

гаиләләр өчен мөһим кызыксындыру чарасы булып тора һәм, һичшиксез, гаилә институтын үстерүгә һәм туучылар санын арттыруга ярдәм итә.

Җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча, 2021 елның 1 гыйнварына республикада 66,2 меңнән артык күпбалалы гаилә исәпләнә, шулардан җир кишәрлекләрен алу исемлекләренә 60,6 мең гаилә кертелде. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, күпбалалы гражданнарга җир кишәрлекләре бирү процессын оештыру эше алып барыла. Нәтиҗәдә җир кишәрлекләрен үз милкенә 38,5 мең күпбалалы гаилә алды.

Берничә муниципаль районда җир кишәрлекләре бирү эше өстәмә җир кишәрлекләрен эзләүгә һәм межалау процедурасын үткәрүгә бәйле рәвештә туктатып торылды. Күпбалалы гаиләләр өчен өстәмә җир кишәрлекләре булдыру эшләрен финанслау мәсьәләсе актуаль булып кала. Хәзерге вакытта җир кишәрлекләренә шактый кытлык бар, аларны Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләренең күпбалалы гаиләләренә бүлеп бирү мәсьәләсе кискен тора.

Татарстан Республикасының «ДОМ.РФ» акционер җәмгыяте белән Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлекләренә карата хезмәттәшлек итү дәвам итә.

Хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә Торак төзелешен үстерү һәм Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлекләреннән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү буенча хөкүмәт комиссиясенең (алга таба – Хөкүмәт комиссиясе) республика дәүләт хакимияте органнарына Казан шәһәренең күпбалалы гаиләләренә алга таба бирү өчен җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен тапшыру турында карарлар кабул ителде:

2014 елның 30 сентябрендәге 8 номерлы – 190,0 гектар (Биектау муниципаль районы һәм Казан шәһәре янында) һәм 117,8 гектар (Константиновка поселогы);

2015 елның 31 мартындагы 3 номерлы – 331,5 гектар (Биектау муниципаль районы);

2019 елның 30 октябрендәге 4 номерлы – 963,6 гектар (Биектау муниципаль районы).

Гомуми мәйданы 639,3 гектар булган җир кишәрлекләреннән (521,5 гектар – Биектау муниципаль районында һәм Казан шәһәре янында, 117,8 гектар – Константиновка поселогында) Казан шәһәренең күпбалалы гаиләләренә бирү өчен 2 500дән артык кишәрлек формалаштыру планлаштырылды, шулардан индивидуаль торак төзелеше өчен 2 274 җир кишәрлеге фактта булдырылды, 1 428 кишәрлек буенча аларны күпбалалы гаиләләргә бирү турында карарлар кабул ителде. Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү эше чират буенча дәвам итә.

*Россия Федерациясе милкендә булган, идарә итү һәм эш итү вәкаләтләре Татарстан Республикасына тапшырылган җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертү*

2020 елда Казан шәһәрендә 183,6 гектар гомуми мәйданлы ике җир кишәрлеге һәм Биектау муниципаль районында 1 419,3 гектар гомуми мәйданлы өч җир кишәрлеге белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләре тапшырылды.

*Җир кишәрлекләрен аларны авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге категориядән төзелеш өчен яраклы категориягә күчерү юлы белән бирүдә, шул исәптән эшкуарлык*

*субъектларына бирүдә булышлык күрсәтү*

2020 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2 201,3 гектар гомуми мәйданлы 1 949 җир кишәрлеген күчерү турында 91 карары кабул ителде.

*Җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасының милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итү*

2020 елда Татарстан Республикасының милек хокукын дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылды һәм 253,1 гектар мәйданлы 92 җир кишәрлеге Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертелде.

Даими (чикләнмәгән вакытта) файдалануга һәм түләүсез файдалануга Татарстан Республикасы милкендәге 535,5 гектардан артык гомуми мәйданлы 146 җир кишәрлеге, муниципаль милеккә 40,0 гектар гомуми мәйданлы 22 җир кишәрлеге бирелде.

*Җир ресурсларын саклау*

Деградацияләнгән җирләр булуны исәпкә алып, Татарстан Республикасының җир ресурсларын саклау өстенлекле бурычларның берсе булып тора. Туфракны җимерелүдән һәм ярлыланудан саклауга юнәлдерелгән чараларга аерым игътибар бирелә. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең туфракларын, җир өсте су объектларын саклау, республика территориясенең экологик иминлеген тәэмин итү максатларында ел саен саклый торган урман утыртмаларын булдыру буенча эш алып барыла. 2020 елда саклый торган урман утыртмалары авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге эрозияле куркыныч җирләрдә 1 934 гектар мәйданда булдырылды.

Сәнәгать җитештерүен үстерү углеводород чималын чыгаруны һәм куллануны арттыра, бу җирлекнең туфрак катламын, гидрологик режимын бозуга, техноген рельеф барлыкка килүгә һәм җир торышының башка сыйфатын үзгәртүгә китерә. Бозылган җирләрнең продуктивлыгын торгызуга юнәлдерелгән иң мөһим чараларның берсе – ул деградацияләнгән җирләрне рекультивацияләү. Татарстан Республикасының җирле бюджетлары акчасы исәбеннән карьерларны түбәндәге күләмнәрдә рекультивацияләү чаралары финансланды:

2016 елда – 17 муниципаль берәмлектә 11,5 млн сумга;

2017 елда – 17 муниципаль берәмлектә 20,8 млн сумга;

2018 елда – 8 муниципаль берәмлектә 5,5 млн сумга;

2019 елда – 11 муниципаль берәмлектә 6,5 млн сумга;

2020 елда – 8 муниципаль берәмлектә 4,0 млн сумга.

*Су объектларын саклау*

Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында иң күп сулы төбәкләренең берсе, республиканың барлык территориясеннән якынча 6,4 проценты су белән капланган, 36 000нән артык су объекты бар. Якынча 4 000 кече һәм урта елга исәпләнә, аларны саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалануга аерым игътибар бирелә.

Су объектлары турындагы мәгълүматларны Дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү максатларында ел саен яр буе линияләренең урнашу урынын билгеләү эшләре үткәрелә. Хәзерге вакытта яр буе линияләренең гомуми озынлыгы 12 736,7 км булган 185 су объектының чикләре

билгеләнде. Су саклау зоналарын билгеләүне таләп итә торган яр буе линиясенең гомуми озынлыгы 42 914 км тәшкил итә.

2020 елда федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына Казан шәһәрендә, Югары Ослан, Зеленодольск, Буа, Тәтеш, Кайбыч муниципаль районнарында урнашкан 48 су объектының яр буе линияләре урнашу урынын (су объекты чикләрен), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклау полосалары чикләрен билгеләү эшләре башкарылды.

Федераль су ресурслары агентлыгында 2021 елга, 2022 һәм 2023 елларның план чорына Татарстан Республикасының су хуҗалыгы һәм су саклау чараларын федераль бюджет акчасыннан финанслауга, шул исәптән 2021 елда Татарстан Республикасының 15 муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан 48 су объектының яр буе линияләре урнашу урынын (су объекты чикләрен), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклау полосалары чикләрен билгеләү чараларын үткәрүгә бюджет проектлары якланды.

*Табигать тыюлыклары фондын үстерү*

Республиканың табигать тыюлыклары фонды 464 689 гектар мәйданлы барлык категорияләрдәге 190 махсус саклана торган табигать территориясеннән гыйбарәт, бу республиканың гомуми мәйданыннан 6,8 процент тәшкил итә.

2020 елда 4 яңа махсус саклана торган табигать территорясе оештырылды:

Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә 22 290 гектар мәйданлы «Чулман-Ык» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы –табигать комплексларын саклап калу, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су янындагы төрләрен саклау максаты белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 август, 751 нче карары);

Актаныш муниципаль районы территориясендә 14 956 гектар мәйданлы «Агыйдел елгасы дельтасы» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы – табигать комплексларын саклап калу, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су янындагы төрләрен саклау максаты белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 август, 761 нче карары);

Лениногорск муниципаль районы территориясендә 12,6 гектар мәйданлы «Покш Пандо» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле – уникаль табигать ландшафтларын, биологик төрлелекне, аларда яши һәм үсә торган үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының сирәк объектларын саклап калу максаты белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 сентябрь, 881 нче карары);

Азнакай муниципаль районы территориясендә 9,7 гектар мәйданлы «Мәвәнез үзәне» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле – уникаль табигать ландшафтларын, биологик төрлелекне, аларда яши һәм үсә торган үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының сирәк объектларын саклап калу максаты белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 сентябрь, 881 нче карары);

Уникаль табигать ландшафтларын һәм кыйммәтле төрләрне саклау максатларында махсус саклана торган табигать территорияләре мәйданын арттыру буенча түбәндәге эш дәвам итә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Мамадыш муниципаль районы территориясендә махсус саклана торган табигать территориясен (Сокольский утравы) булдыру турындагы карары проекты әзерләнде;

фәнни-тикшеренү эшләре нәтиҗәләре нигезендә 3 махсус саклана торган табигать территориясен оештыру эше алып барыла;

Казан шәһәре территориясендә «Рус-немец Швейцариясе» (Скот таулары) табигый урынының төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәленең саклау зонасын булдыру эше алып барыла.

**Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметү**

*«Экология» илкүләм проекты*

2020 елда Татарстан Республикасына «Экология» илкүләм проектының 4 федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру өчен 2 810,0 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан 2 166,3 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән:

Татарстан Республикасында чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын гамәлгә ашыру өчен «Иделне сәламәтләндерү» федераль проекты буенча – 1 543,9 млн сум, шулардан федераль бюджеттан – 1 250,5 млн сум. Республиканың 7 муниципаль районы территориясендә 12 объектта (11 чистарту корылмасында һәм 1 яңгыр сулары канализациясендә) эш алып барылды;

әйләнә-тирә мохиткә тупланган экологик зыян объектларын бетерү буенча 3 чараны гамәлгә ашыру өчен «Чиста ил» федераль проекты буенча – 834,1 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан – 483,8 млн сум;

«Урманнарны саклау» федераль проекты буенча урманнарны торгызу мәйданын арттыру чараларына, урман орлыклары запасларын булдыруга һәм махсуслаштырылган техника һәм җайланма белән җиһазландыруга федераль бюджеттан 197,7 млн сум күләмендә субвенция бирелде;

«Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасы» федераль проекты буенча каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча халыкка коммуналь хезмәтләр күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан 234,3 млн сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар бүлеп бирелде.

2020 елда «Уникаль су объектларын саклау» федераль проекты кысаларында волонтерлар тарафыннан су объектлары ярларын чистарту чаралары гамәлгә ашырылды (финанслау каралмады).

2020 елга каралган федераль проектлар чаралары тулысынча тәгәлләнде, максатчан күрсәткечләр мәгънәләренә ирешелде.

«Биологик төрлелекне саклау һәм экологик туризмны үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру чаралары планында Татарстан Республикасында кар барсын үрчетү үзәген (алга таба – Үзәк) төзү каралды. Бу максатларда Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, Кама Тамагы муниципаль районында Үзәкне урнаштыру өчен сайлап алынган җир кишәрлекләрен хокукый рәсмиләштерү һәм реализацияләү буенча эш алып барыла.

*Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү буенча территориаль системасын үстерү*

Хәзерге вакытта республика территориясендә әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасы кысаларында атмосфера һавасы пычрануны контрольдә тотуның 16 автомат станциясеннән торган атмосфера һавасы пычрануны күзәтү челтәре булдырылды: Казан шәһәрендә – 4, Яр Чаллы шәһәрендә – 2, Түбән Кама шәһәрендә – 4, Алабуга шәһәрендә – 1, Азнакай шәһәрендә – 1, Менделеевск шәһәрендә – 1, Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогында һәм Кәләй авылында – 2, Түбән Кама муниципаль районының Олы Афанасово авылында – 1.

Әйләнә-тирә мохит пычрану югары дәрәҗәдә булу фактларына карата кичектергесез чара күрү, атмосфера һавасы пычрануның мөмкин булган чыганагын билгеләү өчен приборлар комплексы (атмосфера һавасы пычрануны контрольдә тотуның автомат станцияләрендә приборлар комплексына охшаш булган) белән җиһазландырылган 6 күчмә экологик лаборатория кулланыла: Казан шәһәрендә – 2, Яр Чаллы шәһәрендә – 1, Түбән Кама шәһәрендә – 1, Әлмәт шәһәрендә – 1, Азнакай шәһәрендә – 1.

Су ресурслары федераль агентлыгының территориаль органы (Түбән Идел бассейн су идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге) белән килештерелгән Татарстан Республикасы җир өсте су объектларына дәүләт мониторингының территориаль күзәтү челтәре пунктларында күзәтүләр программасы нигезендә су объектлары мониторингын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу вәкаләтләрен башкару максатларында махсуслаштырылган аналитик контроль инспекцияләре тарафыннан ай саен республиканың 37 су объектының, шул исәптән 27 елга, 7 буа, 1 карьер, 2 күлнең (барлыгы 71 күзәтү пункты) гидрохимик торышына (пычрану дәрәҗәсенә) күзәтүләр алып барыла.

Барлыгы территориаль күзәтү системасы белән Татарстан Республикасының 39 муниципаль районы колачланды.

*Атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплары системасын үстерү*

Атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларын файдалану билгеле бер территориядә була торган чыгаруларның (сәнәгать предприятиеләре чыгарулары да, автотранспорт агымнарыннан чыгарулар да) барлык стационар чыганакларының атмосфера һавасына тулаем йогынтысын объектив бәяләргә мөмкинлек бирә торган бердәнбер алым булып тора.

Республикада булдырылган атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплары системасы түбәндәгеләр өлешендә атмосфера һавасының сыйфаты белән идарә итүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирде:

атмасфера һавасының сыйфатын начарайтуга китерә торган атмосфераны пычратуның потенциаль чыганакларын билгеләү (идентификацияләү) һәм һаваны саклау законнарын бозучыларга карата кисәтү чараларын гамәлгә ашыру;

тискәре метеорологик шартлар барлыкка килгәндә атмосфера һавасына чыгаруларны киметүне тәэмин итәргә тиешле предприятиеләрнең нигезләнгән исемлеген әзерләү, шулай ук тискәре метеорологик шартлар чорларында чыгаруларны киметүне тикшерүдә тоту режимнарын эшләү. Үткәрелгән исәп-

хисаплар нигезендә тискәре метеорологик шартлар булганда чыгаруларны киметүне тәэмин итәргә тиешле предприятиеләр исемлеге киңәйтелде, шулай ук тискәре метеорологик шартлар булганда беренчел чиратта контрольдә булырга тиешле шәһәр территорияләре һәм пычраткыч матдәләр исемлеге билгеләнде;

Түбән Кама шәһәрендә һәм Түбән Кама муниципаль районында атмосфера һавасына тискәре йогынты ясый торган гамәлдәге җитештерүләрне киңәйтү яки яңа җитештерүләр булдыру мөмкинлеген анализлау;

Россия Федерациясенең һава саклау законнары таләпләрен үтәүне тәэмин итү өчен атмосфераның исәпләп чыгарыла торган фон пычрануын билгеләү.

2020 елда «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган) «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында Казан һәм Түбән Кама шәһәрләре өчен чыгаруларның стационар һәм күчмә чыганаклары буенча мәгълүматларның җыелма базасын актуальләштерү эшләре башкарылды. Шулай ук 2020 елда Алабуга шәһәре («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясен кертеп) өчен атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплары системасы булдырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама шәһәрендә һәм Түбән Кама муниципаль районында атмосфера һавасына антропоген йөкләнешне киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2016 ел, 9 ноябрь, 828 нче карарын гамәлгә ашыру кысаларында 2020 елда Түбән Кама шәһәренең һәм Түбән Кама муниципаль районының түбәндәге проектлаштырыла торган объектлары буенча гамәлдәге җитештерүләрне киңәйтү һәм яңа производстволар булдыру мөмкинлеге бәяләнде: «ТАНЕКО» акционер җәмгыятенең Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү комплексы объектлары, «АльфаНефтеХим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ВостокВолгоСталь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Акватар» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Түбән Кама» катнаш авыл хуҗалыгы куллануучылар кооперативы, «Транснефть-Прикамье» акционер җәмгыяте филиалы – Әлмәт район нефтьүткәргеч идарәсенең «Түбән Кама – 2» баш суыртып агызу станциясе филиалы.

*Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохите компонентларының төбәк үзенчәлекләрен исәпкә ала торган әйләнә-тирә мохит сыйфатының төбәк нормативларын эшләү һәм аларны Татарстан Республикасында файдалануга кертү*

Россия Федерациясе субъектларына әйләнә-тирә мохит сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү вәкаләтләрен бирү, «Вәкаләтләр бүленешен камилләштерү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2005 елның 31 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон кабул итү белән бәйле рәвештә, 2006 елдан республикада әйләнә-тирә мохит сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү функциясе гамәлгә ашырыла.

2020 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2020 елның 3 февралендәге 110-п номерлы боерыгы белән «Татарстан Республикасының җир өсте су объектлары төбендәге утырмаларда нефть

продуктларының фон күләмендә булуы» төбәк нормативлары расланды.

Шулай ук 2020 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2020 елның 28 гыйнварындагы 89-п номерлы боерыгы белән «Сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен Татарстан Республикасы территориясендә рекультивация һәм башка торгызу эшләрен үткәргәннән соң типик кара туфракларда, селтесезләнгән кара туфракларда, көлсуланган кара туфракларда, аксыл көрән урман, көрән урман, кара көрән урман, кәзле көлсу, кәзле-карбонатлы селтесезләнгән, кәзле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда нефтьнең һәм аның трансформация продуктларының рөхсәт ителгән калдыклары булу» төбәк нормативлары расланды.

Рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң туфракта нефтьнең һәм аның трансформация продуктларының рөхсәт ителгән калдыклары булу нормативлары нефть пычракларын бетерү технологияләрен, материалларын, җайланмаларын һәм башка чараларын, нефть белән пычрануга дучар булган җирләрне рекультивацияләү проектларын эшләгәндә һәм аларга экспертиза үткәргәндә, шулай ук рекультивация үткәргәннән соң җир кишәрлекләрен кабул иткәндә кулланыла. Нефтьнең һәм аның трансформация продуктларының рөхсәт ителгән калдыклары булуның расланган нормативлары булу җирләрне рекультивацияләү эшләре дәвамлылыгын киметергә һәм максатчан файдалану өчен аларны үз вакытында кире кайтарырга, шулай ук рекультивацияләнә торган туфракларда нефть продуктлары концентрациясен нуль дәрәҗәгә җиткерергә тырышканда, туфракларга өстәмә зыян китермичә, эшләрне үз вакытында туктатуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

# ФИНАНС КАПИТАЛЫ ҺӘМ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР

## Финанс ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге

2020 елда Татарстан Республикасы бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр 206,9 млрд сум яки план күрсәткечләреннән 101,4 процент мобилизацияләнде, бу 2019 ел күрсәткечләреннән 42,6 млрд сумга кимрәк. Федераль бюджеттан һәм башка чыганаклардан республикага 86,5 млрд сум акча җәлеп ителде.

**2020 елда Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре структурасы**




Бюджет керемнәрен арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-б номерлы боерыгы нигезендә республикада Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәре артуны тәэмин итү буенча ведомствоара комиссия даими нигездә эшли. Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре арту чаралары түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырылды:

табышка салым – ай саен табышка салым керү мониторингы үткәрелде, аның нәтиҗәсендә узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләрне киметкән оешмалар ачыкланды. Мондый оешмаларның исемлеге квартал саен җавап бирә торган тармак министрлыкларына җиткерелде. Татарстан Республикасының тармак министрлыклары (коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чараларының гамәлдә булуын исәпкә алып) ведомство буйсынуындагы учреждениеләр буенча аналитик эш алып барды, баланс комиссияләрен (шул исәптән читтән торып режимында) үткәрү практикасын дәвам итте, аларда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салымнар керүләрнең киму сәбәпләре анализланды, шулай ук барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга түләүләр буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары булган оешмаларның эшчәнлеге карап тикшерелде. Бергәләп башкарылган эш нәтиҗәләре буенча тармак министрлыклары тарафыннан ведомство буйсынуындагы оешмалар җитештерүенең һәм аларның табышлы дәрәҗәгә чыгуының рентабельлегенә ирешү буенча, шулай ук бюджетка

түләүләр буенча үз вакытында түләнмәгән бурычларны киметү турында тәкъдимнәр эшләнде;

физик затлар керемнәренә салым – «күләгәдәге» эш хакын легальләштерү, «конвертлы» түләүләрне һәм физик затлар керемнәренә салым түләүдән китүнең башка схемаларын ачыклау буенча чаралар үткәрелде, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр хезмәткәрләренә эш хакын федераль законнар белән билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән түбән булмаган күләмнәрдә түләүне тикшерүдә тоту гамәлгә ашырылды, алдагы елның шул ук чорына карата физик затлар керемнәренә салым керүне киметкән салым түләүчеләр мониторингы үткәрелде;

акцизлар – акциз продукциясен төп җитештерүчеләр белән продукция җитештерү һәм реализацияләү күләмнәрен мониторинглау һәм пландагы билгеләнешләргә ирешү буенча даими рәвештә эш алып барылды;

физик затлар мөлкәтенә салым – мөлкәт салымнары керүләрнең тулылыгын тәэмин итү чаралары үткәрелде. Алар кысаларында республиканың эре предприятиеләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль структуралары, муниципалитетлар белән законнар белән билгеләнгән срокларда салымнарны түләү, салым түләүчеләргә – физик затларга салым турындагы хәбәрнамәләрне үз вакытында илтеп җиткерү, физик затлардан түләүләрне өзлексез кабул итүне тәэмин итү буенча кредит оешмалары һәм почта бүлекчәләре белән эш үткәрү, эш режимын эш һәм ял көннәрендә озайту буенча хезмәттәшлек гамәлгә ашырылды, шулай ук киң мәгълүмати кампания, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында җәелдерелде;

салым булмаган керемнәр – Татарстан Республикасы бюджетына, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына агымдагы керүләргә анализ үткәрелде һәм фаразлана торган керүләр бәяләнде, керем базасын арттыру һәм түләүләр буенча бурычларны киметү максатларында салым булмаган керемнәр администраторлары белән уртак эш башкарылды.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны кыскарту эше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге 1493-б номерлы боерыгы белән төзелгән ведомствоара комиссия (штаб) эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырылды. Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында видеоконференция режимында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы киңәшмәләрендә даими рәвештә; Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы икътисадый эшчәнлек төрләре буенча оешмалар белән эш алып барылды.

Моннан тыш, бюджет керемнәре керүләрен арттыру максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан республиканың эре салым түләүчеләре белән, шул исәптән эре предприятиеләрнең һәм кече нефть компанияләренең бюджетка агымдагы түләүләрен анализлау һәм фаразлана торган түләүләрен бәяләү нигезендә эш алып барылды.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына

түләүләрне үз вакытында гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эш алып барылды.

Оешмалар табышына салым һәм мөлкәтенә салым буенча салым ташламалары бирү өлешендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә дәгъва итүче инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына, социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары составына керүгә дәгъва итүче оешмаларның инвестиция проектларына, җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирүгә дәгъва итүче оешмаларның инвестиция проектларына, Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзүгә дәгъва итүче оешмаларның инвестиция проектларына экспертиза ясау гамәлгә ашырылды.

Бер үк вакытта инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында тиешле шартнамәләр гамәлдә булган чор дәвамында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар һәм җыемнар түләүне ел саен тәэмин итү буенча йөкләмәләрнең үтәлешен ел саен бәяләү гамәлгә ашырылды.

Татарстан Республикасы икътисады һәм берләштерелгән бюджеты өчен тәкъдим ителә торган үзгәрешләр кертүнең мөмкин булган нәтиҗәләренә кичектергесез чара күрү максаты белән федераль закон проектлары (шул исәптән законнарга үзгәрешләр кертүгә кагылышлы) буенча системалы эш алып барылды. Шулай итеп, 2020 елда салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга үзгәрешләр кертү буенча законнар чыгару инициативаларына 50дән артык бәяләмә әзерләнде.

Даими нигездә Татарстан Республикасының салым законнарын камилләштерү буенча закон чыгару эше алып барылды. Әйтик, 2020 елда салымнар һәм җыемнар буенча, шул исәптән салым салуның гадиләштерелгән системасы, табышка салым, мөлкәткә салым һәм салым салуның патент системасы буенча 6 закон проекты әзерләнде.

2020 елга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 317,0 млрд сум тәшкил итте, шулардан мәгарифкә – 72,6 млрд сум, социаль сәясәткә – 48,8 млрд сум, сәламәтлек саклауга – 36,9 млрд сум, юл хуҗалыгына – 37,1 млрд сум, авыл хуҗалыгына – 16,4 млрд сум, мәдәнияткә – 11,4 млрд сум.

2020 елда эчке дәүләт финанс контроле буенча вәкаләтләрне үтәү кысаларында 324 контроль чара уздырылды. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә 354,3 млн сум күләмендә бюджет акчасыннан нәтиҗәле файдаланмау билгеләнде. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү өчен учреждение җитәкчеләренә күрсәтмәләр җибәрелде, нәтиҗәдә 89 процент җитешсезлекләр бетерелде. Прокурорлык чараларын күрү өчен тикшерү актлары Татарстан Республикасы прокуратурасына җибәрелде.

2020 елда Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012–2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы указларын гамәлгә ашыру эше дәвам итте.

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2019 елның 20 февралендәге Юлламасын тормышка ашыру буенча Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин тарафыннан расланган 2019 елның 27 февралендәге Пр-294 номерлы йөкләмәләр исемлеге (алга таба – Россия Федерациясе

Президентының 2019 елның 27 февралендәге Пр-294 номерлы йөкләмәләр исемлеге) нигезендә 2020 елга һәм алдагы елларга бюджет өлкәсенең аерым категорияләрдәге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү дәрәҗәсе һәм төбәктәге уртача эш хакы дәрәҗәсе арасында ирешелгән нисбәтне саклап калу бурычы куелды.

2020 елда имин булмаган санитария-эпидемия торышы аркасында икътисадый хәлнең начараюы шартларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш хакын саклауны билгели торган 2020 ел, 8 май, б-916 нчы боерыгы кабул ителде:

медицина оешмаларының аерым категорияләрдәге хезмәткәрләре – 2020 елның 1 кварталы йомгаклары буенча ирешелгән дәрәҗәдә;

бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү шартлары май указлары белән җайга салына торган башка категорияләрдәге хезмәткәрләре – 2019 ел йомгаклары буенча ирешелгән дәрәҗәдә.

2020 ел йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 27 февралендәге Пр-294 номерлы йөкләмәләре исемлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 8 май, б-916 нчы боерыгы нигезендә аерым категорияләрдәге хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү күрсәткечләре тулы күләмдә үтәлде. 2020 елда эш хакын түләү өчен акчага ихтыяҗ 142,2 млрд сум тәшкил итте һәм тулысынча финанслау чыганаклары белән тәэмин ителде, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 4,9 млрд сум, республика бюджеты акчасы исәбеннән – 128,6 млрд сум, бюджеттан тыш акча исәбеннән – 8,7 млрд сум.

2020 елның июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында 2019 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап , шулай ук «2019 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 2020 елның 18 июнендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы каралды һәм расланды. Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан әлеге хисапка тышкы тикшерү һәм экспертиза үткәрелде.

2020 елда 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетын һәм Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру эше 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзегәндә эшләнә торган законнар, документлар проектларын һәм материалларны әзерләү һәм карау графигы нигезендә алып барылды.

«2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы (78-ТРЗ номерлы) 2020 елның 26 ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителде һәм 2020 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан имзаланды. Әлеге законда чыгымнар 31 дәүләт программасы буенча каралды.

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы бюджеты башкарма хакимият органнарын тоту чыгымнары өлешендә элемтә хезмәтләре, транспорт чараларын агымдагы карап тоту чыгымнарының, башка агымдагы чыгымнарның (шул исәптән командировка чыгымнары) билгеләнгән нормативларын исәпкә алып формалаштырылды.

2021 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының социаль-

мәдәни өлкә тармаклары буенча чыгымнар өлешен формалаштырганда норматив финанслау механизмы кулланылды.

2021 елга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетын социаль-мәдәни өлкә тармаклары буенча формалаштыру өчен Татарстан Республикасының тиешле законнары һәм 2021 елга учреждениеләрне финанслау нормативларын раслый торган норматив хокукый актлар кабул ителде.

2020 елда Татарстан Республикасының дәүләт финансларын савыктыру чаралары планы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карары), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, б-644 нче боерыгы белән расланган 2020 – 2022 еллар чорына Татарстан Республикасы керемнәрен арттыру, чыгымнарын оптимальләштерү һәм дәүләт сәясәтен камилләштерү чаралары планы белән күздә тотылган чараларны гамәлгә ашыру дәвам итте.

2020 ел дәвамында Татарстан Республикасы дәүләт бурычын исәпкә алу, рәсмиләштерү, үз вакытында каплау һәм аңа хезмәт күрсәтү мәсьәләләре белән бәйле чараларның тулы комплексы кабул ителгән йөкләмәләр үтәлешенең гамәлдәге графиклары нигезендә үткәрелде. Бу эш кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт бурыч китабын алып бару, Россия Федерациясе Финанс министрлыгына тапшыру өчен хисап мәгълүматын әзерләү гамәлгә ашырылды.

2020 ел дәвамында Татарстан Республикасының дәүләт бурычын кыскарту чаралары планын үтәү тәэмин ителде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 гыйнвар, б-10 нчы боерыгы). Әлеге юнәлеш кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау максатларында коммерциячел үзләштерүләрне гамәлгә ашыруга мораторий сакланды.

2020 елда федераль бюджеттан ике бюджет кредиты җәлеп ителде: Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында акчаның калган өлешен Федераль казначылык органнары аша тулыландыруга (2,06 млрд сум күләмендә транш җәлеп ителде һәм капланды), шулай ук Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында акчаның калган өлешен тулыландыруга 2,06 млрд сум күләмендә бюджет кредитын каплау өчен.

2020 елда Татарстан Республикасы тарафыннан федераль дәрәҗәдә бирелгән Россия Федерациясе бюджеты алдында бюджет кредитлары буенча бурычларны кире кайтару срокларын озайту (күчерү) мөмкинлеге гамәлгә ашырылды: 2012 елда реструктурлаштырылган кредитлар буенча, бурычларны түли башлау вакытын 2023 елдан 2025 елга күчереп һәм 2034 елга кадәр тигез өлешләр белән алга таба каплап, (моноюнәлешле муниципаль берәмлекләргә ярдәм итүгә бирелгән кредитларны исәпкә алмыйча) 2017 елның декабрендә реструктурлаштырылган кредитлар буенча, бурычларны кире кайтару чорын 2029 елга кадәр озайтып һәм 2021 – 2024 елларда ел саен бурычларның 5 проценты буенча, 2025 – 2029 елларда ел саен бурычларның 14 проценты буенча түләп.

2020 елда дәүләт бурычы өлешендә йөкләмәләрне үтәү эше кысаларында федераль бюджет кредитларыннан файдаланган өчен процентларны үз вакытында һәм тулы күләмдә түләү һәм төп бурычны расланган түләүләр графиклары нигезендә 2,06 млрд сум күләмендә каплау гамәлгә ашырылды. Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлар юк.

2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт бурычының гомуми күләме (дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне исәпкә алып) 98,2 млрд сум тәшкил итте, Татарстан Республикасы бюджетының бурыч йөкләмәсе дәрәҗәсе (салым һәм салым булмаган керемнәрнең еллык күләменә дәүләт бурычы күләменең нисбәте) 47,5 процент тәшкил итте.

2020 елда икътисадый кризис шартларында республика бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләмнәре сизелерлек кимүгә карамастан, заем чыганакларына карамаган чыганаклар исәбенә бюджет кытлыгын максималь мөмкин каплауга юнәлдерелгән консерватив алымны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджетын үтәү буенча башкарылган эш әлеге бурыч йөкләнеше күрсәткечен 50 процент дәрәҗәсеннән арттырмау мөмкинлеген бирде, бу бурыч тотрыклылыгының югары булу критерийларыннан берсе булып тора.

2020 елда Татарстан Республикасының кредит рейтингы мәсьәләләре буенча халыкара һәм үз илебез рейтинг агентлыклары белән хезмәттәшлек итү эше дәвам итте. Fitch Ratigs Ltd халыкара рейтинг агентлыгы линиясе буенча республиканың кредит рейтингы инвестиция категориясенә каравын һәм Россия Федерациясе рейтингы дәрәҗәсендә булуын дәвам итә.

Moody's Investors Service Ltd халыкара рейтинг агентлыгы линиясе буенча республика рейтингы Россия Федерациясе суверен рейтингыннан бер баскычка түбәнрәк тора. «Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгы» (АКРА) һәм «Эксперт РА» Россия рейтинг агентлыклары Татарстан Республикасының кредит рейтингын Россия Федерациясендәге максималь дәрәҗәдә бәяли.

*Сәнәгатьне үстерү төбәк фонды*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 апрель, 248 нче карары белән «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына төбәк Сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләре бирелде.

2020 елда федераль Сәнәгатьне үстерү фонды «Үсеш проектлары», «Комплектлау эшләнмәләре» һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» дигән өч программа буенча төбәк сәнәгатьне үстерү фондлары белән бергә финанслау өчен инвестиция проектларын карады.

Сәнәгатьне үстерү фонды программалары, төбәк фондлары белән берлектә, «Эшкәртүче җитештерүләр» секторында сәнәгатьнең өстенлекле юнәлешләре буенча гамәлгә ашырыла торган һәм республика предприятиеләрендә иң яхшы файдалану технологияләре (шул исәптән база тармак технологияләре) принципларына туры килә торган перспектив технологияләрне эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә, импортны алмаштыра торган яки экспорт потенциалы булган гражданлык билгеләнешендәге яңа конкурентлыкка сәләтле һәм югары технологияле продукция җитештерүгә юнәлдерелгән проектларны финанслашуны күздә тота.

Ике фондтан заемның гомуми суммасы 5 ел срок белән бер елга 1 – 5 процент ставкасы буенча 20 млн сумнан 100 млн сумга кадәр тәшкил итә.

2020 елда барлыгы Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды Татарстан Республикасының 785 потенциаль гариза бирүчесенә – сәнәгать эшчәнлеге субъектларына Сәнәгатьне үстерү фонды программалары турында мәгълүмат бирде.

Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фондына 21 заявка керде.

2020 елда Сәнәгатьне үстерү фондының эксперт советы тарафыннан финанслау өчен гомуми суммасы 258,3 млн сумга 3 проект хупланды (шул исәптән Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды тарафыннан 30 процент – 46,5 млн сум күләмендә финанслау):

«Тормоз механизмнары заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Яр Чаллы шәһәре) – заем суммасы 25,1 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды өлеше 30 процент – 7,5 млн сум күләмендә;

«Макситон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Казан шәһәре) – заем суммасы 30 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды өлеше 30 процент – 9 млн сум күләмендә;

«РТИ-Компонент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Яр Чаллы шәһәре) – заем суммасы 100 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды өлеше 30 процент – 30 млн сум күләмендә.

2020 елда әлеге проектлар финансланмады, заем шартнамәләре имза кую стадиясендә.

**Инвестиция сәясәте**

Республика Хөкүмәте төбәкнең инвестицион потенциалын алга җибәрүгә һәм аның инвестицион климатын яхшыртуга, шулай ук инвесторлар өчен бизнес алып баруга уңайлы шартлар тудыруга зур игътибар бирә.

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә 2030 елга төп капиталга инвестицияләрнең реаль үсешенә ирешү 2020 ел белән чагыштырганда 70 проценттан ким булмаган күләмдә билгеләнде.

2020 елда Татарстан Республикасында төп капиталга инвестицияләр күләме 605,8 млрд сум тәшкил итте, ягъни 2019 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 91,1 процент.

Төп капиталга инвестицияләр күләме буенча Татарстан Идел буе федераль округы төбәкләре арасында 1 урында тора.

Төп капиталга инвестицияләрнең шактый күләме эшкәртү җитештерүләрен үстерүгә юнәлдерелгән – 36,9 процент, шул исәптән инвестицияләрнең 15,3 проценты – кокс һәм нефть продуктлары җитештерүгә, 10,1 проценты – химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерүгә, 3,8 проценты автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерүгә туры килә. Файдалы казылмалар чыгаруга төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменнән – 10,3 процент, транспортировкалауга һәм саклауга – 11,1 процент, күчемсез мөлкәт белән операцияләр эшчәнлегенә 5,8 процент җибәрелде.

2020 елда кече эшмәкәрлек субъектларыннан башка предприятиеләр һәм оешмаларның үз акчасы өлеше һәм турыдан-туры статистик ысуллар белән күзәтелми торган инвестицияләр күләме төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләмендә 58,5 процент, җәлеп ителгән акча 41,5 процент тәшкил итте. Бюджет акчасына җәлеп

ителгән акчадан төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменнән 16,6 процент, банклар кредитлары – 9,6 процент, өлешле төзелешкә оешмалар һәм халык акчасы 1,1 процент туры килә.

**Төп капиталга инвестицияләр структурасы (кече эшкуарлык субъектларыннан һәм турыдан-туры статистика методлары нигезендә кертелгән инвестицияләр күләменнән тыш), %**




2020 елда чит илләрдән кергән инвестицияләр күләме 592,7 млн доллар тәшкил итте, шулардан иң зур өлеше – башка инвестицияләр 440,3 млн доллар (кергән инвестицияләрнең гомуми күләменә карата 74,3 процент), турыдан-туры инвестицияләр 152,4 млн доллар (25,7 процент) тәшкил итте, портфель инвестицияләр кермәде.

Чит ил инвестицияләре керү республиканың биш шәһәрендә һәм өч муниципаль районда күзәтелде – Түбән Кама шәһәре – 433,2 млн доллар, Алабуга шәһәре – 88,0 млн доллар, Югары Ослан районы – 42,3 млн доллар, Казан шәһәре – 26,2 млн доллар, Яр Чаллы шәһәре – 1,7 млн доллар, Әлмәт шәһәре – 1,3 млн доллар, Лаеш районы – 0,2 мең доллар, Мамадыш районы – 0,1 мең доллар. Чит ил инвестицияләренең аеруча мөһим күләмнәре Түбән Кама (республикага кергән чит ил инвестицияләреннән 73,1 процент) һәм Алабуга шәһәрләрендә (14,9 процент) тупланды.

2020 елда инвестицияләр 22 илдән керде. Иң актив инвесторлар: Германия – 447,8 млн доллар (чит илләрдән кергән инвестицияләрнең гомуми күләмендә аларның өлеше (75,6 процент) тәшкил итте, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – 42,3 млн доллар (7,1 процент) һәм Словакия – 40,8 млн доллар (6,9 процент).

525,2 млн доллар тәшкил иткән инвестицияләрнең өстенлекле өлеше эшкәртүче җитештерүләрне үстерүгә (чит илләрдән кергән инвестицияләрнең гомуми күләменнән 88,6 процент), һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлекне үстерүгә 41,7 млн доллар (7,0 процент) җибәрелде.

Ел саен «Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы төбәкләрне Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы ярдәмендә бизнес алып бару шартлары буенча бәяли. Елдан-ел Татарстан Республикасы лидерлар өчлегендә үз позицияләрен нык тота. 2020 елда Татарстан Республикасы икенче урын алды.

Бизнеска ярдәм итүнең оештыру механизмнары эше аерым игътибарга лаек. Аерым алганда, төбәктә инвесторлар белән үзара хезмәттәшлекне бәяли торган күрсәткечләр Россиядә иң яхшысы булып тора һәм башка субъектлар өчен үрнәк булып санала.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлаштыру кысаларында:

Күпфункцияле үзәкләрнең Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән электрон хезмәттәшлеге гамәлгә ашырылды;

nalog.ru рәсми сайтында процедуралар турында методологик тулы мәгълүмат алу мөмкинлеге тәэмин ителде, бу, мәсәлән, юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу кебек хезмәтләр күрсәтү срокларын сизелерлек кыскарта.

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятен электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник тоташтыру буенча хезмәт күрсәтүне максималь оптимальләштерү һәм аның үтә күренмәлеген арттыру максатларында:

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучылар өчен мобиль кушымта эшләнде;

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең шәхси кабинетында онлайн консультацияләр өчен «Виртуаль әңгәмәдәш» (чат-бот), шулай ук «online» хезмәтләре өчен түләү сервисын булдыру эше башланды;

Энергия кабул итү җайланмаларын электрон рәвештә «0-визитлар» функциясе аша технологик тоташтыру хезмәтләрен камилләштерү буенча эш алып барылды.

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен дәүләт кадастр исәбенә алуны һәм (яки) милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру бурычын үти торган бүлек төзелде, бу исә эшкуарлар өчен бөтен процессны шактый оптимальләштерә.

Эш башлаучы һәм эшләүче бизнесменнарның документларны теркәүгә кадәр әзерләү мәсьәләләрендә хокукый белемен арттыру өчен Идарә каршында түләүсез юридик консультацияләр тәрәзәсе ачылды.

Дәүләт сатып алуларында катнашу өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары өчен, шул исәптән аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен 30 процент норматив кабул ителде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 февраль, 125 нче карары).

Инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 декабрь, 1178 нче карары белән 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумы расланды, ул республикада инвестиция эшчәнлеген үстерүнең төп өстенлекләрен билгели.

2020 – 2022 елларга дәүләт инвестиция сәясәте өстенлекләре булып инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне үстерү, халыкара икътисадый кооперация пространствосын актив файдалану, электрон сәүдәне үстерү; эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү инфраструктурасын, шул исәптән махсус икътисадый зоналарны, социаль-

икътисадый үсеше алга киткән территорияләрне, инновацион фәнни-технологик үзәкләрне, технопаркларны, индустриаль паркларны, сәнәгать мәйданчыкларын үстерү; цифрлы икътисадны формалаштыру һәм үстерү юнәлешләре билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 февраль, 112 нче карары белән 2020 елга Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге расланды. Аңа якынча 200 өстенлекле инвестиция проекты кертелде, шул исәптән түбәндәге инвестиция проектлары: «Кабатланучан ысул белән 1 елга 60 мең тонна куәтле дивинил-стирол синтетик каучук җитештерү төзү» («Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыяте), «ЭП-600 яңа олефин комплексын һәм иярченнәрен төзү» («Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыяте), «ЭЛОУ-АВТ-6 урнаштыру» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте), «Кокслауның авыр газойлен су белән чистарту җайланмасын урнаштыру» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте), «Каталитик крекинг урнаштыру» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте), «КАМАЗ автомобиленең модель рәтен үстерү һәм аны җитештерү өчен җитештерү куәтләрен модернизацияләү» («КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте), «Зәй дәүләт район электр станциясендә 850 МВт куәтле пар-газ җайланмасы төзү» («Татэнерго» акционер җәмгыяте), «Казан сөт комбинатында җитештерүне модернизацияләү, киңәйтү» («Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте) һәм башкалар.

Комплекслы мәгълүмати ярдәм күрсәтү, дөньякүләм дәрәҗәсендә үз илебез һәм чит ил компанияләре өчен Татарстан Республикасының җәлеп итүчәнлеген арттыру, Татарстан Республикасында инвестицияләү шартлары турында, республиканың икътисадый күрсәткечләре турында, бизнесны үстерү өчен инфраструктура турында актуаль мәгълүмат бирү максатларында дөньяның 11 телендә файдаланып була торган Татарстан Республикасы Инвестицион порталы (www.invest.tatarstan.ru) эшли.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Инвестиция порталында «Бизнес-гид» бүлегендә «Инвесторлар өчен онлайн-сервис» бүлеге бар, анда дәүләт-хосусый партнерлык, кече һәм урта эшкуарлык объектлары өчен чекбокслар урнаштырылган Инвестиция картасы тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы «Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы инициативаларын төбәк дәрәҗәсендә гамәлгә ашыру кысаларында «Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы белән актив хезмәттәшлек итә.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы территориясендә милли социаль инициатива механизмнарын гамәлгә ашыру буенча проект офисы (алга таба – милли социаль инициатива) төзелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 декабрь, 1150 нче карары), ул социаль өлкәдә гражданнарга (сәламәтлек саклау, мәгариф һәм социаль ярдәм күрсәтүне кертеп) хезмәтләр күрсәткәндә каршылыкларны ачыклауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән.

Проект офисының максаты – төбәк дәрәҗәсендә дәүләт һәм муниципаль идарә системасындагы һәм бюджет өлкәсендәге процессларны кеше өчен, аның ихтыяҗлары тирәсендә һәм аның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен эшләсен итеп

үзгәртү. Моның өчен милли социаль инициатива кысаларында тормышта төрле хәлләрдә калган яки булган кешеләрнең ихтыяҗлары, шулай ук барлыкка килә торган киртәләр өйрәнеләчәк.

Хәзерге вакытта «Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы җитәкчелегендә эш төркемнәре очрашулары уза (сәламәтлек саклау һәм хезмәт базары мәсьәләләре буенча, онлайн-форматта), төбәкләр экспертлары иң яхшы тәҗрибәләрне кертү мөмкинлеге турында фикерләр алыша.

Проект офисының төп бурычлары – социаль өлкәдә кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерү, шул исәптән аның хезмәт күрсәтүләр һәм сервислардан канәгатьлелеген арттыру; сәламәтлек саклау, мәгариф һәм кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү өлкәләрендә тормыш хәлләрендәге проблемаларны хәл итүне тәэмин итү; социаль өлкәдә иң яхшы тәҗрибәләр белән алмашу.

Россия Федерациясе субъектларында милли социаль инициатива механизмнарын апробацияләү барышында гражданнарга түбәндәге тормыш ситуацияләрендә ярдәм итә торган иң яхшы тәҗрибәләрне тәкъдим итәчәкләр:

мәктәпкәчә яшьтәге баланың көндезге булуын оештыру;

баланың гомуми башлангыч белем алуын оештыру;

башлангыч сыйныф укучысының өстәмә белем алуын тәэмин итү;

амбулатор медицина ярдәме алу;

планлы стационар медицина ярдәме алу;

югары технологияле медицина ярдәме алу;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәге аша яңа эш эзләү;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен тернәкләндерүнең техник чараларын алу;

өйдә карауны тәэмин итү;

балага пособие алу.

Моннан тыш, иң яхшы идарә тәҗрибәләре һәм социаль-икътисадый инициативалар белән алмашу буенча «Смартека» цифрлы платформасы (smarteka.com) шулай ук социаль өлкәдә актуаль инициативалар белән актив тулыландыралачак. Татарстан уңышлы тәҗрибәне тиражлау өчен ачык, хәзерге вакытта платформада урнаштыру өчен килештерү процедурасы берничә практика уза.

«Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы тарафыннан куелган бурычларга ирешү буенча киләсе адым буларак, төбәкләрнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, юл картасын раслау, шулай ук аны алга таба урыннарда гамәлгә ашыру планлаштырыла.

2020 елның 11 – 13 ноябрендә Мәскәү шәһәрендә «Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы һәм «Росконгресс» фонды тарафыннан оештырылган «Яңа вакыт өчен көч идеяләре» федераль форумы уздырылды. Форумның заявка кампаниясе барышында Татарстан Республикасыннан 7 юнәлеш буенча 532 заявка бирелде.

Татарстан Республикасы проектларын алга этәрү максатларында Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алуның ведомствоара төбәк комиссиясе утырышы уздырылды, аның эш йомгаклары буенча төбәкнең иң яхшы идеяләре сайлап алынды.

Форум программасы кысаларында Татарстан Республикасыннан «Тикшерелгән бизнес» проекты 2020 елның 13 ноябрендә пленар утырышта Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинга тәкъдим ителде һәм хупланды.

*Инвестиция проектларын гамәлгә ашыру ысулларын һәм механизмнарын камилләштерү*

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында», «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» һәм «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләре нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвесторлар өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган табышка салым ставкасын 13,5 процентка кадәр киметү һәм проектны гамәлгә ашыру өчен оешма тарафыннан яңадан булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә салым ставкасын 0,1 процентка кадәр киметү каралды. Инвестиция эшчәнлеге субъектларына әлеге ташламалар проектларның үз-үзен аклау срогына бирелә, ләкин ул 7 елдан да артмаска тиеш, ә машина төзелеше тармагында салым ташламалары инвестицияләр башланган вакыттан алып 13 елга кадәр срокка бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе, шулай ук инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 ел, 7 май, 284 нче һәм 2006 ел, 24 июль, 377 нче карарлары белән регламентлаштырылды.

2020 елда инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турындагы гамәлдәге шартнамәләр кысаларында 24 инвестиция проекты гамәлгә ашырылды, шул исәптән «Йомшак төрү әйберләре һәм полимер пленка материаллары җитештерү заводы төзелеше» («Данафлекс-Нано» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте), «Газ-турбина җайланмалары базасында 3 нче Казан җылылык электр централен модернизацияләү» («ТГК-16» ачык акционер җәмгыяте), «Берьюлы саклана торган 150 000 тонна бөртекле һәм майлы культуралар саклау өчен элеватор төзү» («Зәй элеваторы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте) һәм башкалар.

Алдан бәяләүләр буенча, 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә гомуми суммасы якынча 15,8 млрд сум булган салым ташламалары биреләчәк (шул исәптән 2020 елда – 0,8 млрд сум). Әлеге инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 750 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде (шул исәптән 2020 елда – 7 млрд сум), Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләре 25 млрд сум чамасы тәшкил итәчәк (шул исәптән 2020 елда – 1,5 млрд сум). Ярдәм ителә торган инвестиция проектлары кысаларында 18 мең яңа эш урыны булдырылды.

2020 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында 5 яңа шартнамә төзеде:

«Зеленодольск күпләп-бүлү үзәге» («Зеленодольск күпләп-бүлү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте);

«Алабуга шәһәрендә ГТУ-ТЭС төзелеше» («КЭР-Генерация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте);

«Оксиэтилле продуктлар ассортиментын киңәйтү (МПЭГ. ТПЭГ)» («Түбән

Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыяте);

«OZON күпләп-бүлү үзәге» («Зеленодольск күпләп-бүлү үзәге 2» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте);

«KAZAN PALACE BY TASIGO (1 чират); «Полистрой Иншаат Тааххют Санайи Ве Тиджарет Аноним Ширкети» акционер җәмгыяте вәкиллеге.

Республикада аерым территорияләрне тизләтеп үстерү өчен шартлар тудыруга һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның преференциаль шартларын булдыруга юнәлдерелгән инвестиция мәйданчыклары уңышлы эшләвен дәвам итә, аларны булдыру мөмкинлеге федераль законнар белән карала, шул исәптән махсус икътисадый зоналар: Россиянең «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы иң эре махсус икътисадый зонасы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы республиканың нәтиҗәле инвестиция мәйданчыгының ачык мисалы булып тора. Аның резидентлары арасында бөтен дөньяда танылган компанияләр бар: Rockwool, 3M, Air Liquide, Armstrong, Kastamonu, Hayat, Drylock Technologies һәм башкалар.

2021 елның 1 гыйнварына «Алабуга» махсус икътисадый зонасында 57 резидент урнашкан, шуларның 33 предприятиесе сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы резидентлары тарафыннан игълан ителгән инвестицияләрнең гомуми күләме 218,4 млрд сум тәшкил итте, шул ук вакытта үзләштерелгән инвестицияләр күләме – 9,1 млрд сум (барлык чор өчен арта бара торган йомгак белән – 143,8 млрд сум). 2020 елга табыш күләме 87,3 млрд сум тәшкил итте, арта бара торган йомгак белән – 569,1 млрд сум. 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларына салым керүләре күләме – 6,8 млрд сум, арта бара торган йомгак белән – 42,1 млрд сум. «Алабуга» махсус икътисадый зонасы инфраструктурасы объектларын төзүгә 25,7 млрд сумнан артык бюджет акчасы кертелде. Резидентлар тарафыннан 7 315 эш урыны булдырылды.

2020 елда үткәрелгән Россия махсус икътисадый зонасының инвестиция җәлеп итүчәнлегенең IV илкүләм рейтингы йомгаклары буенча «Алабуга» махсус икътисадый зонасы сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы арасында 1 нче урынны яулады, ул эшкуарлык эшчәнлеге һәм резидентларның инвестиция активлыгы өчен уңай шартлар тудыруда үзенең лидерлыгын раслады.

2020 елда резидент статусын түбәндәге компанияләр алды: «ЭкоПАК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (формалы целлюлоза җепселләреннән бер тапкыр кулланыла һәм биологик таркала торган савыт-саба җитештерүне оештыру проекты), «АСЛ Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (һаваны сәнәгый кондиционерлау системалары җитештерүен булдыру проекты), «ГЭА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (меламинны химик җитештерүне булдыру проекты), «АУРУС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (AURUS модель рәте автомобильләрен җитештерүне булдыру проекты).

«Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы актив үсеш алуын дәвам итә. 2020 ел йомгаклары буенча 101 резидент һәм 26 партнер «Иннополис» махсус икътисадый зонасын үзләренең югары технологияле проектларын үстерү урыны итеп сайлады, алар арасында түбәндәге эре компанияләр

бар: «Яндекс», «Саклык банкы-Технологияләр», «Тинькофф Эшкәртү үзәге», «Ачык мобиль платформа», «Яңа болыт технологияләре», «РТК Софт Лабс», «АйСиЭл Техно», «Ай-Теко Яңа Технологияләр» һәм башкалар. «Иннополис» махсус икътисадый зонасын үстерү нәтиҗәсендә югары квалификацияле яңа эш урыннары булдырылды, алдынгы технологик чишелешләр эшләнә. «Иннополис» махсус икътисадый зонасы территориясендә резидентлар һәм партнерлар тарафыннан инвестицияләнгән акчаның гомуми күләме барлык чор өчен арта бара торган йомгак белән, алдан бәяләүр буенча, 2021 елның 1 гыйнварына 28 млрд сумнан артык тәшкил итте.

***Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешү***

2020 елда «Россия Федерацисендә капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителде, ул капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр кысаларында мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр механизмы түбәндәгеләрне күздә тота:

капитал салулар күләменә карап, 20 елга кадәр срок белән инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның салым һәм башка җайга салу шартларын тотрыкландыруны;

Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр нигезендә 6, 15 яки 20 елга кадәр срок белән «тотрыклыландыра торган төзәтмә» бирүне. Тотрыклыландыра торган төзәтмәгә түбәндәге шартлар керә: табышка салым, мөлкәткә салым, транспорт һәм җир салымы, өстәлгән кыйммәткә салым түләү сроклары һәм кире кайтару тәртибе, яңа салымнар һәм җыемнар буенча, җирдән файдалану һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге шартлары;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура чыгымнарын проекттан түләнгән салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр исәбеннән каплау мөмкинлеге (6 ел – 5 млрд сумга кадәр, 15 ел – 5 млрд сумнан 10 млрд сумга кадәр, 20 ел – 10 млрд сумнан).

Кире кайтарыла торган чыгымнарның иң чик күләме түбәндәгеләрдән арта алмый:

тәэмин итә торган инфраструктура объектлары (транспорт, энергетика, коммуналь, социаль, цифрлы инфраструктуралар объектлары) өчен фактта тотылган чыгымнарның 50 процентыннан.

иярчен инфраструктура объектлары (транспорт, энергетика, коммуналь, социаль, цифрлы инфраструктуралар объектлары) өчен фактта тотылган чыгымнарның 100 процентыннан.

Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр механизмы кысаларында федераль дәрәҗәдә капитал салуларны гамәлгә ашыруга үз акчасын кертә торган инвесторларга ярдәм күрсәтү күздә тотыла:

цифрлы икътисад, экология, авыл хуҗалыгы өлкәсендәге проектлар өчен кимендә 500 млн сум;

эшкәртү җитештерүе өлкәсендәге проектлар өчен кимендә 1,5 млрд сум;

икътисадның башка өлкәләрендәге проектлар өчен кимендә 5 млрд сум.

Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы федераль килешүләр төзү өчен норматив база 2020 елның октябрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте түбәндәге карарлары белән расланды:

«Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү, аларга үзгәреш кертү, аларның гамәлдә булуын туктату, капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау хакында» 2020 елның 1 октябрендәге 1577 номерлы;

«Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешү төзелгән инвестиция проектын тормышка ашыру өчен кирәкле тәэмин итүче һәм (яки) иярчен инфратруктураларны булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын, шулай ук кредитлар һәм заемнар буенча процентлар түләү, әлеге максатлар өчен җәлеп ителгән облигация заемнары буенча купон түләүләрен башкару чыгымнарын каплау һәм әлеге чыгымнарны каплау күләмен билгеләү өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән, дәүләт (муниципаль) предприятиеләреннән тыш) федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2020 елның 3 октябрендәге 1599 номерлы.

2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы нигезләмәләр (төшенчә аппаратын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруның төп механизмнарын тәгаенләү, инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен, инвесторларның хокукларын һәм бурычларын регламентацияләү, шулай ук капитал салуларны саклау һәм бүләкләү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр өлкәсендә вәкаләтләрен беркетү) өлешендә «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелде.

2020 елда «Россия Федерациясендә капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законын (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) үтәү йөзеннән түбәндәге эшләр башкарылды:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 июль, б-1399 нчы боерыгы белән «Россия Федерациясендә капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эш төркеме төзелде;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 20 август, 714 нче карары белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы исеменнән Капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турындагы килешүләргә имза куярга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләнде;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы ярдәмендә һәм алып барылышында 70 млрд сумнан артык суммага 3 капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешү төзелде («Татэнерго» акционер җәмгыяте, «ВБ Восток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «АГК-2» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте):

| Т/с | Проект исеме (инициатор) | Инвестицияләр күләме, млрд сум | Гамәлгә ашыру сроклары | Эш урыннары саны, кеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Зеленодольск» сәнәгать паркы территориясендә гамәлгә ашырыла торган омниканаль сәүдә үзәген булдыру («ВБ Восток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Wildberries ярдәмче компаниясе) | 5,15 | 2019-2021 | 4 010 |
| 2 | Зәй дәүләт район электр станциясендә («Татэнерго» акционер җәмгыяте) 850 МВт куәтле пар-газ җайланмасы (ПГЖ) төзү | 40,83 | 2020-2024 | 103 |
| 3 | 550 000 тонна куәтле каты коммуналь калдыкларны энергетик утильләштерү заводы төзү («АГК-2» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте) | 25,0 | 2018-2022 | 98 |
| **БАРЛЫГЫ:** | | **70,98** | **-** | **4 211** |

Инфраструктураны финанслау механизмы

2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан төбәкләрдә инфраструктура үсешенең яңа механизмы расланды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карары белән яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләре расланды, аларны гамәлгә ашыру максатларында янга кала торган бюджет акчасын инвестиция проектлары өчен инфраструктураны үстерүгә җибәрә торган төбәкләр өчен бюджет кредитлары буенча бурычларны бетерү каралган. Бурычларны бетерү механизмы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 октябрендәге 1705 номерлы карары белән билгеләнде.

*Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория*

Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр булдыру инвестицияләр җәлеп итүнең нәтиҗәле коралы булып тора. Аларның төп максаты – моношәһәрләр икътисадын диверсификацияләү һәм аларның инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру.

2016 ел башыннан Татарстан Республикасында Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Зеленодольск һәм Менделеевск моношәһәрләре территорияләрендә 5 социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзелде.

Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары өчен түбәндәгеләр каралды:

табышка салымның киметелгән ставкасы (федераль бюджетка исәпләү өлешендә – эшчәнлектән беренче табыш алынган вакыттан беренче 5 салым чоры дәвамында 0 процент; Россия Федерациясе субъектлары бюджетына исәпләү өлешендә – беренче табыш алынган вакыттан 5 салым чоры дәвамында 5 процент һәм киләсе 5 салым чоры дәвамында 10 процент);

оешмалар мөлкәтенә салым түләүдән азат итү;

җир салымын түләүдән азат итү;

иминият кертемнәренең гадәти тәртиптә түләнә торган 30 процент урынына 7,6 процент күләмендә киметелгән тарифлары (шул исәптән Пенсия фондына – 22

процент урынына 6 процент, Социаль иминият фондына – 2,9 процент урынына 1,5 процент һәм Мәҗбүри медицина иминияте фондына – 5,1 процент урынына 0,1 процент). Ташлама социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резиденты статусын алган көннән 10 ел дәвамында бирелә һәм социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр булдырылган көннән 3 елдан да соңга калмыйча шундый статус алган резидентларга карата кулланыла.

2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында төзелгән социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләрнең 112 резиденты Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары реестрына кертелде.

Әлеге компанияләр тарафыннан социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары статусы бирелгән вакыттан 17,3 млрд сум капитал салулар башкарылды (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) һәм 9 625 яңа эш урыны булдырылды.

2020 елның IV кварталы йомгаклары буенча (арта бара торган йомгак белән):

«Яр Чаллы» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясендә 38 резидент теркәлде, алар тарафыннан резидентлар статусы бирелгән вакыттан 10,6 млрд сум капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) гамәлгә ашырылды һәм 5 204 яңа эш урыны булдырылды;

«Түбән Кама» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясендә – 20 резидент, алар тарафыннан резидентлар статусы бирелгән вакыттан 2,3 млрд сум капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) гамәлгә ашырылды һәм 500 яңа эш урыны булдырылды;

«Чистай» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясендә – 24 резидент, алар тарафыннан резидентлар статусы бирелгән вакыттан 573,3 млн сум капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) гамәлгә ашырылды һәм 624 яңа эш урыны булдырылды;

«Зеленодольск» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясендә – 26 резидент, алар тарафыннан резидентлар статусы бирелгән вакыттан 3,6 млрд сум капитал салулар гамәлгә ашырылды һәм 3 223 яңа эш урыны булдырылды;

«Менделеевск» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясендә – 4 резидент, алар тарафыннан резидентлар статусы бирелгән вакыттан 214,7 млн сум капитал салулар гамәлгә ашырылды һәм 74 яңа эш урыны булдырылды.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында сораулар исемлеге буенча мәгълүмат**

**Гражданлык җәмгыяте**

***1. Татарстан Республикасында гражданнарның төрле категорияләренә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү максатларында башкарыла торган эш турында.***

Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 73-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында күрсәтелә.

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасында адвокатлар, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм аларның карамагындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары катнаша. 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан адвокатлар хезмәтләре өчен түләүгә 496,8 мең сум бүлеп бирелгән.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы ел саен Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы белән бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында килешү төзи. Хәзерге вакытта бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт системасында 140 адвокат катнаша, алар бушлай юридик ярдәмнең түбәндәге төрләрен күрсәтәләр: телдән һәм язма формада юридик консультация бирү, гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү, судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гражданнарның мәнфәгатьләрен яклауда вәкил булу. 2020 елда бушлай юридик ярдәм күрсәтү сорап адвокатларга 78 граждан мөрәҗәгать иткән. Аз керемле гражданнар, I һәм II төркем инвалидлары барыннан да ешрак мөрәҗәгать иткән.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында һәм алар карамагындагы учреждениеләрдә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өчен җаваплы затлар билгеләнгән. 2020 елда 391 гражданга бушлай юридик ярдәм күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 22 октябрендәге 953 номерлы карары белән «Түләүсез юридик ярдәм» мәгълүмат системасы турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) расланды. Аның төп бурычларының берсе – 73-ТРЗ номерлы Закон кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтелгән гражданнар саны турында хисап тоту. Нигезләмәдә каралганча, мәгълүмат системасында 73-ТРЗ номерлы Законның 12 статьясындагы 1 өлешендә каралган категорияләргә кергән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында белешмәләр һәм документлар тупланырга тиеш.

***2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының инициатива күрсәтүче гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге механизмы турында.***

Гражданнарны җәмгыятьне үстерүгә җәлеп итү эше ведомство һәм муниципаль иҗтимагый советларда коммерциячел булмаган оешмалар вәкиллекләре аша алып барыла.

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары карамагында – 33, республиканың муниципаль берәмлекләрендә 44 иҗтимагый совет эшли.

Гражданнарны җирле проблемаларны хәл итүгә җәлеп итү ресурсы буларак, территорияләрдәге иҗтимагый үзидарәләр республиканың күпчелек муниципаль районнарында актив кулланыла.

Татарстанда шулай ук 2014-2024 елларга «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының (алга таба – ярдәмче программа) социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба - СЮКБО) булышлык итү буенча ярдәмче программасы эшли. Аның максаты – КБОның республиканың социаль-икътисадый үсешендә катнашуын стимуллаштыру, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ татулыкны саклау, халыкка күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең балансланган булуы нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү.

Төп чараларның берсе – КБОга инфраструктур ярдәм күрсәтү. Шул максаттан чыгып, республикада КБОның муниципальара ресурс үзәкләре, шулай ук «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы эшли. Алар ярдәмче программа акчалары исәбеннән укыту, консалтинг эшчәнлеген һәм КБОның эшчәнлеген тәэмин итүне башкара. КБОның муниципальара ресурс үзәкләре Казан, Чаллы, Әлмәт, Чистай, Буа һәм Кукмара шәһәрләрендә урнашкан.

Социаль проектларны гамәлгә ашыручы һәм СЮКБО теркәргә планлаштырган СЮКБО вәкилләре һәм гражданнарның белем дәрәҗәсен күтәрү өчен КБО муниципальара ресурс үзәкләре тарафыннан берлектә «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДАМУ (алга таба - К(И)ФУ) белән берлектә даими рәвештә мәгариф чаралары үткәрелә. 2020 елда «КБО көне» интенсив курслары, «КБОны ничек төзергә», «КБОның грантлар буенча хисап тотуы» семинарлары, «Татарстан Республикасы грантлары» мәгълүмат-белем бирү курслары, «КБОның мәгълүмати ачыклыгы» һәм башка чаралар уздырылды.

Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә СЮКБОга ярдәм итүнең муниципаль программалары кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла.

Гражданлык инициативаларын хуплау һәм граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында республикада «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла. 2015-2020 елларда 15 җәмәгать эшлеклесе һәм республиканың 24 коммерциячел булмаган оешмасы лауреат исеменә лаек булды.

Җирле үзидарә органнарына методологик ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан СЮКБО белән хезмәттәшлекне көчәйтү, шулай ук СЮКБО эшчәнлегенең нәтиҗәле технологияләрен һәм ысулларын куллану буенча методик тәкъдимнәр эшләнде.

СЮКБО эшчәнлегенә мәгълүмати ярдәм күрсәтү зур әһәмияткә ия. Ул социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруны республика массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртудан гыйбарәт. Татарстан Республикасы Иҗтимагый

палатасы, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Татмедиа), шулай ук СЮКБОга ярдәм итү буенча ресурс үзәкләре тарафыннан социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру буенча зур эш башкарыла.

Татмедиа коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан әһәмиятле социаль-гуманитар проектларны гамәлгә ашыруга, шулай ук Татарстан Республикасында ирекләләр хәрәкәте һәм хәйриячелек идеяләрен формалаштыруга даими мәгълүмати ярдәм күрсәтә.

2020 елда йогышлы коронавирус чире таралу шартларында волонтерлар ярдәмгә мохтаҗ барлык гражданнар өчен аларның иң зур ярдәмчеләреннән берсе булды. Ирекләләр хәрәкәте вәкилләре куркыныч яный дигән төркемнәргә кертелгән, шулай ук өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидлар һәм гражданнарның башка категорияләре килергә тиешле оешмаларга һәм учреждениеләргә ярдәм күрсәтте.

Кайнар линиягә бирелгән заявкалар «Волонтерлар-медицина хезмәткәрләре» бөтенроссия хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсе белән берлектә Гомумроссия халык фронтының яшьләр төркеме тарафыннан эшкәртелде. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты базасында «Без бергә» волонтерлар штабы эшләде, монда иҗтимагый оешмалар студентлары һәм активистлары гына түгел, спорт, мәдәният, мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре, битараф булмаган гражданнар катнашты.

Казанда «Казан шәһәре» шәһәр округында халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт учреждениесе базасында 2020 елның 28 мартыннан 25 июленә кадәр 65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга азык-төлек һәм дарулар китерү буенча «БЕЗ ЯРДӘМ ИТӘБЕЗ!» үзәге эшләде.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән 2020 елда «Ярдәм янәшә!» республика хәрәкәтенә этәргеч бирелде. Ул халыкның якланмаган катламнарына ярдәм итүгә, ирекләләр хәрәкәте аша ярдәм күрсәтүгә, предприятиеләр һәм бизнеска хәйрия ярдәменә, иҗтимагый коммерциячел булмаган оешмаларның һәм аерым активистларның эшен оештыруга, үзара ярдәмләшүгә һәм күркәм күршеләрчә ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән иҗтимагый инициативаларны берләштерде. Җәмәгатьчелек оешмалары, предприятиеләр җитәкчеләре, волонтерлык хәрәкәте вәкилләре, бизнесменнар хәрәкәткә этәргеч бирүче көч булды, алар халыкка төрле төр ярдәм күрсәтүдә актив катнашты. Кешеләрне ирекле төстә халыкка ярдәм күрсәтүгә җәлеп итү буенча онлайн-платформа (ярдәмянәшә16.рф) булдырылды, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарында мобиль ярдәм пунктлары эше оештырылды.

«#БезБергә» федераль проектын һәм «Ярдәм янәшә!» республика проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләре территориясендә гомуми саны 6 686 кешелек волонтерлар штабы оештырылды, алар тарафыннан 16 388 заявка эшкәртелде.

Әлеге проектлар үз эшчәнлеген туктатмады, төп максаты кешеләргә конкрет ярдәм күрсәтү, төбәк территориясендә үзара ярдәм форматларын киңәйтү булган #БезБергә төбәк клубына әверелде.

2020 ел ахырына әлеге хәрәкәттә теркәлгән ирекләләр хәрәкәте вәкилләре саны 5,5 мең кешегә җитте. Республиканың барлык муниципаль берәмлекләре

территориясендә 9 меңнән артык заявка эшкәртелде. Волонтерлар тарафыннан кешеләргә 55 меңгә якын азык-төлек җыелмасы китерелде, 46 меңнән артык кайнар аш өләшенде, 500 дән артык онлайн-консультация күрсәтелде (стресска каршы ничек көрәшергә, якыннарыңны ничек тынычландырырга, карантин вакытында нәрсә белән шөгыльләнергә һ.б.). Ирекләләр хәрәкәте вәкилләре ярдәме белән «#БезБергә» һәм «Ярдәм янәшә!» үзара ярдәм акциясе 2021 елда да дәвам иттерелә.

**Икътисад, бюджет**

***3. COVID-19 пандемиясенә бәйле рәвештә 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясенең төп күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү ихтыяҗы бармы?***

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы коллегиясендә 2020 елга эш йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә (алга таба – Статегия-2030) үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү йөкләнде. Аларда федераль дәрәҗәдә яңа стратегик документлар кабул ителүне – 2030 елга кадәр Россия үсешенең илкүләм максатлары, Халыкны эш белән тәэмин итүне һәм халыкның керемнәрен элеккеге дәрәҗәсенә кайтаруны, икътисадның үсешен тәэмин итә торган гамәлләрнең гомуммилли планы раслануны исәпкә алу зарурлыгы билгеләнде. Моннан тыш, 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алу йомгаклары игътибарга алыначак.

Стратегия-2030ны эшләгәндәге кебек үк, аңа үзгәрешләр кертү эшенә дә катнашучыларның киң даирәсе җәлеп ителәчәк.

***4. Татарстан Республикасында салым түләүчеләрнең билгеле бер эшчәнлектән алынган керемгә салына торган бердәй салым төреннән салымның башка төрләренә күчүе буенча башкарыла торган эш турында.***

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, 2021 елның 1 мартына бердәй салым түләүчеләрнең гомуми саныннан:

- 1,8 мең кеше салым салуның гомуми системасына күчте;
- 13,3 мең кеше билгеле бер эшчәнлектән алынган керемгә салына торган бердәй салымны башка махсус салым режимнары белән бергә алып барды;
- гариза язып 23,2 мең кеше башка махсус салым режимнарына күчте.

Билгеле бер эшчәнлектән алынган керемгә салына торган бердәй салым түләүчеләрне салым салуның башка системаларына күчерү, шулай ук республика законнарын федераль законнарга туры китерү өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 25 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 90-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде, аның нигезендә салым салуның патент системасына (алга таба – СПС) түбәндәге үзгәрешләр кертелде:

- эшкуарлык эшчәнлеге төрләре исемлеге 64 төрдән 82 гә кадәр арттырылды;

- бизнес алып бару өчен кулланыла торган мәйданнарга, сәүдә залларына һәм җәмәгать туклануында хезмәт күрсәтү залларына  мәйдан ягыннан максималь чикләүләр сакланды - 150 кв. метр;

- республика территориясен муниципаль берәмлекләрнең 5 төркеменә бүлү сакланды.

2021 елның 1 мартына 20 156 шәхси эшмәкәр (алга таба – ШЭ) СПС куллана. СПС түләүчеләрнең гомуми санынннан 17 936 ШЭ гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан 31 гыйнварына кадәр булган вакыт аралыгында башланган патент алган, шул исәптән 1 043 ШЭ күчеш шартлары буенча патент алган. Гамәле 2021 елның 1 февраленнән 28 февральгә кадәр булган вакыт аралыгында башланган патент алган ШЭ саны – 2 819 берәмлек.

Хәзерге вакытта составына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы вәкилләре кергән ведомствоара эш төркеме гамәлләре кысаларында СПС куллануга бәйле проблемалы мәсьәләләр буенча республиканың эшкуарларыннан һәм эшлекле берләшмәләреннән мәгълүмат җыю һәм анализлау алып барыла.

Хәзерге вакытта төп ике проблема ачыкланды:

- «сәүдә заллары булган стационар сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе» һәм «җәмәгать туклануын оештыру объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы хезмәтләре» эшчәнлеге төрләре өчен салым йөкләнешенең артуы;

- территориаль бүленешнең 2-5 төркеменә караган муниципаль берәмлекләрдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы эшкуарларга салым йөкләнешенең артуы.

Югарыда әйтелгән ведомствоара эш төркеме эшчәнлеге кысаларында 90-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләнә.

***5. Татарстан Республикасында уртача хезмәт хакын 2021 елда арттыру перспективалары турында.***

Татарстан Республикасы предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 2020 елда 39 588,3 сум тәшкил итте һәм 2019 ел белән чагыштырганда 5,6 процентка артты.

Предприятиеләрне үстерү планнарын, муниципаль берәмлекләрнең һәм Татарстан Республикасының тармак министрлыкларының фаразларын исәпкә алып, 2021 елда республикада уртача хезмәт хакын 2020 ел дәрәҗәсенә карата 5,2 процентка арттыру фаразлана.

***6. Авыл инфраструктурасын үстерү (мәгариф, сәламәтлек саклау, юллар, мәдәният объектлары һ.б.) һәм авыл торак пунктларында яңа эш урыннары булдыру турында.***

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән 2020-2025 елларга «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) расланды. Ул

авыл территорияләрендә һәм авыл агломерацияләрендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын, шул исәптән торак шартларын яхшырту, инженерлык һәм социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә комплекслы караш нигезендә эш итүне күздә тота.

Татарстан Республикасында «2013-2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасына «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» ярдәмче программасы кертелгән.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары белән Татарстан Республикасы бюджетыннан республика муниципаль берәмлекләре бюджетларына Дәүләт программасы юнәлешләре буенча субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре расланды.

Дәүләт программасын гамәлгә ашыруның беренче елында аны финанслау күләме 3 084,9 млн сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 1 328,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 040,4 млн сум, җирле бюджетлардан – 40,3 млн сум, бюджеттан тыш акча – 675,5 млн сум.

Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан түбәндәге юнәлешләр финансланды:

1) гражданнарның торак шартларын яхшыртуга – 410,2 млн сум, бу исә 21,8 мең кв. метр торакны файдалануга тапшырырга һәм 315 гаиләне торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Акча авыл җирлегендә торак төзүгә һәм сатып алуга бирелә. Бюджет исәбеннән – 70 %, гражданнар исәбеннән –30 %  финанслана;

2) торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелешенә финанс ярдәме күрсәтүгә – 217,2 млн сум. Бу 6,4 мең кв. метр торакны 91 гаиләгә файдалануга тапшырырга мөмкинлек бирде;

3) инженерлык инфраструктурасын һәм торак төзелеше мәйданчыкларын комплекслы төзекләндерү проектларын үстерүгә – 351,5 млн сум. 6,86 км газ бүлү челтәре, 24 км сүүткәргеч челтәре төзелде, торак төзелеше мәйданчыкларын комплекслы төзекләндерү буенча 10 проект гамәлгә ашырыла;

4) авыл территорияләрен төзекләндерүгә – 791,8 млн сум. 500 дән артык проект гамәлгә ашырылды. Финанслау муниципаль районга 1 объектка 2 млн. сумга кадәр бирелә һәм объектның смета бәясенең 70 процентын тәшкил итә;

5) «Авыл ипотекасы» программасын гамәлгә ашыруга. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында кредитлар бирү күләме буенча алдынгы урында тора, торак сатып алу һәм төзү өчен 1 600 дән артык гаиләне акча белән тәэмин итә. Бирелгән кредитларның гомуми күләме 3,6 млрд сум тәшкил итте.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 ноябрендәге 1567 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла торган ташламалы ипотека программасы ярдәмендә гражданнар еллык 0,1  проценттан 3 процентка кадәр ташламалы ставка буенча торак  төзеләчәк җир кишәрлеге,  яңа йортта фатир, әзер шәхси йорт алуга, шулай ук инде булган җир кишәрлегендә йорт салуга кредит алырга мөмкин. Максималь срок – 25 ел. Заемщикның үз акчасы кимендә  10 % булырга тиеш.

Кредитның максималь суммасы – 3 млн сум. Ипотеканың гамәле авыл җирендә һәм халкы 30 мең кешедән артмаган шәһәрләрдә җиргә яки торакка кагыла.

«Авыл территорияләрендә транспорт инфраструктурасын үстерү» ведомство проекты кысаларында гомуми файдаланудагы автомобиль юллары белән авыл торак пунктларын тоташтыручы автомобиль юлларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә 527,6 млн сум тотылды, бу исә 6 торак пунктны 15,6 км озынлыктагы юл белән тоташтырырга мөмкинлек бирде.

«Авыл территорияләренең заманча йөзе» ведомство максатчан программасына 70,9 млн сум бүленгән, 10,3 км суүткәргеч торбалары челтәре төзелгән.

«Элемтә турында» 2003 елның 7 июлендәге 126-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында 100 дән 500 гә кадәр кеше яшәгән торак пунктлар исемлеге расланды, аларда күчмә радиотелефон элемтәсе хезмәтләрен күрсәтү өчен кулланыла торган элемтә чаралары белән җиһазландырылган тоташтыру нокталары урнаштырылырга тиеш. Әлеге исемлеккә Wi-Fi тоташтыру нокталарын урнаштыру өчен Татарстан Республикасының 755 торак пункты кертелде.

2020 елда аз кеше яши торган 5 торак пункт (Наратлык (Биектау муниципаль районы), Түбән Арбаш (Кукмара муниципаль районы), Карагай (Лениногорск муниципаль районы), Дусай (Мөслим муниципаль районы) һәм Сосновка (Нурлат муниципаль районы) авыллары) «Таттелеком» ГАҖ операторының кәрәзле элемтә челтәрләренә тоташтырылды.

2020 ел дәвамында кәрәзле элемтә операторлары тарафыннан 1 034 база станциясе төзелде, алар исәбенә 2G (596), 3G (327) һәм 4G (1 034) стандартында элемтә хезмәте күрсәтүче җиһазлар кертелде.

«Таттелеком» ГАҖ элемтә операторы тарафыннан «Челтәр компаниясе» АҖ белән берлектә GPON технологиясе буенча абонентларны тоташтыру өчен челтәрләр төзү проекты гамәлгә ашырыла, аның ярдәмендә кулланучыга 100 Мбит/с ка кадәр һәм аннан зуррак тизлектә хезмәт күрсәтелергә мөмкин. 2020 елда әлеге проект кысаларында 3 585 йорт элемтә челтәренә тоташтырылды, 80 млн сумлык инвестиция кертелде. 2021 елга республиканың 70 торак пунктында 60 меңнән артык йортны проектка кертү планлаштырыла, инвестицияләрнең күләме 200 млн сум тәшкил итәчәк.

«Мәгълүмати инфраструктура» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә (алга таба – «Интернет» челтәре) социаль әһәмияткә ия булган объектларны тоташтыру гамәлгә ашырыла. 2021 елда авыл җирендә урнашкан 2 110 объектны челтәргә тоташтыру планлаштырыла.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан фаразлана торган елга эш урыннары булдыру турында белешмәләр даими рәвештә җыела. 2020 елда авыл җирендә 7,9 мең эш урыны булдыру каралган. 8,7 мең эш урыны инде булдырылды. Татарстан Республикасы муниципаль районнары белешмәләренә караганда, 2021 елда яңа ачылган һәм инде эшләп килүче предприятиеләрдә 11,0 мең яңа эш урыны булдыру планлаштырыла. Иң күп эш урыннарын Биектау (1,5 мең), Лаеш (670), Саба (207), Теләче (110) һәм Апас (102) муниципаль районнарында булдырырга исәп тотыла.

Муниципаль районнарда яшәүчеләргә сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтү максатларында фельдшерлык-акушерлык пунктлары (алга таба –ФАП) төзү юнәлешендә эш алып барыла. 2020 елда 43 ФАП төзелгән, финанслауның гомуми күләме 147,4 млн сум тәшкил иткән. 2021 елда 42 ФАП төзү күздә тотыла, финанслауның гомуми күләме – 171,3 млн сум.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган программалар кысаларында 2020 елда Татарстан Республикасы авылларында 9 балалар бакчасы төзелде, шул исәптән:

5 – «Демография» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында: Лаеш (260 урынга исәпләнгән «Көньяк парк» ТК), Питрәч (220 урынга исәпләнгән «Царево утары» ТК), Саба (50 урынга), Тукай (140 урынга) һәм Биектау (340 урынга) муниципаль районнарында;

4 – җитәкчелекнең аерым йөкләмәләре кысаларында һәм инвесторлар акчасына Әлки муниципаль районының Хузангай авылында (40 урынга), Арча муниципаль районының Наласа авылында (40 урынга), Зеленодольск муниципаль районының Новониколаевский поселогында (80 урынга), Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авылында (50 урынга).

2020 елда Алексеевск районының Олы Тигәнәле авылында (20 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә балалар бакчасы булган 60 урынга исәпләнгән) һәм Питрәч районының Яңа Шигали авылында (1 224 урынга исәпләнгән «Царево утары» ТК) 2 мәктәп төзелде.

2021 елда Татарстан Республикасы бюджеты хисабына Лаеш муниципаль районының Усад авылында 500 урынга исәпләнгән мәктәп, Актаныш муниципаль районының Актаныш авылында 462 урынга исәпләнгән мәктәп төзелә башлады, Балтач муниципаль районының Норма авылында 120 урынга исәпләнгән балалар бакчасын төзү тәмамланып килә.

2021 елда «Демография» илкүләм проекты нигезендә Биектау муниципаль районының Эстачи (220 урынга исәпләнгән), Лаеш муниципаль районының Державин (50 урынга исәпләнгән), Богородский (120 урынга исәпләнгән) һәм Питрәч муниципаль районының Көек авылларында (220 урынга исәпләнгән) балалар бакчалары төзелә башлады.

«Мәдәният» илкүләм проектының «Мәдәни мохит» төбәк проекты кысаларында 2020 елда 8 торак пунктта: Буа муниципаль районының Кырык-Садак (100 урынга исәпләнгән), Кукмара муниципаль районының Иске Юмья (200 урынга исәпләнгән), Питрәч муниципаль районының Надеждино (100 урынга исәпләнгән), Тукай муниципаль районының Илбухтино (200 урынга исәпләнгән), Чирмешән муниципаль районының Светлогорск (50 урынга исәпләнгән), Апас муниципаль районының Түбән Биябаш һәм Ясаш-Барыш (50 урынга исәпләнгән), Саба муниципаль районының Сатыш (300 урынга исәпләнгән) авылларында авыл мәдәният йортлары төзелде. Финанслауның гомуми суммасы 105,7 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан 61,3 млн сум тәшкил итте.

***7. М-12 автомобиль трассасын (Мәскәү-Түбән Новгород-Казан) төзү икътисадый яктан нинди файда бирергә мөмкин?***

М-12 «Мәскәү-Түбән Новгород-Казан» автомобиль юлын төзү автомобиль юллары инфраструктурасын киңәйтү һәм яңарту аша Россия Федерациясе территориясенең икътисадый бәйләнеше, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының транспорт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен арттырачак. Тизйөрешле М-12 юлы илнең икътисадый үсешнең перспективалы үзәкләре аша үтәчәк һәм юлны икеләтә тизрәк узуны тәэмин итәчәк. Мәскәүдән Казанга 6,5 сәгать эчендә барып җитәргә мөмкин булачак.

Яңа юл Казан шәһәренең транспорт күп йөргән, авыр йөк төягән һәм башка транзит транспортлы юл кишәрлекләрен читләтеп үтәргә мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге проект нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы инфраструктурасына 166 млрд сум тирәсе акча керәчәк.

Бу төзелеш автомобиль төзү, нефть химиясе, логистика һәм шундый тармакларда яңа эш урыннары булдырырга ярдәм итәчәк. Файдалануга тапшырылганнан соң 3 ел дәвамында эксплуатацияләү этабында яңа эш урыннары уннан унбиш меңгә кадәр артачак.

Юллар төзү барышында республикада, җирле халыкны эшкә җәлеп итеп, хезмәт күрсәтү өчен юл-эксплуатация базалары төзеләчәк.

***8. Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт йөртүчеләргә җайга салынмый торган тарифлар буенча гражданнарның ташламага хокуклы категорияләрен йөрткәндә алынмый калган керемнәрен компенсацияләү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу механизмнары турында.***

Хәзерге вакытта «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориядәге гражданнар өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты ведомстволар арасында килештерү уза. Әлеге проект тәкъдим иткән үзгәрешләрне кабул итү нәтиҗәсендә шәһәрдә йөри торган транспортта транзакция бәясен 20 сумга кадәр каплау һәм шәһәр яны транспортында йөрү бәясен (1 чакрым барган өчен) 2 сум 40 тиенгә кадәр кайтару ставкалары яңадан каралачак.

***9. Халыкара туристлык юнәлеше үзгәрү шартларында Татарстан Республикасында эчке һәм экологик туризмга ярдәм итү һәм аны үстерү чаралары турында.***

2020 елда туристлык өлкәсе яңа коронавирус йогышлы чире таралу нәтиҗәсендә аеруча зыян күргән икътисад тармакларының берсе дип танылды (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы чире таралу нәтиҗәсендә вазгыятьнең начараюы шартларында Россия икътисадының иң күп зыян күргән тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары).

Татарстан Республикасының туристлык өлкәсендә күрсәтелгән хезмәтләр күләме, 2020 елда чиктәш тармакларны исәпкә алып, 17 млрд сум тирәсе дип бәяләнә

(2019 ел белән чагыштырганда 40 процентка кимрәк). Республикага 1,9 млн тирәсе турист килде, бу 2019 ел күрсәткеченнән 47 процентка кимрәк.

Туристлык тармагына ярдәм итү һәм эчке туристлык агымын арттыру максатларында Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан 3 яңа проект тәкъдим ителде:

1. «Ял көннәрендә 1001 ләззәт» яңа туристлык маршруты.

Программа республиканың 11 муниципаль районыннан берсе буенча 1 кешегә 2 200 сум исәбеннән комплекслы тур тәкъдим итә. Бу суммага җирле кунакханәдә яшәү (бер төн, ике урынлы бүлмә), иртәнге аш, ике тапкыр төшке аш ашау һәм ике экскурсия кертелгән. Программа нигездә Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен каралган.

2. Идел буе федераль округы төбәкләренең туристлык мөмкинлекләрен үстерүгә үзара ярдәм итүгә юнәлтелгән «Күршеләргә кунакка» программасы.

Программада Татарстан һәм Марий Эл, Удмуртия Республикасы, Ульяновск, Самара, Оренбург, Түбән Новгород өлкәләре һәм Пермь крае катнашты. Татарстанның туристлык мөмкинлекләре турында радио, телевидение, массакүләм мәгълүмат чараларында 40 сюжет чыкты.

3. «2+1» акциясе.

Әлеге акция Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе һәм «Казан шәһәренең туристлык-мәгълүмат үзәге» ҖЧҖ ярдәме белән гамәлгә ашырылды.

Ике төн рәттән кунган өчен отель сайтында алдан ук түләп куйган очракта, туристка тагын бер төнне бушлай куну, ә балалары булган гаиләләргә 12 яше тулмаган балаларын бушлай кунакханәгә урнаштыру мөмкинлеге бирелде. Акциядә республиканың 24 кунакханәсе катнашты. Броньлаудан 2020 елның җәй айларында аеруча актив файдаландылар. Туристларга шулай ук берничә кафеда һәм ресторанда гомуми чек суммасыннан 25 % ташлама, Казан шәһәренең тарихи үзәге буенча бушлай экскурсия алу мөмкинлеге бирелде.

Хәзерге вакытта республика территориясендә экологик һәм шәһәр яны туризмын үстерү буенча чаралар комплексы эшләнә.

2020 елда «ЭкоТат» тарихи-мәдәни, экологик һәм авыл туризмы проекты гамәлгә ашырыла, ул Татарстанның төньяк-көнчыгышындагы 9 муниципаль районда (Арча, Әтнә, Балтач, Биектау, Кукмара, Мамадыш, Питрәч, Саба, Теләче) уздырыла. Алар органик продукция җитештерү өчен экологик яктан уңай шартларга ия, бу исә гастрономия туризмын үстерү өчен бәхәссез өстенлек булып тора. Матур табигать күренешләре, сирәк очрый торган хайваннар һәм кошлар яши торган урманнар, саф һава – болар барысы да экологик туристлык өчен яхшы мөмкинлекләр бирә. Татар халкының милли бәйрәмнәре һәм традицияләре сакланып калган авыллар Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән туристларда гына түгел, җирле халыкта да зур кызыксыну уята.

Татарстан Республикасының рекреация мөмкинлекләрен ачыклау, экотуризм инфраструктурасының яңа проектларын үстерү һәм «Татарстан Республикасы шәһәрләрен үстерү институты» фонды тарафыннан ял оештыру буенча аз һәм уртача күләмдә инвестицияләре булган эшкуарлар өчен инвестиция проектларын булдыру

максатларында «Табигать территорияләрен һәм экотуристлыкны үстерү дирекциясе» департаменты (алга таба – Дирекция) төзелде.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты Дирекция белән берлектә экологик туристлык һәм табигать туристлыгы өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыручы эшкуарларга ярдәм итүнең кайбер механизмнарын эшли:

- Россия кредит оешмаларында кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү рәвешендә финанс ярдәме;
- Татарстан Республикасы Инвестиция советында карау йомгаклары буенча җир кишәрлеген сатуга куймыйча гына бирү мөмкинлеге;
- табигать туристлыгы һәм экологик туристлык объектларына инженерлык коммуникацияләре уздыру һәм юллар төзү мөмкинлеге.

## Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү, территорияләрне төзекләндерү

***10. Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен тарифлар формалаштыру турында халыкка объектив һәм тулы мәгълүмат бирү тәртибе хакында.***

Тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу федераль законнарга – тармак федераль законнарына, бәяләр билгеләү нигезләренә һәм тарифларны җайга салу кагыйдәләренә, шулай ук тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләргә таянып башкарыла.

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына (алга таба – Тарифлар буенча дәүләт комитеты) гамәлдәге законнарда каралган срокларда тиешле өлкәләрдә җитештерү программаларын һәм тарифлар билгеләү буенча тәкъдимнәрен (тарифларны билгеләү (көйләү) турында гариза һәм булачак дип белдерелгән чыгымнарны раслый торган материаллар) тапшыра.

Коммуналь хезмәтләргә тарифларны исәпләү хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру күләмнәреннән һәм зарури тулай керем зурлыгыннан – җайга салына торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру һәм коммуналь инфраструктура объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү өчен чираттагы чор дәвамында кирәкле финанс чараларының икътисадый нигезләнгән күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла.

Тарифларны билгеләү Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан эшчәнлеге җайга салына торган оешма тәкъдимнәрен, бу тәкъдимнәргә нигез буларак әлеге оешма биргән материалларны, шул исәптән чираттагы хисап чорына һәм чыгымнарны һәм зарури тулай керемне исәпләүнең соңгы датасына бухгалтерлык һәм статистика хисабы күчермәләрен, шулай ук уздырылган тикшерүләр турында белешмәләрне анализлау, тикшерү һәм экспертиза уздыру юлы белән башкарыла. Шул рәвешле, тарифларны исәпләгәндә, җайга салына торган оешманың икътисадый нигезләнгән һәм документаль расланган чыгымнары гына исәпкә алына.

Шул ук вакытта абонентларның бер категориясе өчен икътисадый нигезләнгән дәрәҗәсеннән югарырак тарифлар билгеләү хисабына абонентларның башка

категорияләре өчен икътисадый нигезләнгән дәрәҗәсеннән түбәнрәк тарифлар билгеләү рөхсәт ителми.

Тарифлар билгеләү турында карар кабул итү барышы һәркемгә ачык. Составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, республика министрлыклары, ведомстволары, иҗтимагый оешмалары вәкилләре кергән килештерү комиссиясе утырышында алдан карап тикшерелгәннән соң, карар Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында кабул ителә.

Карарлар законнар таләпләренә катгый туры китереп кабул ителә, Татарстан Республикасы Прокуратурасында тикшерү уза, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарыла.

Билгеләнгән тарифлар турында бөтен мәгълүмат, шулай ук идарә утырышларының җайга салына торган оешма чыгымнары җентекләп аңлатылган беркетмәләреннән күчермәләр түбәндәге адрес буенча Тарифлар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла: https://kt.tatarstan.ru/postprikaz.htm.

Моннан тыш, кулланучыларның мәнфәгатьләрен яклау һәм җылылык, су белән тәэмин итү, юынтык су агызу, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәләрендә оешмалар эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү максатларында җайга салына торган оешмалар җайга салына торган эшчәнлек турында мәгълүматтан ирекле файдалануны тәэмин итәргә тиеш.

Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә аңлатып бирелергә тиешле мәгълүмат составы, тәртибе, сроклары һәм ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә мәгълүматны ачу стандартлары турында» 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган мәгълүматны ачу стандартлары белән билгеләнә.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә ачык бирелергә тиешле мәгълүмат составы, тәртибе, сроклары һәм ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәре оешмалары һәм җайга салу органнары тарафыннан мәгълүматны ачу стандартлары турында» 2013 елның 5 июлендәге 570 номерлы карары белән расланган мәгълүматны ачу стандартлары нигезендә билгеләнә.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә ачык бирелергә тиешле мәгълүмат составы, тәртибе, сроклары һәм ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүматны ачу стандартларын раслау турында» 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган мәгълүматны ачу стандартлары нигезендә билгеләнә.

Шул исәптән җайга салына торган оешманың җайга салуның чираттагы чорында финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүмат , җитештерүдә төп чыгымнары структурасын да кертеп, ирекле файдалану өчен ачык булырга тиеш (җайга салына торган эшчәнлек өлешендә). Һәр оешманың хезмәт күрсәтү эшчәнлеге буенча мәгълүмат белән Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге сайтында танышырга була: https://kt.tatarstan.ru/raskritie-informatsii.htm.

Торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар формалаштыру турында халыкка объектив һәм тулы мәгълүмат бирү өчен Тарифлар буенча дәүләт комитеты сайтында «Еш бирелә торган сораулар» бүлеге даими яңартылып тора.

Тиешле аналитик мәгълүмат көн саен «Интернет» челтәрендәге социаль челтәрләрдә урнаштырыла.

Халыкта коммуналь хезмәтләргә тарифлар билгеләү белән бәйле сораулар туган очракларда атна саен Тарифлар буенча дәүләт комитетында гражданнарны кабул итү уздырыла. Сорауларны кайнар линиягә шалтыратып бирергә дә мөмкин: +7(843) 221-82-00.

1. «Безнең ишегалды» республика программасын гамәлгә ашыру турында.

Республиканың барлык күпфатирлы йортлары ишегалларын төзекләндерү максатыннан 2020 елда Татарстанда «Безнең ишегалды» дигән яңа социаль программа башланып китте, аның кысаларында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан муниципаль берәмлекләр һәм «Татарстан Республикасының техник инвентаризация бюросы» АҖ белән берлектә ишегалларында инвентаризация ясалды. Аның нигезендә 9 546 ишегалдының 6 775 ендә (49,6 млн. кв. метр) комплекслы ремонт уздыру кирәклеге ачыкланды.

Объектлар исемлеге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең заявкалары нигезендә аларга бүлеп бирелгән финанслау лимиты чикләрендә төзелә. 2020 елда «Безнең ишегалды» программасы буенча 1 091 ишегалды территориясе төзекләндерелде. Бу эшкә 8,0 млрд сум күләмендә акча бүлеп бирелде.

**Сәламәтлек саклау**

***12. Коронавирус йогышлы чире белән авырган гражданнарны дәвалап бетерү (реабилитацияләү) буенча күрелә торган чаралар турында. Әлеге мәсьәләне норматив җайга салу планлаштырыламы?***

Татарстан Республикасында авыруларга медицина реабилитациясе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1239 номерлы карары нигезендә мәҗбүри медицина иминиятләштерүе (алга таба - ММИ) база программасы кысаларында уздырыла.

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина территориаль иминиятләштерүе программасын эшләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан, COVID-19 йогышлы авыруы белән чирләгән авыруларның медицина реабилитациясе узуын исәпкә алып, 2021 елга билгеләнгән планлы бирем һәм финанс чаралары яңадан бүленде, аның нәтиҗәләре буенча республиканың әлеге юнәлештә эшләүче медицина оешмаларына 34,2 млн сум бүлеп бирелде, ул 1 954 авыруны хастаханәгә салу мөмкинлеге бирәчәк.

I квартал, 2021 елның 6 һәм 9 айлары йомгаклары буенча әлеге мәсьәлә буенча республика медицина оешмалары эшенә планлы мониторинг үткәрелде һәм кирәк булган очракта Комиссия утырышында карап тикшерү өчен тәкъдимнәр кертеләчәк.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры санаторий-курорт учреждениеләрендә (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) дәвалап бетерү (реабилитацияләү) турында» 2011 елның 28 мартындагы 233 номерлы карарына стационарда дәваланганнан соң Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән санаторий-курорт учреждениеләрендә дәвалап бетерелергә (реабилитацияләү узарга) тиешле эшләүче гражданнар исемлегенә өстәмәләр кертү өлешендә үзгәрешләр кертү әзерләнә.

***13. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Мине тап» сервисы үрнәгендә (Мәскәү шәһәре) медицина учреждениесендә гражданның кайда булуын күрсәтүче хезмәт яисә онлайн-сервис булдыру перспективалары турында.***

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау тармагын мәгълүматлаштыру чаралары «Сәламәтлек саклау» милли проекты кысаларында гамәлгә ашырыла. Хәзерге вакытта федераль таләпләр нигезендә төбәк медицина мәгълүмат системалары эшләп бетерелә. Әлеге системаларны гамәлгә ашыру срогы – 2024 елга кадәр. Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару теге яки бу медицина оешмасында гражданның кайда булуы турында мәгълүмат булган онлайн система төзергә мөмкинлек бирәчәк.

***14. Дарулар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар (нинди күләмдә) бүлеп бирү перспективалары турында:***

***– сирәк (орфан) авырулары булган гражданнар;***

***– онкологик авырулар, шикәр диабеты, бронхиаль астма авырулары ачыклану артуга бәйле рәвештә төбәк дәрәҗәсендә ташламалардан файдаланучылар.***

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16, 83 статьялары нигезендә орфан авырулары булган гражданнарны дарулар белән тәэмин итүгә чыгымнарны каплау Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә тапшырылды.

2021 елга Татарстан Республикасы бюджетында гражданнарның аерым категорияләрен дарулар һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр белән бушлай тәэмин итүгә чыгымнар каралган, гомуми суммасы – 1 090,04 млн сум (2020 ел белән чагыштырганда 104,0 %), шул исәптән:

гражданның гомер озынлыгын киметүгә яки инвалидлыкка китерә торган тормышына куркыныч янаучы һәм хроник сирәк (орфан) авырулары булган гражданнарга – 168,1 млн сум (2020 ел белән чагыштырганда 104,0 %);

төбәк дәрәҗәсендә җаваплылыкта булган ташламага ия булучыларга – 921,9 млн сум (2020 ел белән чагыштырганда 104,0 %).

Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 5 гыйнварындагы 16 номерлы Указы нигезендә тормышына куркыныч янаучы һәм хроник сирәк (орфан) авырулары булган балаларга ярдәм итү буенча «Яхшылык әйләнәсе» фонды төзелде. Ел саен

фондка федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән субсидияләр рәвешендә грантлар биреләчәк.

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә салым чорында 5 млн сумнан артык кереме булган физик затларга салым салу өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 ноябрендәге 372-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 5 млн сумнан артык кереме булган физик затларга салым күләме 15% ка кадәр арттырылды.

2020 елның 25 июнендә Иҗтимагый палата әгъзалары белән булган очрашу нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның 2020 елның 1 сентябрендәге Пр-1395 номерлы йөкләмәсе нигезендә бюджетның югарыда күрсәтелгән өстәмә керемнәрен, кыйммәтле дарулар сатып алуны да кертеп, сирәк очрый торган (орфан) авырулары булган балаларны дәвалауга тоту планлаштырыла.

***15. Белем бирү оешмаларында (шул исәптән муниципаль) торып укымаучы сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү турындагы мәсьәләне карау планлаштырыла микән?***

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру мәсьәләләре җирле үзидарә органнары компетенциясенә керә һәм тиешле карар йә муниципаль берәмлек башкарма комитеты карары нигезендә регламентлаштырыла.

Мәктәпләрдә ташламалы туклану җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылган муниципаль берәмлек башкарма комитеты карары яисә боерыгы нигезендә билгеләнгән гаилә категорияләренә керүче укучыларга бирелә.

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашату мәсьәләсе хәзерге вакытта Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) белән берлектә эшләнә.

***16. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында республикада гамәлгә ашырыла торган балалар һәм яшьләр өчен ял итү һәм сәламәтләндерү программалары турында, смена юнәлешләре күрсәтелгән һәм Портал аша юлламалар сатып алуга гаризалар формалаштыру мөмкинлеге булган бүлек булдыру планлаштырыламы?***

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсен цифрлаштыру кысаларында һәм халыкка Татарстандагы балалар лагерьлары турында мәгълүмат бирү максатларында пилот проект – «Татарстан Республикасы балалар лагерьлары. Сезнең балагыз өчен онытылмас каникуллар һәм тәэсирләр» (https://dol.tatar.ru) онлайн-сервисы эшләп килә, биредә 100 балалар өчен ял итү һәм сәламәтләндерү учреждениесе (шул исәптән барлык республика һәм муниципаль) тәкъдим ителгән. Аларның һәркайсы буенча эш режимы һәм урнашу шартлары турында мәгълүмат карау мөмкин. Сервис ярдәмендә мәгълүматны өйрәнергә, инфраструктурасына һәм гамәлгә ашырыла торган программаларына карап, кызыксындырган лагерьны сайлап алу мөмкинлеге тудырыла.

Броньлау һәм турыдан-туры юлламалар сатып алу өлешендә онлайн-сервис функционалын киңәйтү планлаштырыла.

Республикада гамәлгә ашырыла торган балалар һәм яшьләр өчен ял итү һәм сәламәтләндерү программалары турында мөстәкыйль онлайн-сервис булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мондый бүлек булдыру планлаштырылмый.

**Социаль сәясәт, гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары**

***17. Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре урынына акчалата компенсация бирү мөмкинлеге турында.***

Республикада буш җир кишәрлекләре җитмәү һәм аларда транспорт, инженерлык инфраструктурасы төзүгә бәйле зур финанс чыгымнары таләп ителүгә бәйле рәвештә, өч һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләргә аларның ризалыгы белән җир кишәрлекләренә алмашка торак шартларын яхшыртуның башка социаль чараларын тәкъдим итү буенча Россия Федерациясе төбәкләренең иң уңышлы тәҗрибәләренә анализ ясалды.

Анализ нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуда мохтаҗ булуы критерийларын (кимендә 5 ел Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче), күпбалалы гаиләнең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын раслаучы документларга таләпләрне исәпкә алып, шулай ук җир кишәрлеге бирүгә срокны бетерүне күздә тотучы (бер ел дәвамында), Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү буенча тиешле тәкъдимнәр әзерләнде.

***18. Балаларны яследә урыннар белән тәэмин итү проблемасын һәм мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә кадрлар кытлыгын хәл итү сроклары турында.***

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган программалар кысаларында 2020 елда республикада 27 балалар бакчасы төзелде, шул исәптән:

«Демография» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында – 5 030 урынга исәпләнгән 22 балалар бакчасы – Казан шәһәрендә – 9, Чаллыда – 3, Түбән Камада – 2, шулай ук Биектау, Зеленодольск, Арча, Буа, Лаеш, Питрәч, Саба, Тукай муниципаль районнарында берәр балалар бакчасы (шулардан 2 525 урынга исәпләнгән бакчалар бакчалары – 1,5 тән 3 яшькә кадәрге балалар өчен) төзелде;

җитәкчеләрнең аерым йөкләмәләре буенча һәм инвесторлар акчалары хисабыннан – Казан шәһәрендә, шулай ук Арча, Әлки, Зеленодольск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарында330 урынга исәпләнгән 5 балалар бакчасы.

Республика буенча мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге уртача 94,4% тәшкил итә, шул исәптән 98% – 3 яшьтән өлкәнрәк балалар өчен. 36 муниципаль берәмлектә мәктәпкәчә белем алу өчен 100 процент мөмкинлекләр тәэмин ителә.

2021 елда республикада 2 390 урынга исәпләнгән 13 балалар бакчасы төзү планлаштырыла. Эшләп килүче балалар бакчаларында төркемнәрне үзгәртеп кору юлы белән өстәмә рәвештә 1 390 ясле урыны булдырылачак.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә 350 белгечкә ихтыяҗ бар. Тармакны педагогик кадрлар белән тәэмин итү максатларында чыгарылыш сыйныф укучыларын максатчан әзерләү һәм эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү нигезендә абитуриентлар кабул итүне оештырганда югары һәм урта белем бирү мәгариф оешмалары белән хезмәттәшлек гамәлгә ашырыла.

***19. Пенсиягә өстәмә буларак федераль социаль түләүләр күләмен билгеләү өчен Россия Федерациясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләме нигезендә Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумын арттыру мәсьәләсе республика Хөкүмәте тарафыннан тикшереләме?***

2021 елга кадәр ел саен Татарстан Республикасы законнары нигезендә пенсиягә өстәмә буларак федераль социаль түләүләр күләмен билгеләү өчен республикада пенсионерның яшәү минимумы күләме билгеләнеп килде. Законнар «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 134-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә кабул ителде.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе субъектларында пенсиягә өстәмә буларак социаль түләүләр билгеләү максатларында пенсионерның яшәү минимумы күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 июлендәге 975 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнде.

2020 елның 28 сентябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2021 елга пенсионерның яшәү минимумы 8 423 сум күләмендә билгеләнде.

2021 елның 1 гыйнварыннан «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы Федераль закон) үз көченә керде, аның нигезендә шул исәптән, 134-ФЗ номерлы Федераль законга түбәндәге үзгәрешләр кертелде: 2021 елдан яшәү минимумы кулланучылар кәрзине бәясеннән түгел, ә узган ел өчен җан башына уртача медиана кеременнән чыгып исәпләнелә.

473-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләп үтелгәнчә, җан башына уртача медиана кереме буенча халыкның яртысында җан башына туры килә торган уртача кереме түбәнрәк, яртысында – югарырак. Шул ук вакытта киләсе 5 елга яшәү минимумы җан башына уртача медиана кеременең 44,2% күләмендә теркәлгән. 2019 елда Россия Федерациясе буенча медиана кереме – 26 365,3 сум, ягъни Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы 11 653 сум тәшкил итәчәк.

Шул ук вакытта киләсе елга тулаем Россия Федерациясе буенча халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләме, шул исәптән 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган пенсиягә өстәмә буларак федераль социаль түләүләрне билгеләү өчен дә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчъяклы комиссия фикерен исәпкә алып, тулаем Россия Федерациясе буенча шул ук елга җан башына яшәү минимумы

күләменнән чыгып билгеләнергә тиеш, шул ук вакытта тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләмен билгеләнергә тиеш.

Төбәктә яшәү минимумы күләме киләсе елга субъектлар тарафыннан җан башына федераль яшәү минимумы күләме нисбәтендә, әмма Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган һәр төбәк өчен махсус эшләнгән коэффициентларны исәпкә алып билгеләнә. Россия Федерациясе субъектында билгеләнә торган пенсионерның яшәү минимумы күләме, шул исәптән 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган пенсиягә өстәмә буларак социаль түләүләрне билгеләү максатларында кулланыла.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, субъектларда яшәү минимумы күләме арту көтелә, әмма бу үсеш 4 ел дәвамында (2025 елга кадәр) этаплап барачак.

Шул ук вакытта 2019 елның 17 июнендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 147-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2021 елда Россия Федерациясе субъектында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләме Россия Федерациясе субъекты тарафыннан Россия Федерациясе субъектында 2020 елның II кварталына җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләменнән дә ким булмаган күләмдә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 10 февралендәге 69 номерлы карары нигезендә җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы 9 955 сум, хезмәткә сәләтле халык өчен – 10 622 сум, пенсионерлар өчен – 8 423 сум, балалар өчен 9 995 сум күләмендә расланган.

Пенсионерның расланган яшәү минимумы күләме «Пенсиягә өстәмә буларак федераль социаль түләүләр күләмен билгеләү өчен 2021 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры килә.

2020 елның II кварталы белән чагыштырганда җан башына яшәү минимумы күләме 3% ка (287 сумга), хезмәткә сәләтле халык өчен – 3% ка (328 сумга), пенсионерлар өчен – 7% ка (534 сумга), балалар өчен – 3% ка (282 сумга) арткан.

***20. Хәрәкәтләре чикле кешеләр өчен уңайлы мохит тудыру максатларында җәмәгать урыннарын төзекләндергәндә гражданнарның фикерләрен исәпкә алу механизмы турында.***

Тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә объектлардан файдалану мөмкинлекләрен арттыру өчен «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларга карата дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында 2011 елдан Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең «Уңайлы мохит» дәүләт программасын гамәлгә ашыруда катнаша.

Төбәк ярдәме программасын тормышка ашыру өчен 10 ел эчендә инвалидларның объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алуын арттыруга федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан 2,7 млрд сум акча тотылды, барлыгы 921 объект (шул исәптән 399 – мәгариф, 184 – сәламәтлек саклау, 143 – социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү, 93 – мәдәният, 92 –

физкультура һәм спорт өлкәсендә, шулай ук 10 метрополитен станциясе) инвалидлар өчен җайлаштырылды.

Ярдәмче программада инвалидларның барлык категорияләре мәнфәгатьләре дә исәпкә алынды, объектларда терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган, ишетү һәм күрү сәләтен югалткан инвалидларның әлеге объекттан һәм анда күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын булдыру чаралары күздә тотыла. Казан метрополитенының гамәлдәге станцияләрен җайлаштыру, коляскадагы инвалидлар өчен җәяүлеләр өчен юл чыгу урыннарын һәм торак фондын төзекләндерү эшләре башкарылды. Реконструкция коляскадагы инвалидлар яшәгән торак йортларның подъездларына (1 710 подъезд) кагылды. Шулай ук күз буенча инвалидлар күпләп яшәгән торак йортлар да җайлаштырылды (2011 елда – 2 йорт, 2012 елда – 28 йорт).

Соңгы елларда республикада хәрәкәтләре чикле халык төркемнәренең социаль инфраструктура объектларыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен күп эшләр башкарылды. Эшләр универсаль дизайн принцибына таянып башкарылды, ә архитектура һәм тарихи әһәмияткә ия объектлар акыл нигезендә эшләнгән җайланма позициясеннән чыгып төзекләндерелде. Оешмаларда инвалидлар өчен җайлаштыру эшләрен башкарганда комплексллы алымнар кулланылды, инвалидларның үзләрен, учреждение белгечләрен һәм, тулаем, халыкны объекттан файдалану мөмкинлеге бирүче элементлардан дөрес кулланырга өйрәттеләр.

Хәрәкәтләре чикле халык төркемнәренең объектлардан файдалану мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү максатларында «Җайлаштырылган объектлар картасы» проекты гамәлгә ашырылды (http://karta.tatar.ru), ул мөмкинлекләре чикле кешеләргә социаль инфраструктура объектларыннан файдалану мөмкинлеге турында дөрес мәгълүмат алырга һәм төрле учреждениеләргә бару маршрутларын планлаштырырга мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта күрсәтелгән ресурста 6 725 объект турында мәгълүмат бар.

«Ачык Татарстан» проекты кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында «Халык контроле» проекты гамәлгә ашырыла, аның «Уңайлы мохит» бүлегендә кулланучы теләсә кайсы объекттан файдалану мөмкинлеге турында хәбәрнамә калдырырга һәм дәүләт яисә муниципаль хакимият органнары кабул иткән карарның сыйфатын бәяләргә мөмкинлек бирә. Республика халкының барлык мөрәҗәгатьләре дә җентекләп тикшерелә һәм һәр очрак буенча оператив карарлар кабул ителә. Проект гамәлгә ашырылган чорда 2 057 мөрәҗәгать кабул ителде, 1 690 гариза уңай хәл ителде, 186 мөрәҗәгать буенча эшләр үткәрү планлаштырыла, 175 гариза нигезле рәвештә кире кагылды; 6 гариза буенча эш дәвам ителә.

**Мәгариф, мәдәният**

***21. Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү эше турында.***

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү, үстерү һәм аларның кулланылышын арттыру өчен шартлар тудыру максатларында республикада «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм

башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары).

Дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче халыкларның телләрен популярлаштыру максатында ел саен сәләтле балалар һәм яшьләр белән 30дан артык чара үткәрелә: иншалар конкурслары, иҗади конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләр, туган телләр буенча олимпиадалар, барлыгы 40 меңнән артык кеше катнаша. 20 дән артык чара милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне популярлаштыруга, шул исәптән татар телен саклауга да юнәлтелгән.

Иң зур чаралар булып түбәндәгеләр тора: татар һәм рус телләре буенча халыкара олимпиадалар, «Илһам» яшь язучылар бөтенроссия конкурсы, балалар театр коллективлары фестивале, туган телләр буенча төбәк олимпиадалары, Туган тел форумы, Туган тел көне һәм Рус теле көне, рус теле һәм татар теле буенча тоталь диктантлар, якшәмбе мәктәпләре укучылары фестивале һәм слеты, конференцияләр һәм түгәрәк өстәлләр, тел лагерьлары, милли спорт төрләре спартакиадасы, «Татар яшьләре көннәре» форумы, Татарстан халыклары ризыклары, «Идел акчарлагы» яшь әдәбиятчылар конкурсы, «Болгар-Туган тел» лагеры, «Төркиләр алтыны» бөтенроссия яшьләр форумы, балалар һәм яшьләр өчен «Сәләт» форумы, балалар һәм яшьләр өчен татар лидерлар мәктәбе һәм башкалар.

Әлеге мәсьәләгә системалы якын килү нәтиҗәсендә тулы бер чаралар комплексы булдырылды, ул Татарстан Республикасында яшәүче төрле халыклар вәкилләре арасында үзара аңлашуга һәм үзара хөрмәткә ирешүгә ярдәм итә.

Милли телләрне өйрәнү һәм үстерү буенча тәҗрибә алмашу һәм иң яхшы эш үрнәкләре белән уртаклашу максатында Башкортстан, Саха-Якутия, Хакасия, Марий Эл республикалары, Свердловск, Төмән, Ульяновск өлкәләре, Пермь крае делегацияләренең визитлары булды. Алар барышында Казан һәм Иннополис шәһәрләре, шулай ук Арча һәм Биектау муниципаль районнары белем бирү оешмаларында булып, мәгариф мәсьәләләре буенча мастер-класслар һәм түгәрәк өстәлләр үткәрелде.

Ел саен Россия Федерациясе субъектларында һәм чит илләрдә Татар мәгарифе көннәре үткәрелә, алар кысаларында Татарстан Республикасының әйдәүче укытучылары катнашында мастер-класслар һәм түгәрәк өстәлләр оештырыла, татар телен өйрәнү мәсьәләсе буенча методик консультация бирелә.

Республика һәм Россия Федерациясе субъектларыннан татар балаларын татар теленә тирәнтен өйрәтү өчен, К(И)ФУ, Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты укытучылары тарафыннан татар теле дәресләре, мастер-класслар, тренинглар, танылган язучылар, эшлеклеләр, ММЧ вәкилләре, яшьләр оешмалары белән очрашулар, Татарстанның тарихи һәм истәлекле урыннары буенча экскурсияләр уздырыла.

Язма мәдәният һәйкәлләрен саклау һәм әлеге материаллардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе каршындагы «Китап» рус һәм татар халкының язма мирасы электрон мәгълүмат базасын төзү буенча эш алып барыла.

Экспедицияләр нәтиҗәсендә халыктан 950 берәмлек язма мирас ядкәре табылды һәм сатып алынды.

Елдан-ел «Рус теле буенча тотальь диктант» һәм «Татарча диктант» акцияләрендә катнашырга теләүчеләр саны арта бара. 2020 елда рус теле буенча тоталь диктантта 6 меңгә якын кеше катнашты, чара республиканың 91 мәйданчыгында узды. Татар теле буенча диктантта 22 чит илдән һәм Россия Федерациясенең 47 төбәгеннән 85 меңнән артык кеше катнашты, бөтен дөнья буйлап 1 410 мәйданчык файдаланылды. Татарстан Республикасында диктант 45 районда, 180 мәктәптә һәм Казан шәһәренең 26 җәмәгать мәйданчыгында узды.

Республика китапханәләре фондларын ел саен милли һәм туган якны өйрәнү турында китаплар һәм вакытлы матбугат белән, шул исәптән Татарстан Республикасы халыклары телләрендә, комплектлау кысаларында, 2020 елда 9 820 нөсхә документ (189 атама): татар телендә – 6 344 нөсхә, рус телендә – 2 544 нөсхә, чуваш телендә – 208 нөсхә, мари телендә – 391 нөсхә, башкорт телендә – 333 нөсхә сатып алынды.

***22. Мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген арттыру максатларында хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына ярдәм итү турында.***

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төп гомуми белем бирү программаларына дәүләт аккредитациясе нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү хосусый гомуми белем бирү оешмалары һәм шәхси эшкуарларга мәктәпкәчә белем бирү эшчәнлеге алып баруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алуга хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, хосусый гомуми белем бирү оешмалары һәм эшкуарлар исемлеге расланды.

Татарстан Республикасында 34 хосусый балалар бакчасы (24 дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмасы һәм мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы 10 шәхси эшкуар) эшли, аларда мәктәпкәчә яшьтәге 3 013 бала тәрбияләнә.

2020 елда хосусый балалар бакчаларында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 131,2 млн сум акча бүлеп бирелде. Субсидияләрне дәүләтнеке булмаган 15 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, мәктәпкәчә төркемнәре булган 6 шәхси мәктәп һәм 10 шәхси эшкуар алды.

2021 елга мәктәпкәчә белем бирүне оештыруга чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алуга 15 шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (балалар саны – 1 259) һәм 9 шәхси эшкуар (балалар саны – 811) гариза бирде.

Мәктәпкәчә белем бирү уку-укыту программалары гомуми үсеш, компенсацияләү, сәламәтләндерү яисә катнаш юнәлештә эшләүче балалар төркемнәрендә алып барыла, шулай ук ул балаларның яше буенча, ә аерым алганда, 3 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк яштәгеләргә аерыла. 3 яшькә кадәрге төркемнәргә 789 бала, 3 яшьтән өлкәнрәк төркемнәргә 1 281 бала йөри.

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәктәпкәчә белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланды. Нормативлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, шәхси эшкуарларга мәктәпкәчә белем бирүне оештыруга чыгымнарны каплауга бирелә торган субсидия күләме 2021 елда 87,7 млн сум тәшкил итәчәк.

***23. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм Татарстан Республикасының бер-берсенә якын урнашкан муниципаль районнары арасында гомуми белем бирү оешмалары укучыларының истәлекле урыннарга, музей-тыюлыкларга һәм музейларга күмәк сәфәрләрен оештыру өчен мәктәп автобусларыннан файдалану мәсьәләсен карап тикшерү турында.***

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы муниципаль районнарында гомуми белем бирү оешмалары укучыларының күмәк сәфәрләрен, шул исәптән мәдәни-массакүләм, спорт һәм башка чараларда катнашу өчен оештыруда мәктәп автобуслары актив кулланыла. 2020 ел нәтиҗәләре буенча 1 370 мәктәп төркеменә шундый сәфәрләр оештырылды.

«Россия мәгариф академиясенең Мәгарифкә идарә институты» ФДБКБУ тарафыннан мәктәп автобусларыннан файдалану мөмкинлекләрен арттыру максатларында «Белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру турында» методик тәкъдимнәр проекты эшләнде, ул мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларын социаль өлкә объектларына алып бару өчен транспорт белән тәэмин итү, шул исәптән мәктәптән тыш эшчәнлекне оештыру өчен мәктәп автобусларыннан файдалану мөмкинлеген бирәчәк.

Хәзерге вакытта методик тәкъдимнәр проекты Россия Федерациясе субъектлары белән җәмәгатьчелек фикер алышуы этабында. Проектка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына 2021 елның февралендә җибәрелде.

***24. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының өстәмә белем бирү оешмаларын, шулай ук махсуслаштырылган мәгариф оешмаларын (кадетлар өчен интернат-мәктәпләр, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен интернат-мәктәпләр) капиталь төзекләндерү перспективалары турында.***

Мәгариф оешмалары биналарын төзекләндерү эшләре Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын капиталь төзекләндерү программасы кысаларында (алга таба – программа) гамәлгә ашырыла. Шулай ук программа кысаларында махсус атамасы

булган (кадетлар) һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен дәүләт гомуми белем бирү оешмалары төзекләндерелә.

2020 елда Советлар Союзы Герое Илдар Мәннанов исемендәге 82 номерлы кадет мәктәбенә һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен 87 номерлы мәктәпкә (Чаллы шәһәре), шулай ук Казан шәһәренең сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен 172 номерлы мәктәбенә 274,0 млн сумлык капиталь ремонт ясалды.

Моннан тыш, Зәй, Лениногорск, Мамадыш, Саба, Спас муниципаль районнарында балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының 5 бинасында капиталь ремонт үткәрелде. Бу максатларга бүлеп бирелгән акчаларның гомуми суммасы 50,76 млн сум тәшкил итте, шуларның Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән – 43,8 млн сум, җирле бюджетлар исәбеннән – 6,96 млн сум.

2021 елда сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларының 9 бинасын ремонтлау планлаштырыла.

***25. Утыз ел элек төзелгән мәктәпләргә, аларда ашханәләр яки спорт заллары урнаштыру өчен янкормалар төзү мөмкинлеге турында.***

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы линиясе буенча «Мәгариф» һәм «Демография» илкүләм проектларын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджеттан уртак финанслау нигезендә гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төзелә. Әлеге илкүләм проектлар нигезендә гамәлдә булган мәгариф оешмалары биналарына янкормалар төзү каралмаган.

Гамәлгә ашырыла торган программалар кысаларында һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җыелма сметасында мәгариф оешмалары биналарына янкормалар төзү өчен башка акчалар шулай ук каралмаган.

***26. Шәһәр мәктәпләрендә спорт заллары төзү яисә аларны капиталь төзекләндерү максатларында аерым дәүләт программасы (ярдәмче программа) эшләү перспективалары турында.***

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, гомуми белем бирү оешмалары, балаларга өстәмә белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары (шул исәптән тулай тораклар), фәнни оешмалар биналарын ремонтлауга һәм төзүгә юнәлдерелгән чаралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары белән расланган «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү» дәүләт программасының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасына (алга таба – ярдәмче программа) кертелгән. Югарыда күрсәтелгән ярдәмче программада авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларын ремонтлауны үз өченә алган чаралар каралган.

2014–2020 елларда авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шулай ук үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балалар һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими һәм массакүләм шөгыльләнүгә

җәлеп итү максатларында гомуми белем бирү оешмаларында 123 спорт залы төзекләндерелде.

2021–2023 елларда авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында 6 спорт залын ремонтлау планлаштырыла. Бу максатларга 7,3 млн сум каралган, шул исәптән федераль бюджет чаралары исәбеннән – 5,9 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән – 1,4 млн сум.

***27. Мәктәп яны территорияләрен төзекләндерү һәм камилләштерүгә юнәлтелгән «Мәктәп ишегалды» республика программасын булдыру мөмкинлеге турында.***

Татарстан Республикасында мәгариф объектларын инфраструктура ягыннан үстерүгә зур игътибар бирелә. Ел саен федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән муниципаль берәмлекләрдә мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзелә. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән мәгариф объектларын, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары биналарын капиталь төзекләндерү программасы гамәлгә ашырыла, аның кысаларында түбәләрне, фасадны, керү урыннарын, санитар узелларны, инженерлык системаларын ремонтлау, тәрәзә һәм ишек блокларын алыштыру, террорчылыкка каршы һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, хәрәкәтләре чикле кешеләрнең биналарда хәрәкәт итүе өчен мөмкинлекләрне арттыру буенча беренчел әһәмияттәге эшләр башкарыла. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары белән расланган «2019–2023 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы нигезендә ел саен универсаль спорт мәйданчыклары, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары территориясендә төзелә. Мәктәп яны территорияләре инфраструктурасын төзекләндерү һәм камилләштерү эшләре, кирәк булганда, муниципаль берәмлекләр һәм инвесторлар акчалары исәбеннән башкарыла.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми белем бирү оешмалары территорияләрен комплекслы төзекләндерү чараларын үткәрүгә финанс ихтыяҗын билгеләү буенча аналитик эш алып барыла.

***28. Республиканың һәр районында яшьләр үзәкләре төзү максатчан программасын кабул итү мөмкинлеге турында.***

Дәүләт яшьләр сәясәте объектларын реновацияләү максатларында түбәндәге объектларда төзекләндерю эшләре башкарылды:

153 яшүсмерләр клубында (2015 елдан башлап), шул исәптән 2020 елда – 16 яшүсмерләр клубында (биналарны капиталь төзекләндерү һәм яшүсмерләр клубларының матди базасын ныгыту программасы буенча);

10 яшьләр үзәгендә (2018 елдан башлап), шул исәптән 2020 елда – 5 яшьләр үзәгендә (биналарны капиталь төзекләндерү программасы буенча, территорияне төзекләндерү һәм яшьләр үзәкләренең матди базасын ныгыту);

23 балаларны савыктыру лагеренда (2019 елдан башлап), шул исәптән 2020 елда – 11 балаларны савыктыру лагеренда («Җәй-балаларга» балаларны савыктыру лагерьларының матди-техник базасын капиталь төзекләндерү, реконструкцияләү, төзү һәм яңарту программасы буенча).

2021 елда 11 яшүсмерләр клубын, 4 яшьләр үзәген, 9 балаларны савыктыру лагерен реновацияләү планлаштырыла, моңа 1 195,0 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Хәзерге вакытта яшьләр үзәкләре төзү ихтыяҗы булган 17 муниципаль берәмлектән торган исемлек формалаштырылды. Әлеге максатларга якынча 3,06 млрд сум акча кирәк булачак (финанслау чыганагы билгеләнмәгән).

***29. Татарстан Республикасында балалар техник иҗаты челтәрен үстерү турында.***

Татарстан Республикасының өстәмә белем бирү өлкәсендә техник иҗат өстенлекле юнәлеш булып тора. Республикада 2012 елдан техник юнәлештәге өлкәдә балаларга өстәмә белем бирү инфраструктурасын үстерү, эшчеләр һәм инженерлык белгечлекләрен популярлаштыру буенча эзлекле рәвештә эш алып барыла. Шушы вакыт эчендә республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә түбәндәгеләр оештырылды һәм уңышлы эшли:

- техник иҗат буенча 58 база мәйданчыгы;
- робототехника буенча 53 база мәйданчыгы;
- һөнәри юнәлеш буенча «Авиация иле» дигән 8 база мәйданчыгы;
- балалар сәнәгать робототехникасы буенча 9 муниципаль терәк үзәк;
- 139 мәктәптә фәнни-техник иҗат берләшмәләре.

Федераль грантлар кысаларында түбәндәгеләр булдырылды:

- JuniorSkills компетенцияләре буенча 9 база мәйданчыгы (2017 елда);
- техник иҗатны (инженерлык лабораторияләрен) үстерү буенча заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән 9 терәк муниципаль үзәк (2016 елда).

Республикада Яр Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләрендә өч «Кванториум» балалар технопаркы эшләп килә, аларда 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге 2 570 бала икътисадның реаль секторы җайланмаларында инженерлык фәннәре буенча күнекмәләр ала.

2020 елның сентябреннән Чаллы шәһәрендә «Кванториум» балалар технопаркы» коммерциячел булмаган автоном базасында «Кванториум» мобиль технопаркы үз эшен башлап җибәрде, ул Әгерҗе, Актаныш, Зәй, Менделеевск, Минзәлә һәм Сарман муниципаль районнарында 1 038 балага өстәмә белем бирү хезмәтләрен күрсәтә.

Интеллектуаль, индустриаль һәм бизнес-партнерлар белән үзара челтәр хезмәттәшлеге кысаларында Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Н.Туполев исемендәге Казан фәнни-тикшеренү техник университеты-Казан авиация институты, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятие, «Казан ачык талантлар университеты 2.0» коммерциячел булмаган автоном оешмасы, «Казан технологияләр һәм дизайн колледжы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе, «Татарстан Республикасының Уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы, «Иннополис университеты»

коммерциячел булмаган автоном югары белем бирү оешмасы һәм башка оешмалар белән килешүләр төзелде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, шулай ук «Казан ачык талантлар университеты 2.0» коммерциячел булмаган автоном оешмасының үзара масштаблы челтәр хезмәттәшлеге проекты кысаларында 2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасында техник иҗатны үстерү буенча гамәлләрнең ведомствоара планы (юл картасы) гамәлгә ашырыла.

Сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү һәм һәркем өчен өстәмә белем бирүдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максаты белән ел саен республикада техник иҗатка багышланган 70тән артык чара үткәрелә. Алар турында мәгълүмат Татарстан Республикасының олимпиадалар, интеллектуаль, иҗади конкурслар, мастер-класслар һәм чаралар буенча «ПАНОРАМА» бердәм мәгълүмат-конкурс платформасында (https://panorama.tatar/) (алга таба – «ПАНОРАМА») урнаштырыла.

«ПАНОРАМА» – ул балалар, ата-аналар, педагоглар һәм конкурсларны оештыручылар өчен мәгълүмати ресурс. Платформа онлайн-заявка бирү, конкурс материалларын беркетү һ.б. мөмкинлеген күздә тота, кулланучыларга методик материалларның, норматив базаның киң исемлегеннән, методик лабораториядән файдалану мөмкинлеген бирә. Яңалыклар лентасында чаралар анонслары, конкурслар йомгаклары урнаштырыла. Порталның эше модель үзәкнең профильле бүлекләре эшчәнлеге нигезендә тәэмин ителә.

Техник иҗат буенча иң масштаблы чаралар түбәндәгеләр:

– «Иннополис университеты» коммерциячел булмаган автоном югары белем бирү оешмасы белән берлектә үткәрелә торган республика робототехника олимпиадасы;

– «XXI гасыр Кулибиннары» республика олимпиадасы, Казан (Идел буе) федераль университеты һәм «Татарстан Республикасының Уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасының республика советы белән бергә үткәрелә;

– Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең балалар техник иҗатына ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү буенча республика фестивале;

– 5–7 нче сыйныфлар мәктәп укучылары өчен НТИ.Junior дигән түгәрәк хәрәкәте олимпиадасы һ.б.

Техник иҗат буенча республика конкурс чараларында җиңүчеләр һәм аның призерлары Татарстан Республикасын Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге чараларда тәкъдим итәргә лаеклы.

***30. Республика һәм җирле бюджетлардан финанслана торган мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балалар өчен өстәмә белем бирү челтәрен (түгәрәкләрне һәм секцияләрне) арттыру мөмкинлеге турында.***

2020 елда балаларга өстәмә белем бирүнең 12 011 берләшмәсе (түгәрәкләр һәм секцияләр) оештырылды, шул исәптән түбәндәге юнәлешләр буенча: сәнгать иҗаты

– 5 318, спорт – 1 728, техник һәм спорт-техник – 1 290, туристлык-туган якны өйрәнү – 966, экологик-биологик – 575, культурологик – 56, башкалар – 2 078. Түгәрәкләргә һәм секцияләргә йөрүче балалар саны 186 005 кеше тәшкил итте.

2020 елда Нурлат шәһәрендә «Киләчәк» балалар иҗат үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе ачылды, аның төзелешенә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 121,0 млн сум акча җибәрелде.

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы белән килештереп, белем бирү оешмалары челтәрен үстерү һәм халыкны аларның хезмәтләре белән тәэмин итү буенча 2016 елның 4 маендагы АК-15/02вн номерлы методик тәкъдимнамәләр (алга таба – Методик тәкъдимнамәләр) расланды, ул Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормаларыннан чыгып, халыкның яшь составын һәм тыгызлыгын, транспорт инфраструктурасын һәм халыкның мәгариф өлкәсе хезмәт күрсәтүләреннән файдалану мөмкинлегенә һәм алар белән тәэмин ителешенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә алып, мәгариф өлкәсе оешмаларын, шул исәптән авыл җирлегендә, урнаштыру буенча таләпләрне үз эченә ала.

Методик тәкъдимнамәләр нигезендә сәнгать өлкәсендә һөнәри белем алганга кадәр өстәмә программаларны гамәлгә ашыручы балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында ихтыяҗны исәпләгәндә, халык саны 10 меңнән артык булган торак пунктларда балалар сәнгать мәктәпләре саны гомуми белем бирү оешмаларындагы 1 – 9 сыйныф укучыларының кимендә 12 процентын тиешле программалар белән колачлаудан чыгып билгеләнә. Шулай ук Методик тәкъдимнамәләрдә өстәмә белем бирү учреждениеләренең территориаль һәм транспорттан файдалана алу критерийлары, шул исәптән белем алучының яшәү урыныннан өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы оешмага кадәр бару юлының вакыты билгеләнде.

Татарстан Республикасында мәдәният өлкәсендә – 103 балалар сәнгать мәктәбе, мәгариф өлкәсендә 40 балалар сәнгать мәктәбе эшли, аларда балаларга һөнәри белем алганга кадәрге программалар буенча да, гомуми үстерү программалары буенча да белем бирелә. 2020/2021 уку елында гомуми белем бирү оешмаларының 1–9 сыйныф укучыларының саны – 431 328 кеше, балалар сәнгать мәктәпләрендә укучылар саны 60 518 кеше тәшкил итте, тиешле программалар белән колачлау 14,03 процент тәшкил итә. Шулай итеп, хәзерге вакытта республика халкы өчен балалар сәнгать мәктәпләреннән норматив файдалану мөмкинлеге тәэмин ителде.

Һәр белем бирү учреждениесе турында (шул исәптән аның урнашу урыны, учреждениегә укырга керү һәм анда уку тәртибе һәм шартлары, дәресләр расписаниесе, элемтәгә керү өчен мәгълүматлар турында) мәгълүмат «Интернет» челтәрендә https://edu.tatar.ru һәм http://navigator.rmc.tatar.tatar адреслары буенча Татарстан Республикасында Электрон мәгариф һәм «Татарстан Республикасының балаларга өстәмә белем бирү навигаторы» сайтларында урнаштырыла һәм алардан һәркем файдаланырга мөмкин.

«Татарстан Республикасының балаларга өстәмә белем бирү навигаторы» сайтында түбәндәгеләрне сайлау мөмкинлеге каралган:

– әзерләү юнәлешләре (техник, сәнгать, табигый-фәнни, физкультура-спорт, социаль-педагогик, туристлык-туган якны өйрәнү);

– программаның типлары (гомумүстерү, һөнәри белем алганга кадәрге, спорт әзерлеге);

– җайлаштырылган программалар (сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалид балалар өчен);

– программаны гамәлгә ашыру шартлары (түләүле, түләүсез);

– баланың яше (5 яшьтән 17 яшькә кадәр).

***31. Түбәндәгеләрнең хезмәт өчен түләү дәрәҗәсен арттыру перспективалары турында:***

- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ярдәмче персоналның;

- Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында азык-төлек блоклары һәм ашханә хезмәткәрләренең (җитештерү мөдире, пешекче, кухня хезмәткәрләре).

Белем бирү оешмаларында ярдәмче персоналның эш хакы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә нигезендә исәпләп чыгарыла. Әлеге нигезләмә нигезендә белгечләр гомумтармак вазыйфаларының база окладлары һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә. База окладына кызыксындыру характерындагы түләүләр һәм компенсация характерындагы түләүләр билгеләнә.

Азык-төлек блоклары һәм ашханәләр («пешекче», «җитештерү мөдире (шеф-повар)» һәм «ашханә мөдире» вазыйфалары) хезмәткәрләренә белем бирү оешмаларында эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә рәвештә 20 процент күләмендә өстәмә билгеләнә.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133 статьясындагы 3 өлеше нигезендә эш вакыты нормасын тулысынча үтәгән һәм хезмәт вазыйфаларын башкарган хезмәткәргә эш хакы хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән түбән түләнмәскә тиеш. «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2021 елның 1 гыйнварыннан хезмәт өчен түләүнең минималь күләме бер айга 12 792 сум тәшкил итә.

Әгәр дә эш вакытының айлык нормасын тулысынча эшләү шарты белән хезмәткәрнең айлык эш хакы дәрәҗәсе хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән минималь күләменә җитмәсә, эш бирүчеләр аны әлеге күләмгә кадәр җиткерүне тәэмин итә.

Республика гомуми белем бирү оешмаларында азык-төлек блоклары хезмәткәрләренең эш хакын арттыруга бәйле мәсьәлә аерым контрольдә тора.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан республика гомуми белем бирү оешмаларында азык-төлек блоклары хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге билгеләнә һәм финанс-икътисадый нигезләмәсе эшләнә.

Республиканың мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ярдәмче персоналның хезмәте өчен түләү системасына үзгәреш кертү бары мәгариф тармагы буенча гына аерым карала алмый, чөнки хезмәткәрләрнең әлеге категориясе (гомумтармак хезмәткәрләре) барлык тармакларда диярлек эшли, һәм, шуңа бәйле рәвештә, бу категория өчен хезмәт өчен түләү системасына үзгәреш кертү буенча карар системалы характерда булырга тиеш.

**Иҗтимагый иминлек**

***32. Республиканың су объектларында кешеләр иминлеген профилактикалау һәм тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.***

2020 елда су объектларында 118 вакыйга теркәлде, 94 кеше үлде (шул исәптән 10 бала), 64 кеше (шул исәптән 6 бала) коткарылды. Су объектларында һәлак булу белән бәйле һәлакәтләрнең төп сәбәпләре түбәндәгеләр: җиһазландырылмаган урыннарда (шул исәптән исерек хәлдә) су коену, сулыкка (сәламәтлеге начараю аркасында балык тоткан вакытта көймәдән, ярдан, пирстан) егылып төшү һәм боз астына китү. 2020 елда азсыешлы суднолар белән 3 авария теркәлде, алар аркасында 1 кеше һәлак булды, 13 кеше (шул исәптән 5 бала) коткарылды. 2012 елдан һәлак булучы кешеләр саны 2,1 тапкырга (198 кеше – 2012 елда, 94 – 2020 елда) кимеде.

Су объектларында кешеләр иминлеген профилактикалау һәм тәэмин итү максаты белән түбәндәге чаралар үткәрелә:

– 2021 ел башыннан контроль-күзәтчелек чаралары кысаларында Азсыешлы суднолар дәүләт инспекциясенең дәүләт инспекторлары тарафыннан 306 патруль торылды, патроль тору барышында 5 652 әңгәмә уздырылды (аңа 10 518 кеше җәлеп ителде). 2020 елда 1 998 патруль тору гамәлгә ашырылды, 32 696 әңгәмә уздырылды (аңа 78 468 кеше җәлеп ителде). Патруль тору маршрутлары балыкчыларның бозга массакүләм чыгу урыннарына максималь барудан чыгып эшләнде;

– профилактика чаралары барышында массакүләм мәгълүмат чараларында 129 чыгыш ясалды. Гомуми белем бирү оешмаларында 65 дәрес үткәрелде (2 199 бала җәлеп ителде). 2020 елда 1 155 чыгыш оештырылды, 1 006 дәрес үткәрелде (36 731 бала җәлеп ителде). Халыкка мәгълүмат бирүнең һәм хәбәр итүнең гомумроссия комплекслы системасы ярдәмендә кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка мәгълүмат бирү системасы аша су объектларында үз-үзеңне дөрес тоту темасына бер тәүлеккә 120 видеоролик трансляцияләү гамәлгә ашырыла;

– Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча координацияләү киңәшмәсенең уртак утырышының 2018 елның 19 апрелендәге ПР-95 номерлы беркетмәсе нигезендә барлык муниципаль берәмлекләрдә 2021 елга су объектларында кешеләр үлеме рискларын киметү планнары эшләнде һәм аңа төзәтмәләр кертелде;

– балыкчыларның бозга традицион чыга торган 101 урыны тикшерүдә тотыла һәм 4 боз кичүе эшли (Зеленодольск шәһәре – Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы (Зеленодольск районы). Казан шәһәре – Югары Ослан авылы (Югары Ослан районы), Соколка авылы (Мамадыш районы) – Яңа Закамский (Мамадыш районы),

Покровский авылы (Алабуга районы) – Красный Ключ поселогы (Түбән Кама районы));

– Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең «2020–2021 елларның кышкы чорында су объектларында Татарстан Республикасы халкының иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 21-20р номерлы боерыгы нигезендә 45 муниципаль берәмлектә 1 ноябрьдән 20 апрельгә кадәр 119 мобиль патруль төркеменең (532 кеше) эше оештырылды. Боз тоткан чор башланганнан алып, алар тарафыннан 6 243 патруль торылды, 17 623 әңгәмә уздырылды, 24 939 белешмә-истәлек һәм листовка таратылды, кешеләрнең һәм автотранспортның бозга чыгуын тыю турында 740 аншлаг куелды, 65 граждан административ җаваплылыкка тартылды (Административ хокук бозулар буенча Татарстан Республикасы кодексының «Боз калынлыгы 7 сантиметрдан кимрәк булганда су объектларының боз өстенә чыгу һәм (керү)» дигән 3.10 статьясындагы 2 нче өлеше буенча);

– яз көне боз эрегән чорда балыкчыларның бозга күпләп чыгу урыннары янында, һава мендәрендә йөри торган судноларны кулланып, 9 вакытлы коткару постын оештыру планлаштырыла.

Ел саен су коену сезоны алдыннан Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе тарафыннан, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән берлектә, куркынычсызлык айлыгы чорында һәм су коену сезоны тәмамланганга кадәр Татарстан Республикасының су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү чараларын активлаштыру турында боерык чыгарыла.

2021 елда Азсыешлы суднолар дәүләт инспекциясенең төп көчләре азсыешлы суднолардан, аларны вакытлыча куеп тору базаларыннан (корылмаларыннан), кичүләрдән, пляжлардан файдалануны күзәтү, шулай ук республика су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү һәм суда кешеләр ял итү өчен урыннарны җиһазландыру өлкәсендә өстенлекле бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

Пляжларны, азсыешлы судноларны вакытлыча куеп тору урыннары өчен базаларны (корылмаларны) техник тикшерү еллык тикшерүләр үткәрү планы нигезендә уздырыла.

Татарстан Республикасының су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү максатларында 2020 елда муниципаль берәмлекләр бюджетлары белән бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру барышында пляжларны карап тоту һәм коткару постлары белән җиһазландыру өчен 10 550,9 мең сум (Татарстан Республикасының 15 муниципаль берәмлегендә 23 коткару посты) акча бүлеп бирелде. 2021 елда әлеге максатлар өчен 14 718,8 мең сум күләмендә акча каралды. Хәзерге вакытта әлеге акча кысаларында Татарстан Республикасының 21 муниципаль берәмлегендә 31 коткару посты тотыла.

Республикада су объектларында иминлекне тәэмин итү өлешендә ике иҗтимагый оешма эшчәнлек алып бара: «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең суларда коткару җәмгыяте» җирле иҗтимагый оешмасы һәм «Татарстан Республикасының суларда коткару җәмгыяте» төбәк иҗтимагый оешмасы.

«Татарстан Республикасы Казан шәһәренең суларда коткару җәмгыяте» җирле иҗтимагый оешмасы әгъзалары тарафыннан ике төп бурыч үтәлә: халык белән профилактик эш алып бару һәм массакүләм спорт чараларын уздырганда су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү. Су коену чорларында «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең суларда коткару җәмгыяте» җирле иҗтимагый оешмасы хезмәткәрләре пляжларда, иҗтимагый коткару постларын оештырып, куркынычсызлыкны тәэмин итә. 14 муниципаль берәмлектә «Татарстан Республикасының суларда коткару җәмгыяте» төбәк иҗтимагый оешмасының укыган әгъзалары кизүе белән җиһазландырылган коткару постлары эше 2020 елның 1 июленнән 31 августына кадәр оештырылды. Халыкка мәгълүмат бирү өчен Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы сайтында «Суда ял итү», «Куркынычсыз балык тоту» бүлекчәләре булдырылды. Республиканың шәһәр округларында һәм барлык муниципаль районнарында «Татарстан Республикасының суларда коткару җәмгыяте» төбәк иҗтимагый оешмасы бүлекләре оештырылды, аларның әгъзаларының гомуми саны 463 кеше тәшкил итә. Алар арасында студентлар, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре, Азсыешлы суднолар дәүләт инспекциясенең штаттан тыш инспекторлары, азсыешлы суднолар хуҗалары, азсыешлы судноларны вакытлыча куеп тору базалары (урыннары) җитәкчеләре һәм авыл җирлекләрендә яшәүчеләр бар. Бүлекләрне йөзү чаралары һәм коткару чаралары белән җиһазландыру буенча эш алып барыла.

Татарстан Республикасы Куркычсызлык Советының һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча координацияләү киңәшмәсенең уртак утырышының 2018 елның 19 апрелендәге ПР-95в номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методик үзәгендә республиканың 42 муниципаль берәмлегеннән бирелгән заявкалар нигезендә Татарстан Республикасының суларда коткару җәмгыятенең 418 әгъзасы (шул исәптән 2018 елда – 196, 2019 елда – 127, 2020 елда – 95 коткаручы) «Матрос-коткаручы» программасы буенча укыды.

***33. Татарстан Республикасында, шул исәптән Казан шәһәрендә гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар турында.***

Гражданнарны җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү эшчәнлеге «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

Республика муниципаль берәмлекләре территориясендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә эчке эшләр органнарына ирекле халык дружиналары актив ярдәм күрсәтә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 апрель, б-702 нче боерыгы белән Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы төзелде. Республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә дә шундый ук штаблар булдырылды, аларның

башлыклары итеп башкарма комитетлар җитәкчеләре яки аларның урынбасарлары билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында халык дружиналарының (эшчәнлекне матди-техник яктан тәэмин итү, халык дружиначыларын шәхси иминләштерү, аларны матди кызыксындыру) эшен оештыруга ел саен 8 млн сумнан артык акча бүлеп бирү каралды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 август, 603 нче карары белән «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премиясе турында нигезләмә расланды (30 премия – 5әр мең сумнан, 10 премия – 20шәр мең сумнан, 3 премия 50шәр мең сумнан каралды).

2021 елның 1 гыйнварына Татарстанда гомуми саны 21 687 кешедән торган 1 463 халык дружинасы теркәлде, шул исәптән 204е – сәнәгать предприятиеләрендә һәм оешмаларда; 241е – мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау һәм спорт учреждениеләрендә, 1 018е – гражданнарның яшәү урыны буенча (317 ишегалды, 671 авыл, 30 – район үзәкләрендә).

Казан шәһәрендә 270 халык дружинасы эшли: предприятиеләрдә һәм оешмаларда – 50 (605 кеше), мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау һәм спорт учреждениеләрендә – 32 (609 кеше), гражданнарның яшәү урыны буенча – 188 (627 кеше).

2020 елда ишегалды дружиналары әгъзалары 1 132 рейд уздыруда катнашты, рейдлар вакытында алар, полициянең участок вәкаләтле вәкилләре белән берлектә, торак секторга профилактик тикшерү үткәрү кысаларында якынча 3,8 мең адрес буенча булды, 2 676 профилактик исәптә торучы затларны тикшерүдә катнашты. Дружиначылар мәгълүматы буенча 359 кеше исәпкә куелды. Алар ярдәмендә 102 җинаять ачылды, 1 571 административ хокук бозу очрагы туктатылды, шул исәптән Казан шәһәрендә 12 җинаять ачылды, 234 административ хокук бозу туктатылды.

2020 елда җәмәгать тәртибен саклауда барлыгы 50 493 халык дружиначысы катнашты (кабат җәлеп итүне исәпкә алып), шулардан офицерлар патрульлеге нарядлары составында – 13 104, полициянең участок вәкаләтле вәкилләре белән – 32 332, полициянең тышкы хезмәтләре нарядлары белән – 5 057. Халык алдында, иҗтимагый-сәяси, дини, мәдәни-тамаша һәм спорт чараларын үткәргәндә хокук тәртибен тәэмин итүдә халык дружиналарының 7 896 әгъзасы катнашты.

2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы территориясендә хокук саклау юнәлешендәге 1 209 яшьләр иҗтимагый берләшмәсе (917 мәктәп, 90 студентлар, 176 эшчеләр, 26 яшьләр) эшли, аларның саны 17 меңнән артык кеше (17 141) тәшкил итә. Аларның эшчәнлегенең координаторы булып «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тора. Күпчелек муниципаль берәмлекләрдә (Казан шәһәреннән, Әтнә, Саба һәм Чирмешән районнарыннан тыш) «Форпост» үзәгенең муниципаль структур бүлекчәләре төзелде.

2013 елдан Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә караган Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе

бүлеге каршындагы полициянең штаттан тыш хезмәткәрләре бүлекчәсе (300 кеше) эшли, аның төп бурычы – ЮХИДИ хезмәткәрләренә киң күләмле массакүләм чаралар үткәргәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү.

Юл хәрәкәте иминлеген профилактикалауда шулай ук 2005 елда оештырылган «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенә караган Татарстан республика ветераннар берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы актив катнаша. Хәзерге вакытта ул 564 кешене берләштерә.

Республикада «Хәрәкәтнең яшь инспекторы» дигән 1 346 отряд эшли, аларның әгъзалары булып 17 031 укучы тора. Отрядлар бурычларына мәктәп укучылары арасында Юл хәрәкәте кагыйдәләрен пропагандалау һәм юл-транспорт җәрәхәтләрен профилактикалау керә.

Татарстан территориясендә «Лиза Алерт» (Казан шәһәре), «Василиса» (Яр Чаллы шәһәре), «След» (Түбән Кама шәһәре), «Надежда» (Алабуга шәһәре), «Поисковый Центр» (Казан шәһәре) ирекләләр (волонтерлар) оешмалары эшчәнлек алып бара, алар хәбәрсез югалган кешеләрне, беренче чиратта, балаларны эзләү чараларын үткәргәндә хокук саклау органнарына булышлык күрсәтә. 2020 елда бу оешмаларның әгъзалары хәбәрсез югалган 176 кешенең кайда булуын билгеләүдә катнашты, алар ярдәмендә 107 кеше, шул исәптән 33 балигъ булмаганнар табылды.

### ***34. Татарстан Республикасында юлларда, шул исәптән индивидуаль мобильлек чаралары катнашында юл-транспорт һәлакәтләре санын һәм үлүчеләр санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.***

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм алар салган зыяннарны киметү чараларын тормышка ашыру турында» карары кабул ителә.

2019 елдан Россия территориясендә «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты гамәлгә ашырыла, аның төп бурычлары – юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү һәм юл-транспорт һәлакәтләрен концентрацияләү урыннары санын киметү. Проект Казан, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәр агломерацияләрендә гамәлгә ашырыла. Аны үтәү өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе (алга таба – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ) бүлекчәләренә 79 патруль автомобиле, юлларны һәм транспортны эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тикшерүдә тота торган 300дән артык махсус техник чара бирелде, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеге мәсьәләләрен яктырту өчен 4,2 млн сум акча бүлеп бирелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы карары белән «2013–2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы расланды, аның нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасына белем бирү оешмалары өчен гомуми суммасы 2,17 млн.сумга 20 мең яктылык кайтаручы җайланма һәм 2 җиһазлар комплексы кайтартылды.

Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән финанслана торган юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасының «2014–2025 елларга юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Аның гомуми финанслау күләме 22 519,8 млн сум, шул исәптән 2020 елда – 2 121,93 млн сум тәшкил итә (тулы күләмдә үзләштерелде).

2020 елда әлеге программаларны гамәлгә ашыру барышында:

– 34 светофор объекты, 70 км юл киртәсе, 14 км җәяүлеләр (рәшәткә) коймасы урнаштырылды;

– юл өслегенең 680 ясалма тигезсезлеге, 114 км юллар яктырткычы төзекләндерелде;

– 12 км тротуар төзелде;

– автомобиль юлларының 287 участогында инженерлык чаралары үткәрелде.

Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерү системаларын үстерү дәвам итә. 2020 елда тасвирнамәләре яхшыртылган 284 яңа стационар комплексы сатып алынды һәм файдалануга тапшырылды, алар дүрт хәрәкәт полосасында транспорт чаралары хәрәкәтенең мизгел эчендәге тизлеген дә, уртача тизлеген дә, ә 19 юл чатында – борылу һәм борылып кире юнәлештә хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозуларны теркәргә сәләтле.

Билгеле бер урнаштырылган урында, хәрәкәт барышында һәм стационар рәвештә транспорт чаралары хәрәкәте тизлеген үлчәргә мөмкинлек бирә торган 10 мобиль комплекс сатып алынды, юл-патруль хезмәтенең 40 автомобиле транспорт чараларын эзләү мәгълүматлары базалары буенча автомат режимда тикшерергә мөмкинлек бирә торган яңа мобиль комплекслар белән җиһазландырылды.

Заманча системаларны кулланышка кертү түбәндәге юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны ачыкларга мөмкинлек бирде: каршы як хәрәкәте өчен билгеләнгән юлга чыгу, светофорның тыя торган сигналы янганда тукта сызыгын үтеп чыгу, авыр йөкле һәм эре габаритлы йөкләр ташу кагыйдәләрен, транспорт чаралары туктау һәм аларны вакытлыча куеп тору кагыйдәләрен, «Хәрәкәт туры» («Хәрәкәт туры яки уңга») юл билгеләре билгеләгән таләпләрне, «Рөхсәт ителгән максималь массасы 15 тоннадан артыграк булган йөк автомобильләре хәрәкәте тыела» дигән тыя торган юл билгесе таләпләрен бозып, юл чатында борылу һәм борылып кире юнәлештә хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозу.

Федераль автомобиль юлларында йөк автомобильләре йөртүчеләренә юллардагы хәлләр: булган юл-транспорт һәлакәтләре, һава шартлары, хәрәкәт тизлеген тикшерү һ.б. турында хәбәр итү системасы файдалануга тапшырылды.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның юлда закон тыңлаучан итеп тоту стереотипларын формалаштыру максаты белән киң күләмле мәгълүмати-пропаганда акцияләре һәм чаралары үткәрелде: машина йөртү осталыгы буенча «Автоледи», Өлкәннәр көненә багышланган «Автосессия» республика конкурслары, массакүләм мәгълүмат чаралары, кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар, иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемалары буенча матбугат конференцияләре һәм түгәрәк өстәлләр.

Балалар белән аларның юл-транспортта җәрәхәтләнүен профилактикалау һәм аларны юл хәрәкәтендә куркынычсыз катнашуга өйрәтү буенча массакүләм чаралар

оештырылды (балалар һәм яшүсмерләр автомәктәпләре, хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары арасында «Куркынычсыз тәгәрмәч» республика, район һәм шәһәр конкурслары, хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары активистларының профильле сменалары, белем бирү оешмалары арасында юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча конкурслар, «Атлый торган автобус» («Шагающий автобус»), «Куркынычсызлык минутлары» профилактика чаралары).

2020 елда белем бирү оешмаларына 35 автокласс, 26 мобиль автошәһәрчек, 15 база автошәһәрчеге, 19 велотренажер, 56 интерактив такта, «Беренче ярдәм күрсәтү нигезләрен белү» этабын әзерләү һәм үткәрү өчен 31 манекен, «Куркынычсыз тәгәрмәч» хәрәкәтнең яшь инспекторлары конкурсының «Велосипедны фигуралы йөртү» этабын әзерләү һәм үткәрү өчен 175 элемент бирелде.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре һәм мәктәп укучыларына өстәмә белем бирү системасының гомуми белем бирү учреждениеләре өчен фәнни-методик материаллар, программалар, басма һәм электрон уку пособиеләре бастырып чыгарылды. Башлангыч сыйныф укытучыларының һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләренең «Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече мәктәп яшендәге балаларга юлларда хәвефсез тәртип кагыйдәләрен өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» темасы буенча квалификациясен күтәрү курслары үткәрелде.

Ата-аналар белән балаларга юлда хәвефсез тәртип кагыйдәләренең нигезләрен өйрәтү, транспорт чараларында балаларны йөрткәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча системалы эш җайга салынган (Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләренең ата-аналар җыелышларында катнашуы, ата-аналар патруле активистлары белән уртак профилактик рейдлар үткәрү, бала тудыру йортларында юл йөрү кагыйдәләре буенча тренинглар үткәрү оештырылган).

Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы һәм «Балаларның Мәрхәмәтле Юлы» федераль басмасы ярдәмендә яшь инспекторларның хәрәкәтен үстерү буенча беренче вебинарлар узды. Алар бөтен илдән 16 меңнән артык катнашучы җыйдылар.

Республиканың яшь хәрәкәт инспекторлары командасы «Куркынычсыз көпчәк» Бөтенроссия конкурсында катнашты һәм 1 урынны яулады.

Республика клиник хастаханәсенең перинаталь үзәгендә «Куркынычсызлык - иминлек» акциясе башланды. Бала тудыру йортыннан чыгарылганда гаилә автомобиль люлькасын бушлай ала.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре «Иннополис» университеты белгечләре белән берлектә машина йөртү хокукларын алу өчен практик имтихан кабул итү буенча аппарат-программа комплексы эшләделәр. Система, юл шартларына карап, машина йөртүчегә кандидатның гамәлләренә җавап бирә. Яңалыкларны теоретик имтихан тулыландырачак - аларны виртуаль чынбарлык күзлекләре ярдәмендә тапшырырга мөмкин булачак. Мондый комплекс имтихан алу сыйфатын арттырырга ярдәм итәчәк.

Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә юл-транспорт һәлакәтләрен рәсмиләштерү үзәкләре эшли башлады. Алар бердәм тәрәзә принцибы буенча ЮХИДИ хезмәткәрләрен җәлеп итмичә юл-транспорт һәлакәтен (шул исәптән Евроберкертмә буенча) рәсмиләштерергә һәм шунда ук иминият компаниясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә.

«2014–2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасы кысаларында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы чаралары комплексын, шулай ук «2013 - 2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасын гамәлгә ашыру юл-транспорт һәлакәтләре санын киметүнең һәм аларның нәтиҗәләрен киметүнең уңай динамикасын саклап калырга мөмкинлек бирде. Әйтик, 2020 елда Татарстан Республикасы юлларында 4 005 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән (2019 ел белән чагыштырганда 11,5% ка кимрәк), аларда 331 кеше һәлак булган (2019 елда - 369) һәм 4 881 - яралар алган (2019 елда - 5 619).

Элеккеге кебек үк, транспорт чаралары йөртүчеләр авария хәленә билгеле бер йогынты ясый. Алар гаебе белән 3 574 юл-транспорт һәлакәте булган, яки юл-транспорт һәлакәтенең 89,2% ы (2019 елда - 4 133), аларда 277 кеше һәлак булган (2019 елда - 317) һәм 4 497 кеше яраланган (2019 елда - 5 269).

ЮХИДИ хезмәткәрләре тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен РФ АХБКо 20.25 статьясы (административ штрафны түләмәү яки административ арест салу урынын үз белдеге белән калдыру) буенча 29 289 беркетмә рәсмиләштерелгән (2019 елда - 28 172), 1 704 хокук бозучыга административ арест салынган, 20 054 - штрафка тартылган, 808 - мәҗбүри эшләр рәвешендә санкция кулланган.

***35. Торак йортларда һәм гражданнар күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.***

Татарстан Республикасы территориясендә ел саен янгын сүндерү-профилактика эшләре алып барыла. Алар составына полиция хезмәткәрләре, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, “Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгы” дәүләт учреждениесенең янгын профилактикасы инструкторлары, Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте Татарстан республика бүлекчәсе хезмәткәрләре, муниципаль янгын сагы әгъзалары кергән профилактик төркемнәр оештырылды. Профилактик төркемнәр күпфатирлы торак йортларга, шәхси йорт биләмәләренә, шул исәптән күп балалы гаиләләр, ялгыз өлкән гражданнар, имин булмаган элементлар яшәгән урыннарга йөриләр, янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча күрсәтмәләр бирәләр, көнкүрештә үз-үзеңне тоту турында листовкалар һәм белешмәләр тараталар, гражданнар җыеннарын үткәрәләр. Бу эш радио, телевидение, массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

Сәүдә-күңел ачу һәм спорт комплексларында электрон-мәгълүмати телекоммуникацияләр системасын үстерүне исәпкә алып, шулай ук Казан шәһәре автовокзалы бинасында таблосында даими рәвештә янгынга каршы тематикага социаль видеороликлар трансляцияләнә торган ОКСИОН системалары урнаштырылган.

2016–2020 елларда Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе тарафыннан янгынны вакытында ачыклау һәм янгын турында хәбәр итү максатында Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Янгынга каршы баш идарәсе тарафыннан балигъ булмаган балалары булган социаль

куркыныч хәлдәге гаиләләр, күпбалалы (5 һәм аннан да күбрәк бала булган) гаиләләр, социаль яклау органнарында патронаж исәбендә торучы инвалидлар, шулай ук Бөек Ватан сугышы ветераннары яшәгән йортларда (фатирларда) янгын турында автоном хәбәр иткечләр белән җиһазландыру буенча хәйрия акциясе уздыру инициативасы белән чыкты. Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 41,9 млн сум бүлеп бирелгән. Күрсәтелгән категориядәге 39 939 йорт биләмәсендә 153 804 автоном янгын хәбәрчесе урнаштырылган. 2018 елдан 2020 елга кадәр муниципаль берәмлекләр, гражданнар һәм иганәчеләр ярдәме хисабына барлыгы 27 270 йорт биләмәләрендә 65 369 хәбәр иткеч урнаштырылган. Әлеге системалар инде үз нәтиҗәлелеген күрсәтте. Әйтик, 2016 – 2021 елларда торак йортларда (фатирларда) булган 62 янгын очрагында янгын сүндерүчеләр реакциясе аркасында, йортта яшәүчеләргә янгын чыгу турында үз вакытында хәбәр иткәннәр, бу 125 кешенең (шул исәптән 53 бала) гомерен коткарган.

Кешеләрнең массакүләм булу урыннарында Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан массакүләм чаралар (спорт, дәүләт, милли бәйрәмнәр һ.б.) үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен кизү тору оештырыла.

***36. Юлларда теләнү өчен инвалидлар һәм социаль якланмаган башка төркемнәрдән файдалануга бәйле хокук бозуларга каршы көрәшкә юнәлтелгән чаралар турында.***

Эчке эшләр органнары тарафыннан күзәтүчесезлекне һәм сукбайлыкны (шул исәптән балигъ булмаганнар арасында) профилактикалауга, җәмәгать урыннарыннан теләнчеләрне һәм башка асоциаль затларны ачыклауга һәм алуга юнәлтелгән чараларны үткәрүгә даими игътибар бирелә.

Чаралар барышында кибетләр персоналы, базарлар хезмәткәрләре, кешеләр белән сукбайлык һәм теләнү белән шөгыльләнүче балалар, шулай ук балигъ булмаганнарны теләнеп йөрүгә җәлеп итүче өлкән затлар турында мәгълүмат алу турында әңгәмәләр уздырыла.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ хезмәткәрләре инвалидларны һәм юлларда теләнчелек өчен социаль якланмаган башка төркемнәрне куллануга бәйле хокук бозуларны профилактикалауда һәм кисәтүдә актив катнашалар. Юлларның машина юлы өлешендә транспорт чаралары хәрәкәте өчен киртәләр тудыручы теләнчелек белән шөгыльләнүче затларга карата Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.29 статьясындагы 1 өлеше буенча административ материаллар төзелә (Юл хәрәкәте кагыйдәләрен җәяүле яисә юл хәрәкәте процессында катнашучы башка зат тарафыннан бозу).

**Экология, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре, бакчачылык**

***37. Татарстан Республикасы территориясендә хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү өлкәсендәге законнарны үтәү барышы турында, шул исәптән хуҗаларсыз хайваннар өчен приютлар булдыру өлешендә.***

2020 елның 1 гыйнварыннан «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 498-ФЗ номерлы Федераль закон) аерым нормалары үз көченә керде, алар, аерым алганда, хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр җайга сала. 498-ФЗ номерлы Федераль законның төп чараларына аулаулар, хайваннарны бары тик приютларда гына тоту, югалган хайваннарны аларның хуҗаларына кайтару, агрессив булмаган хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару, яңа хуҗаларына тапшырганчы яисә аларның табигый үлеменә кадәр хайваннарны приютларда урнаштыру керә.

498-ФЗ номерлы Федераль законда бары тик хайванның авыр дәваланмый торган авыруы яки хайван тормышына туры килми торган кискен имгәнүенең нәтиҗәсе булган очракта гына эвтаназия куллану мөмкинлеге каралган. Калган очракларда хуҗаларсыз хайваннар аларның табигый үлеменә кадәр бары тик приютларда гына генә яшәячәк.

Хайваннар өчен приютлар дәүләт, муниципаль, шулай ук шәхси булырга мөмкин. Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарны вакытлыча тоту өчен 17 пункт эшли.

498-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели торган “Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) кабул ителде.

«Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) нигезендә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына 2014 елдан алып хуҗаларсыз хайваннарны аулау, карап тоту һәм санын җайга салу буенча вәкаләтләр бирелде.

«2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хуҗалардан башка хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда чараларны оештыруга муниципаль районнарга һәм шәһәр округларына 56,7 млн сум күләмендә субвенцияләр бүлеп бирү каралган.

498-ФЗ номерлы Федераль законны һәм 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге закон асты актлары басылып чыкты:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 1 ноябрендәге 995 номерлы карары (Махсуслаштырылган предприятиеләр тарафыннан хуҗаларсыз хайваннарны аулау, транспортировкалау, карап тоту, исәпкә алу һәм

аларның санын җайга салу чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар нормалары стандартлары билгеләнгән);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы карары (Татарстан Республикасы территориясендә хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе расланган);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 31 гыйнварындагы 65 номерлы карары (Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче 1 000 кешегә хуҗаларсыз хайваннар санының нормативы билгеләнгән);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 февралендәге 90 номерлы карары (Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе расланган). Күрсәтелгән Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру процедурасын регламентлый, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә һәм аның территориаль органнарына хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗаларсыз хайваннарны карап тоту һәм алардан файдалану таләпләрен үтәү өлешендә дәүләт күзәтчелеге вәкаләтләрен беркетә;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 февралендәге 150 номерлы карары (Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибе һәм хайваннарны карап тоту нормалары расланган).

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы тарафыннан хайваннар өчен приютлар төзүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү максатында дәүләт программасын эшләү турында мәсьәлә карала.

***38. Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү системасын реформалаштыру барышы турында. Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыкларны аерым җыюны оештыру перспективалары һәм каты коммуналь калдыкларны чыгару буенча «факт буенча» хезмәт күрсәткән өчен исәп-хисап турында.***

Калдыклар белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыруда катнашу буенча (алга таба – ККК), ул «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясында билгеләнгән, 2016 – 2018 елларда төбәк дәрәҗәсендә Татарстан Республикасының ККК белән эш итүнең яңа системасына күчү өчен кирәкле норматив хокукый база тулысынча формалаштырылган.

2019 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы яңа системага күчте, шул ук вакытта ККК белән эш итү Көнбатыш һәм Көнчыгыш зоналары буенча ККК белән эш итү буенча төбәк операторлары тарафыннан Татарстан Республикасының калдыклар белән, шул исәптән ККК белән эш итү өлкәсендәге территориаль схема (алга таба – Территориаль схема) нигезендә тәэмин ителә.

ККК белән эш итү буенча төбәк операторлары эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешүләр 10 елга төзелгән: эшчәнлекнең Көнчыгыш зонасы буенча - «Гринта» ҖЧҖ белән, эшчәнлекнең Көнбатыш зонасы буенча - «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» ҖЧҖ белән.

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның $24^6$-$24^7$ статьялары нигезендә ККК белән эш итү, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү югарыда күрсәтелгән төбәк операторы тарафыннан Трриториаль схема нигезендә тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 21 декабрендәге 1202 номерлы карары белән ККК әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә тискәре йогынтыны киметүгә, ККҚдан икенчел матди ресурсларны максималь алу максатларында ККК аерым туплау системасын булдыруга, ККК белән эш итү буенча хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтүгә юнәлтелгән Татарстан Республикасы территориясендә ККК туплау (шул исәптән аларның аерым туплану) тәртибе расланды. Әлеге тәртип буенча КККны аерым туплауның дуаль схемасы (органик калдыкларны үз эченә алмаган һәм алган КККны аерым туплау) Татарстан Республикасы территориясендә КККны аерым туплауның төп ысулы буларак билгеләнә. ККК туплауның дуаль схемасын куллану контейнер мәйданчыгында төргәктән һәм чит кушылмалардан чистартылган азык-төлек калдыкларын җыю өчен аерым контейнерлар, куллану үзенчәлекләрен югалткан пластмасса эшләнмәләрне җыю өчен челтәр контейнерлар урнаштыру мөмкинлеген кире какмый.

Хәзерге вакытта республиканың күп шәһәрләрендә контейнер мәйданчыкларында ПЭТФ-шешәләр (полиэтилентерефталаттан), көнкүреш химиясеннән пластик тәлинкәләр, пластик канистрлар өчен челтәр контейнерлары урнаштырылган. Моннан тыш, халыкка утильчимал кабул итү пунктлары да эшли, анда халыкка картонны, кәгазьне, алюминий банкаларны, ПЭТФ-шешәләрне һәм ККҚның башка утиль морфологик компонентларын утильләштерүгә биргән өчен акча түләнә.

Казан шәһәрендә «Чиста мохит» проекты кысаларында халыктан икенчел чимал кабул итүнең 10 махсуслаштырылган пункты эшли, анда ККК морфологик компонентларының 11 төре утильләштерүгә кабул ителә, шул исәптән ПЭТ-шешәләр, ТБП канистрлары (түбән басымлы полиэтилен), көнкүреш химиясеннән ТБП тартмасы, пленка. Проектның планнарында - мондый пунктлар санын 20 гә кадәр арттыру. Республиканың контейнер мәйданчыкларының 25 % ККҚны аерым туплау өчен контейнерлар белән тәэмин ителгән, күрсәтелгән контейнер мәйданчыкларының иң күбе Казан шәһәренә туры килә (53 %). Шул ук вакытта ККК аерым җыюга күчү транспорт чыгымнарын арттыруга йогынты ясарга мөмкин, чөнки бүленгән икенчел чимал эшкәртү пунктларына аерым транспорт чаралары белән китерелергә тиеш.

ККҚны масштаблы аерым туплауга күчүне тиешле инфраструктура төзегәннән соң гамәлгә ашыру планлаштырыла, ул тупланган ККК барлык күләмен, аларны алга таба утильләштерү өчен, икенчел матди ресурсларны максималь алу максатыннан, эшкәртү объектларына җибәрергә мөмкинлек бирә.

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның $24^{10}$ статьясы нигезендә ККК белән эш итү өлкәсендә

шартнамәләр буенча ККК күләмен һәм (яисә) массасын билгеләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 3 июнендәге 505 номерлы карары белән расланган ККК күләмен һәм (яисә) массасын коммерция исәбенә алу кагыйдәләре (алга таба – 505 номерлы кагыйдә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

505 номерлы кагыйдәләрнең 6 пункты ККК милекчеләре белән исәп-хисапны тормышка ашыру максатларында ККК коммерциячел исәпкә алу 505 номерлы кагыйдәләренең 5 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә, ә атап әйткәндә:

исәпләү юлы белән, түбәндәгеләрдән чыгып:

- күләмнең микъдар күрсәткечләрендә күрсәтелгән ККК туплау нормативлары;

- ККК тупланган урыннарда урнаштырылган ККК туплау өчен контейнерлар саны һәм күләме.

Кулланучылар һәм төбәк операторлары арасында килешү төзегәндә югарыда санап үтелгән ысулларның берсе сайлана.

Калдыкларның фактта барлыкка килүеннән чыгып, ККК чыгару федераль законнарда каралмаган. Шуңа бәйле рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 3 июнендәге 505 номерлы карарына «билгеләнгән» терминын «чыгарылган» контейнерларга алыштыру өлешендә үзгәрешләр кертү максатка ярашлы. Алыштыру контейнер мәйданчыкларында контейнерлар саныннан һәм күләменнән чыгып, чүп чыгару машинасына төялгән контейнерларны чыгару фактын исәпкә алып, коммерция исәбе ысулын корректлы файдаланырга мөмкинлек бирәчәк.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) массасын коммерция исәпкә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 3 июнендәге 505 номерлы карарына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустин адресына 2020 елның 29 июнендәге 01-5727 номерлы хат белән җибәрелде.

***39. Кошлар, терлекләр токымнары, җирле селекция җиләк-җимеш һәм яшел культуралар сортлары турында мәгълүматны да кертеп, соңгы утыз елда селекция өлкәсендә Татарстан Республикасының казанышлары турында.***

Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы культуралары селекциясе белән «Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты - «Россия Фәннәр академиясенең федераль тикшеренү үзәге» ФДФБУ аерымланган структур бүлекчәсе» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе (алга таба – ТатФХФТИ) шөгыльләнә. Хәзерге вакытта ТатФХФТИ үсемлекчелек, үсемлекләрне яклау һәм аларның биотехнологияләре һәм зоотехнияләр буенча тикшеренүләр алып бара. Селекция 15 культура (көзге арыш, көзге бодай, көзге тритикале, сабан бодае, арпа, сабан рапсы, борчак, соя, карабодай, тары, бәрәңге, кукуруз, алмагач, чия, слива), орлыкчылык - 13 культура (көзге арыш, көзге бодай, көзге тритикале, сабан бодае, арпа, рапс, борчак, солы, клевер, люцерна, солы, карабодай, бәрәңге) буенча алып барыла.

Фәнни нәтиҗәләрнең әһәмияте һәм яңалыгы. 2020 елда селекция казанышларына һәм уйлап табуларга Россия Федерациясенең 9 патенты алынган, патентларга 8 гариза бирелгән. Куллануга кертелгән Слекция казанышларының

Ддәүләт реестрына (алга таба – Дәүләт реестры) институтның Россиянең 32 төбәгендә җитештерүдә эшләүче 102 селекция сорты кертелгән. 26 сорт дәүләт сорт сынавын уза.

Тикшеренүләр яңалыгы Россия Федерациясенең селекция казанышларына һәм уйлап табуларга 194 патенты белән якланды, шуларның 53 е гамәлдәге. Соңгы елларда сортлар булдыру ешлыгы шактый артты. 5 ел эчендә 53 сорт булдырылган, шуларның 30ы Дәүләт реестрына кертелгән.

Эшләнмәләр Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе милкенең барлык рәвешләрендәге хуҗалыкларда актив кертелә. Соңгы 10 елда Татарстан селекциясенең сортлары 777 мең гектардан артык чәчүлек мәйданнары били, Россиядә - 2,0 млн гектарга якын. Беренче унлыкта – Россиядә чәчү мәйданнары буенча алдынгылар рәтенә Раушан сабан арпасы , Экада 109 сабан бодае, Тантана көзге арыш сортлары керә.

2017 елдан ТатФХФТИ Россия Федерациясе авыл хуҗалыгын үстерү буенча 2017 – 2025 елларга «Россия Федерациясендә бәрәңге селекциясен үстерү» ярдәмче программасы буенча федераль фәнни-техник программаны гамәлгә ашыруда катнаша. Максат - авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бәрәңгенең үз сортларын сыйфатлы орлык материалы белән тәэмин итү һәм бәрәңге игүнең орлык материалы импортына бәйлелеген киметү.

Гомумән алганда, соңгы 10 елда институтта бәрәңгенең вируска карыш торырлык 9 сорты булдырылган, 5 - Дәүләт реестрына кертелгән, 4 - дәүләт сорт сынавы уза. Ел саен илебез селекциясенең 70 сорты экологик-географик сынау уза. Үткәрелгән сынаулар күрсәткәнчә, институтта чыгарылган бәрәңгенең заманча сортлары Россия аналогларыннан югары уңдырышлылык, бик яхшы тәм сыйфатлары, крахмалның югары булуы белән аерылып тора.

Моннан тыш, ТатФХФТИ базасында «Бәрәңгенең биоресурс коллекциясе» күмәк куллану үзәге булдырылды, аның составында 523 сорт һәм гибрид бар, сәламәтләндерелгән меристем нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасы эшләнде һәм гамәлгә кертелде. Биотехнологик комплекс халыкара сыйфат стандартларына туры килә торган савыктырылган орлык бәрәңге җитештерергә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта институт тарафыннан җиләк-җимеш культураларының селекция процессы, яңа сыйфат характеристикалары булган алма, слива һәм чия сортларын булдыру процессын үз эченә алган бүлекчәләрнең берсе буларак, күмәк һәм сәнәгать бакчачылыгы өчен өлгерү сезонын исәпкә алып, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгының Дәүләт биреме нигезендә үткәрелә. Җимеш үстерү юнәлешендә институтта галимнәр тарафыннан барлыгы 40 тан артык алмагач, слива, чия, кура җиләге үстерелгән, алар актив рәвештә республика хуҗалыкларына кертелә. Җиләк-җимеш культуралары селекциясе буенча институт Урта Идел буе зонасында эшли. Дәүләт реестрына хәзерге вакытта ТатФХФТИ селекциясенең 21 сорты кертелгән. Соңгы 5 елда 6 сорт җиләк-җимеш культурасы булдырылган, 2 сортка ( «Синеокая» өй сливасы һәм «Камская» алмагачлары) Россия Федерациясе патентлары алынган, 4 сорт дәүләт сорт сынауларын уңышлы уза («Аркад Теньковский» алмагач, «Аляевская», «Низкорослая», «Шеланговская» чияләре).

Республиканың терлекчелек комплексында соңгы утыз елда түбәндәге юнәлешләр буенча яңа токымнар чыгарылды:

терлекчелек өлкәсендә селекция казанышларына - сөтчелек юнәлешендәге эре мөгезле терлекләр буенча Татарстан тибындагы холмогор токымына патент алынган, республиканың 28 нәселле хуҗалыгында 25 мең сыер асырыйлар;

сарыкчылык өлкәсендә Татарстан токымыннан булган сарык Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы» агрофирмасы» ҖЧҖендә үрчетелә, анда 1 500 баштан артык сарык бар;

атчылык өлкәсендә селекция казанышларына - татар токымлы атларга хокук иясе - «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелектә нәсел эше буенча баш дәүләт авыл хуҗалыгы идарәсе» дәүләт казна учреждениесе, аңа 10037 номерлы патент бирелде.

Хәзерге вакытта республиканың 5 хуҗалыгында татар токымыннан 700дән артык ат исәпләнә һәм әлеге токымлы атлар үрчетү буенча нәселле репродуктор статусын алу буенча эш алып барыла.

**Җирле үзидарә мәсьәләләре**

***40. Җирле үзидарә органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләренең вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү дәрәҗәсе турында.***

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары, тәкъдим ителгән федераль индекс-дефляторларны исәпкә алып, республиканың берләштерелгән бюджетын төзүнең бердәм сценар шартларыннан чыгып формалаштырылды.

2021 елга бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда җирле бюджетлар, 2020 ел дәрәҗәсенә карата 1,0 млрд. сумга, ягъни 3,1 % ка киметеп, законнар белән беркетелгән керемнәр буенча 32,1 млрд. сум күләмендә фаразланган. 2021 елга җирле бюджетларның чыгымнары үз вәкаләтләре буенча, 2020 елга карата 4,2 млрд сумга, ягъни 7,5 % ка үсеш белән, 59,6 млрд. сум күләмендә билгеләнгән.

Шулай итеп, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларының чыгым вәкаләтләренең 2021 елга беркетелгән керемнәр белән тәэмин ителеше уртача 53,9 % тәшкил итте.

Җирле бюджетларның баланс проблемасы ел саен бюджетара җайга салу аша хәл ителә.

2021 елга җирле бюджетларны баланслау максатларында Татарстан Республикасы бюджетында җирле бюджетларга 15,4 млрд сум күләмендә дотацияләр һәм субсидияләр каралган. Моннан тыш, физик затлар керемнәренә салым муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең бер өлешен алмаштыручы өстәмә нормативлар буенча җирле бюджетларга 12,2 млрд сум күләмендә күчерелергә тиеш.

Финанс ярдәмен исәпкә алып, 2021 елга республика җирле бюджетлары керемнәренең гомуми күләме 59,7 млрд сум күләмендә каралган, тискәре трансфертлар түләү буенча йөкләмәләрне исәпкә алып, үз вәкаләтләре буенча чыгымнар күләме – 59,7 млрд сум.

Шул рәвешле, 2021 елга җирле бюджетлар чыгымнар формалашуның сценарий шартларында дефицитсыз булып тора.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, ел саен Татарстан Республикасы бюджетыннан республика районнарына һәм шәһәрләренә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, социаль-мәдәни өлкә объектларын файдалануга кабул итүгә һәм файдалануга кертүгә, шулай ук муниципаль учреждениеләрне үстерүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрүне тәэмин итә торган чараларны гамәлгә ашыруга акчалар өстәмә рәвештә җибәрелә. Әйтик, 2020 ел дәвамында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга беренчел бүленгән финанс ярдәменә өстәмә рәвештә 10,9 млрд сум күләмендә бюджетара трансфертлар бирелгән.

Муниципаль берәмлекләр бюджетлары ел саен салым һәм салым булмаган керемнәр буенча беренчел расланган планлаштырылган билгеләнештән арттырып үтәлә.

Муниципаль берәмлекләр бюджетларына 2020 елда үз керемнәре 48,9 млрд сум күләмендә кергән, бу расланган планга карата 106% тәшкил итә. 2020 ел нәтиҗәләре буенча җирле бюджетларның беренчел расланган салым һәм салым булмаган керемнәренә өстәмә рәвештә алынган салым күләме 3,4 млрд сум тәшкил иткән. Ел дәвамында планлы күрсәткечләрдән тыш алынган җирле бюджетларның күрсәтелгән үз керемнәре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү буенча чыгымнарны финанслауның өстәмә чыганагы булып тора.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләү методикалары җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасының тиешле законнары белән расланды.

## *41. Халыкны су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү чаралары турында.*

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне оештыру, су чыгаруны җирле үзидарә мәсьәләләренә кертә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 3 меңнән артык су җыю җайланмасы файдаланыла, шул ук вакытта лицензия буенча су чыгару 1 220 су белән тәэмин итү чыганагы булган хуҗалык субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның 996 лицензиясе авыл җирлегендә халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен бирелгән, калган лицензияләр хуҗалык-эчәргә яраклы су, яки предприятиеләрне техник су белән тәэмин итү өчен бирелгән. Куллану килешүләре булмаган чишмәләр саны 306 берәмлек тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте ел саен җирлекләрне 650 млн сумлык су белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә муниципаль берәмлекләргә

финанс ярдәме күрсәтә. Татарстан Республикасы торак пунктларында төзелергә, капиталь ремонтланырга һәм реконструкцияләнергә тиешле халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү объектлары исемлеге җирле үзидарә органнарыннан гаризалар нигезендә формалаша.

Су чыгару объектларын модернизацияләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар бүлеп бирелә. 2021 елга финанслауның гомуми күләме167,1 млн сум булган чистарту корылмаларын модернизацияләү һәм канализация челтәрләрен капиталь ремонтлау чаралары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 14 гыйнварындагы №24-б боерыгы белән расланды. Исемлек җирле үзидарә органнарыннан гаризалар нигезендә төзелә.

«Чиста су» проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын арттыру буенча төбәк программасы расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 июлендәге 636 номерлы карары), ул Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчалары исәбеннән 1 014,1 млн сумлык 10 чара үтәүне күздә тота.

«Иделне чистарту» федераль проекты кысаларында 2019–2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасы расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 июлендәге 635 номерлы карары), ул Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 10 010,5 млн сумлык чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота.